# ФӘНИС ЯРУЛЛИН
# ӘСӘРЛӘР

Өч томда

# I
том

*Шигырьләр, поэмалар, җырлар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2 Рос=Тат)-5
Я74

РЕДКОЛЛЕГИЯ:

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Р.Х.Корбанов, Х.Г.Әюпов*

**Яруллин Ф.Г.**

Әсәрләр: 3 томда / Фәнис Яруллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.

ISBN 978-5-298-01617-9

1 т.: Шигырьләр, поэмалар, җырлар / кереш сүз авт. С.Хәкимова. — 2007. — 495 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01625-4

ISBN 978-5-298-01625-4 (1 т.)
ISBN 978-5-298-01617-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Яруллин Ф.Г., 2007

## ҖИҢҮЛӘР ҖИҢЕЛ БИРЕЛМИ

Татар әдәбияты — мең еллык әдәби мирасы, бай язу культурасы, стиль үзенчәлекләре, жанрлар төрлелеге белән бөтен дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән әдәбият. Буыннар чылбырының ныклыгы, дәвамчылыкның көчлелеге нәтиҗәсендә ул безнең көннәргә кадәр килеп ирештe. Бай сүз сәнгатенең элек-электән тупланган тәҗрибәсе чагыштырмача яшьрәк әдипләрнең иҗатларына да йогынты ясады һәм әле дә ясап килә.

Менә шушы бай мираслы әдәбиятка санлы өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдипләр арасында Фәнис Яруллин да бар. Аның иҗатында Кол Галидән үк килә торган киң диапазонлы фикерләү куәсе, «Идегәй» эпосындагы масштаблылык, «Таһир-Зөһрә» кебек гыйшык дастаннарыннан күчкән кайнарлык, Г.Кандалыйдагы кебек үзенчәлекле шаянлык һәм шулар белән бергә халык авыз иҗатына хас тапкырлык, сагыну-сагышларны, милләтебезгә хас булган башка асыл сыйфатларны күрергә мөмкин.

Узган гасырның алтмышынчы елларында татар әдәбиятына бер төркем яңа буын әдип һәм шагыйрьләр килде. Алар арасында Ф.Яруллин үзенең күптармаклы һәм үзенчәлекле иҗаты белән игътибарны җәлеп итә. Аның әдәби эшчәнлеге үзенчәлекләреннән берсе төрле жанрларда иҗат итү булса, икенчесе — авторның геройлары арасындагы мөнәсәбәтләрнең тирән драматизм белән сурәтләнеп, нечкә психологик алымнар белән чишелүдә. Алай гына да түгел, шагыйрь, прозаик, драматург, балалар әдәбияты өлкәсендә армый-талмый эшләүче һәм җәмгыятьтә барган вазгыятьнең төрле якларын тиз арада күреп алып, аларга матбугат аша үз бәясен биреп баручы кыю фикерле, туры сүзле публицист та ул.

Төрле жанрларга караган әсәрләре Ф.Яруллиның эзләнү һәм табышларын гына түгел, бәлки әдипнең Яңарыш

чоры татар әдәбиятында тоткан урынын тулырак ачыклау ягыннан да игътибарга лаеклы.

Эш шунда ки, әдипнең тәрҗемәи хәле, шәхси язмышы аның иҗади эшчәнлегенә көчле тәэсир ясый, әсәрләрендә чагылыш таба һәм бу ахыр чиктә язучының татар әдәбияты үсешендәге үз юлын һәм урынын билгели. Ягъни байтак дәрәҗәдә шәхси биографиясе белән бәйле рәвештә ул беренче әсәрләреннән үк диярлек шул вакыттагы рәсми идеология кануннарына буйсындырылган әдәби юнәлешкә бик үк туры килеп бетмәгән мәсьәләләр күтәрә башлый һәм алга таба әлеге тенденцияләр аның иҗатында көчәйгәннән-көчәя бара. Ләкин эш язучының үз язмышын әдәби әсәрләрендә чагылдыруда гына түгел, ә фикерләү рәвешенең шактый дәрәҗәдә башкачарак булуында, ягъни әсәрләрен тормышның тышкы конфликтлары аша түгел, вакыйга-күренешләрне күңелдә туган хис һәм кичерешләргә бәйләп, аны күңелдән үткәреп тормыш каршылыклары белән бәрелештә, дөнья турында, күбрәк гадәти булмаган шәхес аша герой язмышын алгы планга куюда.

1960 еллар, билгеле ки, әдәби мохит өчен берникадәр уңайлыклар барлыкка килгән чор. Шәхес культы фаш ителә, хаксызга гаепләнгән хисапсыз башка кешеләр белән бергә татар әдипләре дә реабилитацияләнеп үз илләренә кайта башлый. Аларның ачы тормыш тәҗрибәләре белән яшьләрнең фәлсәфи уйланулары әдәби үсештә үзенчәлекле синтезын барлыкка китерә. Иҗтимагый тормыш ни рәвешле генә бормалы булмасын, табигый ки, анда буыннар алмашыну бара һәм бу үз чиратында яшәешкә карата фикерләр үзгәрүгә китерә.

Ф.Яруллинның иҗаты әнә шундый чорга туры килде. Авыр язмыш сынаулары яшь әдипне шәхес буларак өлгерергә, дөньяга алсу күзлек аша түгел, ә тирән фикри кыйммәтләр призмасы аркылы карарга өйрәтә. Иҗади эшчәнлегенең башлангыч чорында ук шигырьләр, хикәяләр, сонетлар һәм әкиятләр, хәтта драматургия жанрына караган скетчлар язуы аның киләчәктә күпкырлы талант иясе булып җитлегәчәгенә ишарәли.

Ф.Яруллинның беренче шигырьләре 1960 еллар башында матбугат битләрендә күренә башлый. Берникадәр самими, бераз моңсу, шул ук вакытта юмор чаткылары да күренеп алган әлеге әсәрләр тиз арада укучы күңеленә юл таба. Чөнки укучы аларда үз хисләрен, үз кичерешләрен күрә. Шуңа күрә аның шигырьләрен каләмдәшләре һәм тәнкыйтьчеләр дә хуплап каршы ала. Яшь шагыйрьнең исеме тиздән географик киңлекләрне дә иңли башлый. Аның әсәрләре Мәскәүдә, Молдавиядә, Казахстанда һәм башка республикаларда төрле телләрдә нәшер ителү моңа ачык дәлил. 1964 елда «Комсомольская правда» газетасы уздырган яшь шагыйрьләр ярышында Ф.Яруллин шигырьләре икенче урынны ала. Алтмышынчы елларда бу газетаның тиражы берничә миллион данә икәнлеген искә төшерсәк, шагыйрьнең укучылары саны никадәр артуын күз алдына китерүе авыр түгел. Шул ук елда «Правда» нәшрияты конкурста җиңүчеләрнең иҗат үрнәкләрен «Розовый олень» дип аталган аерым җыентык итеп бастырып чыгара. 1964 елда Ф.Яруллинның Татарстан китап нәшриятында «Мин тормышка гашыйк» дип аталган аерым шигырь китабы нәшер ителә. Аңа кадәр әлеге авторның күп кенә шигырьләре 1963 елда әлеге нәшрият тарафыннан тәкъдир ителгән коллектив җыентыкта да дөнья күргән була.

Шагыйрь беренче китабын ни өчен шулай атаган? Әлеге сорауга җавап бирү өчен игътибарны бераз гына булса да аның тормыш юлына юнәлтү сорала.

Ф.Яруллин Баулы районы Кызылъяр авылында туган. Аларның гаиләсендә алты бала үсә. Әтиләре Гатаулла абзый сугышның беренче елларында ук фронтка китә һәм 1942 елның гыйнварында каты яраланып кыр госпитальендә вафат була. Әниләре Бибигафифә апа үзенең тырышлыгы белән алты баланы ач-ялангач итмичә аякка бастыра. Гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килгән Фәнис, белемгә омтылышы көчле булса да, сигезенче сыйныфны тәмамлагач эшкә урнашырга мәҗбүр була.

Өч елдан артык «Татнефть» берләшмәсенең элемтә конторасында монтер булып эшләгәч, ул хәрби хезмәткә чакырыла. Укчы-радистлар мәктәбендә укый һәм... шунда фаҗигагә юлыга. Ләкин Ф.Яруллин рухи төшенкелеккә бирелмичә, үзенең сигезенче сыйныфта укыганда ук шигырьләр, стена газеталары өчен мәкаләләр язуын исенә төшереп, палатадашлары тирән йокыга талгач, күңелендәге хисләр-кичерешләрне, фикерләрне шигъри юлларга сала башлый. Шуңа күрә дә аның беренче китабы «Мин тормышка гашыйк» дип аталуы шагыйрьнең үз язмышына чакыру ташлавы дип аңлашыла.

Тора-бара шигырьләр белән беррәттән поэмалар, хикәяләр, повестьлар, пьесалар иҗат ителә. Аңа киң танылу алып килгән әсәрләрдән «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте дисәк, ялгыш булмастыр. Анда автор кеше рухының мөмкинлекләрен Фәнияр образы аша ача.

Күп кенә каләм ияләре производствога багышланган, ягъни зур күләмле эш процессында гына геройларны тирәнтен ачып була дип, гигантомания белән мавыкканда, Ф.Яруллин аерым шәхеснең тормыш-яшәешен психологик киеренкелектә, геройны төрле халәт яссылыгында сурәтләү юлы белән дә тулы канлы, тормышчан итеп күрсәтә алу мөмкинлеген дәлилләде. Бу татар әдәбияты өчен яңалыкларның берсе иде. Әсәр рус теленә дә тәрҗемә ителеп, башта Татарстан китап нәшриятында нәшер ителде, бераздан Мәскәүдә «Первая борозда» дип исемләнгән җыентыгына әлеге повесть тулы килеш кертелә. Бу повестьның казах теленә дә тәрҗемә ителүен һәм татар телендә дүрт тапкыр дөньяга чыгуын, шулай ук күрмәүчеләр өчен дә Брайль алфавиты белән өч томда басылуын әйтсәк, әсәрнең киң катлау укучылар арасында казанган популярлыгы турында артык шәрехләп тору соралмый. Моннан тыш «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», «Кайту», «Яралы язмышлар», «Портрет» һәм башка повестьлары әдәбиятыбызга яңа геройлар, яңача фикерләүче образлар алып килүе белән шулай ук үзенчәлекле.

Ф.Яруллин иҗатының 1960–1970 елларда популярлашып китүе турында аның әсәрләренә карата язылган бихисап тәнкыйди бәяләмәләр, әдипнең портретына штрихлар, авторның шәхесен ачуны максат итеп язылган очерклар, СССРның бик күп төбәкләреннән төрле телләрдә язылган хуплау хатлары ачык сөйли. Дөрес, кайберәүләр әлеге популярлыкны әдипнең авыр язмышка дучар булуы белән бәйле дип тә уйладылар. Алай ялгышучыларның берсенә шагыйрь мондый юллар белән җавап бирә:

Бирә алам аңа сынык кура,
Булдыралса, уйнап карасын.

Сынык кура — сындырылган язмыш. Аңарда төрле көйләр уйнар өчен скрипкасының бер кылында гына

катлаулы музыкаль әсәрләр башкара алган Паганини булырга кирәк, әлбәттә. СССР да, гомумән Россиядә, сындырылган язмышлар байтак, ләкин аларны җиңеп рухи биеклеккә күтәрелүчеләр күп түгел. Тәнкыйтьчеләр, гомумән Ф.Яруллин турында язучылар, игътибарны күбрәк әдипнең әнә шул сыйфатына юнәлттеләр. Билгеле, алар сүзендә дә хаклык бар. Батыр булу җиңел түгел. Ләкин совет әдәбиятында батырлык үз-үзен корбан итү бәрабәренә башкаларга җиңеллек тудыру өчен эшләнде. Әйтик, Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин һәм башкалар Бөек Ватан сугышында күкрәкләре белән дошман амбразурасын каплап һәлак булдылар. Шулай ук ниндидер эштә зур уңышларга ирешеп рекорд арты рекорд куючылар бар. Бу шул дәверләрдә алып барылган сәяси идеология нәтиҗәләре иде. Меңнәрчә корбаннар өстеннән атласаң атла, әмма дөньяны шаккатырырлык батырлык кыл. Интеллектуаль, әхлакый сафлыкка омтылучылар ул заманнарда югары күтәрелә алмадылар. Ф.Яруллин әлеге повестенда һәм гомумән бөтен иҗатында аерым шәхеснең әхлакый сыйфатларын батырлык дәрәҗәсенә күтәрә. Ләкин тәнкыйтьчеләр бу рухи биеклекнең тамырлары нәрсәдә икәнен ача алмадылар. Ә алар әдипнең талантында.

1962 елда әле Казан хастаханәсендә ятканда ук Татарстан радиосында диктор булып эшләүче Э.Гаделев аның белән әңгәмә оештыра. Шигырьләрен магнитофон тасмасына яздыра, радиотыңлаучылар Ф.Яруллинның шигырьләрен үзе укуында, аның тавышында ишетә. Шагыйрьнең иҗатын яратучылар тагын да күбәя. Ул чорда әле тәүлегенә бер-ике сәгать кенә эшләүче телевидение дә читтә калмый. Җиңел видеокамералар булмаганлыктан, шагыйрьне төрле ракурсларда фотога төшерәләр һәм аларны экраннар аша күрсәтәләр. Ә арткы планда А.Арсланов тавышы Ф.Яруллин шигырьләрен яңгырата. Хәтта кинематография дә Ф.Яруллин белән кызыксына. 1960 елларда безнең республикада «Между Волгой и Уралом» дигән документаль фильмнар чыгарыла. Алты республикага таратылган кино-журналның бер саны Ф.Яруллин иҗатын һәм шәхесен яктыртуга багышлана.

Кинематографлар моның белән генә канәгатьләнмичә, Ф.Яруллин һәм аның иҗатын киңрәк планда яктырту юнәлешендә аның кайбер каләмдәшләрен (Илдар Юзеев, Рахмай Хисмәтуллин һ.б.) һәм яшь шагыйрь янына килеп йөрүче кызларны палатага җыеп, берничә көн кинога төшерәләр. Югарыдан кемдер бу эшне туктатырга әмер бирә. Берничә ел элек Ф.Яруллинның 60 яшьлек юбилеен билгеләп үткәндә, телевидениедән килгән оператор шагыйрьгә: «Без бит сине больницада ятканда кинога төшереп, кыска метражлы фильм эшләгән идек. Аны экранга чыгарттырмадылар. Шулай да без аны озак сакладык, күптән түгел генә яндырдык», — дип әйтә. Чөнки кинофильмда Ф.Яруллин җәмгыятьтә шәхеснең роле зур булуын, зур шәхесләр генә җәмгыятьнең үсешен тизләтә дигән фикер әйтә. Бу сүзләр совет идеологиясенә каршы килә дип санала. Шуның нәтиҗәсе буларак фильм күрсәтелми. Әмма Ф.Яруллин үзен ниндидер батырлык эшләүче итеп санамый. Аның үзен күрсәтүгә караганда иҗатын тизрәк халыкка җиткерәсе килә. Әйе, ул чакта сәясәт чылбыры халыклар иреген нык буып тора, ләкин ул заманның да кайбер уңай яклары булганлыгын истән чыгарырга ярамас. Аралашу, республикалар белән республикалар арасында әдәбият алмашулар, әдәби декадалар татар әдәбиятының офыкларын киңәйтә. Ф.Яруллин физик мөмкинлекләре чикле булуга карамастан, андый чаралардан читтә калмый. Мәсәлән, Әзәрбайҗан белән Татарстан арасында шундый декада уздырылу уңаеннан Татарстан китап нәшриятында тугандаш халык шагыйрьләренең шигырьләре тупланган «Каспий дулкыннары» дигән китап басылып чыга. Аны әзерләү барышында әсәрләрне татарчага тәрҗемә итүдә ул да актив катнаша.

Бу урында бераз чигенеш ясап, шуны әйтү дә урынлы булыр: Ф.Яруллин хастаханәдә ятканда урта мәктәпне тәмамлап өлгергәнлек аттестаты ала. 1964–1970 елларда читтән торып Казан дәүләт университетында белем ала һәм аны уңышлы тәмамлый. Аның әле шигырь, әле хикәяләр җыентыгы басылып чыга тора. Иҗади эшчәнлеген ул тәрҗемәләр башкару белән аралаштырып алып бара. Аның рус, каракалпак һәм башка чит тел әдәбияты үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итүе иҗатында тел байлыгын үстерүгә, стиль үзенчәлекләрен камилләштерергә булыша.

Сәламәтлеген даими рәвештә кайгыртып тору кирәклегеннән аңа еш кына төрле шифаханәләрдә булырга туры килә. Шуңа да карамастан ул анда да тыныч кына кала алмый. Әйтик, Бәкер курортында булган чагында шагыйрь янына күп кенә якын-тирә авыллардан сыйныфы-сыйныфы белән укучылар килә. Ә бер кичне Ф.Яруллин белән бергә дәваланырга килгән Д.Шәрәфетдинов әлеге курорт клубында аның белән очрашу оештыра. Ул әдип укыган кайбер шигырьләрне русчага тәрҗемә итеп тамашачыга җиткерә.

Ф.Яруллинга бу очрашу уңай тәэсир ясый. Беренче тапкыр халык белән турыдан-туры аралашып алар тарафыннан шигырьләренең ничек кабул ителүен үз күзләре белән күрү, әсәрләренә язылган җырларны тыңлау аны иҗади хезмәткә тагын да дәртләндереп җибәрә. Әйтергә кирәк, аның шигырьләрендәге халыкчанлык, фикернең строфадан строфага үсә баруы көй язучыларның игътибарын җәлеп итә. Мәсәлән, иҗатының башлангыч чорында ук композитор Наилә Зарипова Ф.Яруллинның дүрт шигыренә көй яза. «Янармын да янармын», «Илем чакыра», «Сиреньнәр» дигән җырлар алтмышынчы еллар башында ук язылып радио фондына алына. Аларны Эмиль Җәләлетдинов, Венера Шәрипова кебек танылган профессиональ җырчылар башкара, әлеге җырларны үзешчәннәр дә теләп җырлый. Шагыйрь әсәрләренә язылган йөздән артык җырны төрле буын вәкилләре үз итте.

Гомумән югары эстетик зәвыкка ия булган күпкырлы талант иясе Ф.Яруллин нинди генә жанрда язмасын, үз әсәрләрендә матурлыкны, камиллеккә омтылышны һәм рухи байлыкны иң зур кыйммәтләрдән саный. Үзенең укучыларына да шушы идеяне ирештерергә омтыла. Әдип иҗатында табигать образы еш кулланыла икән, әлбәттә, ул фон өчен генә түгел, ә матурлыкны кеше белән табигатьнең гармониясе аша сурәтләү өчен алына. Кеше һәм табигать — бербөтен. Шушы бөтенлек саега башлаган күңел байлыгын тулыландыра, аңа бизәкләр өсти. Тау, елга һәм чишмәләр, урман-кырлар, чәчәкле болыннар, кояшлы, айлы, йолдызлы күкләр; җил-давыллар, кар-бураннар, болыт һәм яшеннәр; чиксезлек һәм кешенең үзенә генә билгеле булган микродөньясы — болар әдипнең яратып кулланган образлары. Табигать төрле халәттә, төрле төстә булган кебек, әдип әсәрләрендә дә мондый халәтләр җанның бөеклеген яки түбәнлеген, хисләрнең төрлелеген, кичерешләрнең катлаулы яки тирәнгә яшерелгән икәнлеген күрсәтү өчен кирәк.

Шагыйрь үз әсәрләрендә Вакыт һәм Чиксезлек төшенчәләрен бик табигый рәвештә кертеп җибәрә. Бу аның әсәрләренә киңлек, биеклек кенә өстәп калмый, образлар эченә төренгән фәлсәфи фикерләрне ачарга да ярдәм итә.

Ф.Яруллин иҗатында табигать күренешләре катлауландырылган метафоралар, чагыштыру, параллель кую яки капма-каршылык (антитеза) рәвешендә бирелсә, халык традицияләре, әхлак проблемалары җанны тетрәндерерлек вакыйгалар эчендә сурәтләнә. Төрле жанрларда иҗат итүче әдип буларак, аның хикәя, повесть һәм кайбер драма әсәрләренә игътибарны юнәлтү урынлы булыр. Автор «Тәрәзәгә кунган күбәләк», «Сандугач оясы», «Курку», «Рәнҗү» кебек хикәяләрендә хәзерге заманның характерлы проблемаларына әйләнеп баручы әхлаксызлык, халкыбызда булган матур традицияләрнең — кешелеклелек, ата-ананы зурлау, үз гаебеңне тану кебек матур сыйфатларның югала баруы өчен борчыла. Олыны — олы, кечене кече итеп карау, авыр чакта бер-береңә ярдәмләшү — безнең халкыбызны үзәге нык булган милләт итүдә зур роль уйнаган сыйфатларның берсе. Күп кенә күркәм гадәтләребез онытылып бара, югалуга дучар ителә. Кешеләрдә хөсетлек, бер-берсеннән көнләшү кебек яман сыйфатлар өстенлек ала башлады. Бу хәл совет чорында бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләү, ягъни ялганга корылган идеология нигезендә башланган иде. Ф.Яруллинның «Әнә килә автомобиль», «Бай эти», «Койрыксыз сандугач» һәм башка комедияләрендә ( ә бит боларның беренчесе 1974 елда ук сәхнәгә куела) үз туганыңнан да көнләшү, байлыкка табыну, үз этиләренең акчасын һәр бала бары тик үзенә генә тиешле дип санау матур традицияләребезнең инде күптән бозыла башлавын күрсәтә. Номенклатур катлау урлашты, алдашты, халыкны хәерчелектә тотып үзенә буйсындырырга теләде. Җәмгыятьнең барлык өлкәләренә таралып өлгергән бу афәт формация алышыну белән юкка чыкмады, киресенчә, тагын да киңрәк мәйданга таралды. Хәзер инде урлашу үзе бер батырлыкка әйләнде. Халкыбыздагы батырлык төшенчәсе дә астын өскә әйләндереп куелган баскыч хәленә төште. Әдипнең «Җимерелгән хыяллар» пьесасында бу проблема кискен куела. Үз теләге белән укып, очучы һөнәрен алган Мансурны Таулар иленә бомба яудырырга җибәрәләр һәм ул үзенә йөкләтелгән вазифаны шатланып, тырышып башкара. Нәтиҗәдә аңа Герой исеме бирелә. Ул бик горурланып сыйныфташлары белән очрашуга кайта. Ләкин элекке дуслары аны үз араларына кертмиләр. Чөнки ул әлеге исемне дошманга каршы сугышып түгел, ә тыныч халыкны, ирек сөйгән һәм шул үз иркен, үз азатлыгын саклау өчен көрәшкә күтәрелергә мәҗбүр булган халыкны юк итү, йортларын җимерү бәрабәренә алган. Мансур үзен-үзе атып үтерергә омтылып карый, ләкин пистолеты да аны тыңламый. Автор үзенең героен әнә шундый тетрәндергеч вакыйгалар аша гомерлек хурлык эчендә калдыра.

Әхлагыбыз бозылу «Яралы язмышлар» повестенда да калку сурәтләнә. Яңа гына туган нарасыен чүплеккә ыргыту яки аны тудыру йортында калдырып китү татар халкында гомердә булмаган хәл. Хәтта совет чорында да ятим сабыйларны гына балалар йортына урнаштырганнар. Хәзерге ялган демократияне халык теләсә нәрсә эшләргә ярый дип кабул итте. Шуның нәтиҗәсендә ата-аналы ятимнәр артты. Ф.Яруллинның бу повесте татар, рус һәм инглиз телләрендә басылып чыгуы белән укучылар контингентын һәм аның таралу географиясен янә киңәйтеп җибәрде. Бу әсәре белән Ф.Яруллин тагын бер кат әхлакый батырлыкның (Миңлегөл образы аша) сугыштагы яки хезмәттәге батырлыктан ким булмавын күрсәтте.

Күпкырлы талант иясе Ф.Яруллинның иҗади эшчәнлеге гади укучы ихтирамын гына яулап калмады, рәсми җитәкчелек тарафыннан да югары бәяләнде. Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен аңа Татарстан Республикасының «Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде (1984), ул Республиканың Муса Җәлил исемендәге комсомол (1978), Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә (1995) лаек булды, «Халыклар дуслыгы» ордены белән бүләкләнде (1988), «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мәртәбәгә ия булды (2001). «Восточный экспресс» газетасы уздырган анкета җавапларына нигезләнеп, «Парадигма» нәшрияты 2005 елда игълан иткән йөз мәшһүр татар арасында Ф.Яруллинның да булуы шагыйрь иҗатының кыйммәтен бәяләүче янә бер күрсәткеч булды.

Ф.Яруллинның укучыларга тәкъдим ителә торган өчтомлыгын 2004 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган сайланма биштомлыгына кермәгән әсәрләр тәшкил итә. Беренче томда поэмалар, шигырьләр, җырлар; икенче томда драма һәм проза әсәрләре; өченче томда балалар өчен язылган әкиятләр, повестьлар, хикәяләр.

Әдип соңгы елларда аеруча күп эшләгәнлектән, шигърияттән торган томга яңа әсәрләре генә кертелгән. Ләкин аның күпчелек әсәре вакытлы матбугатта дөнья күргән һәм укучылар хуплавын алган. Икенче томдагы «Кыйбласызлар» повесте да яңа һәм бүгенге көннең яраларын ачучы әсәр. Үз чорыңа бәя бирү авыр эш. Ф.Яруллин шушы авырлыктан курыкмыйча, геройсыз заманның «геройларын» сурәтли. Түбәнлеккә төшүнең сәбәпләрен ача. Ә инде өченче томдагы әкиятләр, балалар өчен иҗат ителгән хикәя-повестьлар һич икеләнмичә киң мәйдан укучыларына тәкъдим итәрлек.

Сайланма өчтомлыкка сүз башы буларак язылган мәкаләдә Ф.Яруллинның күпкырлы, киң масштаблы иҗатын иңләү мөмкин түгел. Аны фәнни нигездә өйрәнү — киләчәк эше. Бу мәкаләдә исә әдипнең күпкырлы иҗатчы буларак татар әдәбиятына керткән өлеше, стиль үзенчәлекләре, тасвирланган вакыйгаларның драматизмын сурәтләгәндә психологизм алымнарын оста файдалануы, табигать белән кеше арасында гармония булганда гына эстетик зәвыкны үстерерлек әсәрләр иҗат итәргә мөмкин булуы һәм әдипнең халык традицияләренә таянып, иҗатының һәр тармагында аларның тагын да үстерелүе күпмедер күрсәтелде. Ләкин әдип торган саен яңа яклары белән ачыла бара. Соңгы вакытларда ул нинди дә булса бер тема алып шигъри тупламнар иҗат итә башлады. «Чорлар күләгәсе», «Йокысызлар да кирәк», «Без табигать балалары», «Сөю бит ул картаюны белми», «Йөрәгендә бара күтәреп» һәм башкалар. Мондый тупламнарны шикләнмичә поэма дип атарга мөмкин. Чөнки аларда тема үстерелә, образлар яңа яклары белән ачыла һәм йомгаклау формасында тәмамлана.

Әдәбиятыбызның үткәне һәм киләчәге турында уйланып язылган мәкаләләре дә Ф.Яруллинның яшь буын турында кайгыртуын, әдәбиятыбызда буыннар чылбыры өзелмәскә, һәр чор үз проблемасын, үз йөзен, үз сулышын, үз тавышын калдырырга тиешлеген әйтә килә. Ышанып әйтергә була: бу олы шәхес һәм әдипнең сүзләре яшьләргә ишетелми калмас.

*Сәвия Хәкимова,*

филология фәннәре кандидаты

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

# Мәхәббәт — мәңгелек сер

*Мәхәббәт ул — изге нәрсә,*
*Иңдерелгән Алладан.*
*Башланган ул иң беренче*
*Адәм белән Хавадан.*

## НУРСӨЯ

*(Поэма)*

### I

Яфрак булып көннәр коелып тора,
Йолдыз булып еллар атыла.
Яшен ташы килеп бәрелә дә,
Гомер чүлмәгебез ватыла.

Күкрәкләре белән һава ертып
Очып бара күктә ике кош.
Алда әле күпме язлар, көзләр,
Алда әле күпме салкын кыш.
Канатларын җилләр каермасмы,
Яндырмасмы яшен утлары?
Карап торсаң, гади генә кошлар,
Очышлары нинди югары!

* * *

Сиңа атап күпме шигырь яздым,
Уйлар мең кат дөнья урады.
Ләкин синең күңел байлыгыңны
Ачар сүзләр табып булмады.
Никадәрле генә тырышсам да,
Шигырьләргә җаның сыймады.
Әле һаман сиңа әйтер өчен
Сүзләр эзлим, тыймыйм уйларны.
Алда ята өем-өем кәгазь,
Уйда — язылачак поэма.
Нигә һаман утың сүнми диеп,
Тәрәзәдән карый Ай гына.
Ут сүнмәсен әле өебездә,

Аксын әле тормыш бер көйгә.
Кыштыр-кыштыр өйдә син йөргәндә
Җанга рәхәт әле, Нурсөя.
Үз хатынын мактап яза, диеп
Әйтсә әйтсен, әйдә, кешеләр.
Ә мин язам әле, чөнки беләм:
Дөньяда юк синең төслеләр.
Син авыргач, әйбәт кешеләрне
Күңелемнән кат-кат санадым.
Кайгыларым белән күтәрерлек
Башка беркем югын аңладым.

**II**

Бездән алда уйлар йөри,
Хыялларны иялтеп.
Уй-хыяллар, ашкынулар
Ун гомергә җитәрлек.

Кичтем кара төн диңгезен,
Эчтем Айның яктысын.
Эзләдем сөю җимешен,
Аның да иң татлысын.
Йолдызлар чүеп уйнадым,
Чиксез күкләргә менеп.
Керфекләремнең очында
Яшеннәр торды биеп.
Ачылды күк капкалары,
Ак болытларда йөздем.
Таң нурларыннан яктырды
Минем сулышкан йөзем.
Өмет чаткылары сүнеп,
Карурманнарда калдым.
Яктыртыр өчен юлымны,
Йолдызлар үрелеп алдым.
Дәштем күкләргә баш чөеп,
Кайда, дип, минем парым?
Кем сыйдырыр йөрәгенә
Яралы бөркет җанын?!
Кем бар җирдә бу бөркеткә
Ныклы канат булырлык?
Чапты Вакыт ярсу аттай
Ашкынып, томырылып.
Күкләрдән җавап килмәде,
Сорасам да ничә кат.
Уйлагандыр Күк Хуҗасы —
Җавапны син үзең тап.
Мин сиңа зур язмыш бирдем,
Күтәрә алсаң күтәр.
Акыллы яр таба алсаң,
Хәлең җиңеләеп китәр.
Андый кешенең барлыгын
Йөрәгем белән тоеп
Карурманнарга йөгердем,
Учка чәчәкләр җыеп.
Ләкин минем чәчәкләрем
Яна башлады дөрләп.
Йөрәккә менде ялкыны
Тамырлар буйлап үрләп.
Уйладым: безнең мәхәббәт,
Ахры, бик гади булмас:
Ут булса — мәңге янар ул,

Гөл булса — мәңге сулмас.
Әйтте бер кош: үз парыңны
Эзләмә әллә кайдан.
Сикереп төшмәс ул яныңа
Кояштан яки Айдан.
Эзләгәнең Җир кызы ул,
Карап торсаң, бик гади.
Тик җаны белән бөек ул,
Йөрәге белән гали.
Аның сөюе алдында
Баш ияр Зөһрә, Ләйлә.
Кош булып очып керер ул
Өеңә берәр җәйдә.
Ачып куйдым тәрәзәмне,
Көтәм,
Тузына хисләр.
Агылып керә җаныма
Шомлы, караңгы кичләр.
Көтә-көтә арыймын да
Йоклап китәм саташып.
Ул соң әллә мине тапмый
Йөри микән адашып?
Мин дә эзлим, көтеп ятмыйм
Бәхет өйгә кергәнен.
Карурманнар кичкән чакта,
Сыйпап китәм гөлләрен.
Кул изим, чакырам аны,
Кычкырамын: мин монда!
Тавыш чыкмый, усал җилләр
Каплана минем тынга.
Ул гүзәл янына килеп
Җиттем генә дигәндә —
Уянып китәм үземнең
Күреп туйган бүлмәмдә.
Бәргәләнәм, өзгәләнәм,
Күкрәкләремне төям.
Өстемдәге албастыны
Алып еракка чөям.
Бутала көн белән төннәр,
Бутала төшләр, өннәр.
Ул булып күренә күземә
Белмимен әллә кемнәр.
Йә ул болытлар өстеннән
Миңа кул болгап китә,
Яки ак яулыгын җәеп
Күкне томанлы итә.
Ник уйный ул минем белән,
Ник килә дә югала?
Аның көмеш тавышы гына
Каеннарга урала.
Мин барам тавыш артыннан,
Тавышны булмый тотып.
Йөрим кара урманнарда
Төн пәрдәләрен ертып.
Аның тавышы әле күктә,
Әле җирдә тоела.
Яфраклардан шыбыр-шыбыр
Аның тавышы коела.
Әллә ул мине үртиме,
Шаярамы — кем белә?!

Тоттым дигән чакта гына,
Йокым шартлап өзелә.
Әйтерсең без Сак белән Сок,
Арада биек таулар.
Тауларны кичеп чыгарга
Төн җитми — ата таңнар.
Дәшәм тавыш иясенә:
Мин барыбер табармын.
Тауларга күп менгәнем бар,
Серен беләм тауларның.
Син ирекле урман кызы,
Мин дә коллардан түгел.
Ирекле урман кызына
Шар ачык минем күңел.
Кер әйдә һич тә курыкмый,
Ирегеңне чикләмәм.
Теләсәң, чыгып китәрсең,
Ишегемне бикләмәм.
Шулай диеп әйтүемә
Җанда кузгалды тартыш:
Ирек чикләнми буламы,
Кушылгач ике язмыш?!
Минем шушы сораудан соң
Күренде синең шәүләң.
Шәүләң дә синең ак иде,
Бик нурлы иде гәүдәң.
Иңнәреңдә ике толым
Чайкалып бара иде.
Синең баскан эзләреңдә
Гөл үсеп кала иде.
«Язмышларны бәйләп кенә
Чикләнәмени ирек? —
Кеше һәркайда ирекле,
Җанында булса хөрлек.
Синең эзләгәнне белеп
Килдем менә яныңа.
Сөю богау була алмас
Икебезнең җанына».
Шул сүзләрне әйттең дә син
Салдың телемә җиләк.
Җиләгең телдә эрүгә,
Әллә нишләде йөрәк.
Кердем утка, төштем суга,
Буталды әйтер сүзем.
Күңелеңдәге матурлыкны
Күрсәтә иде йөзең.

**III**

Зур язмышлар очрашканда,
Күкләр фатиха бирә.
Фәрештәләр теләк тели:
Мәңге яшәгез бергә.

Купты давыл,
Күкрәде күк,
Ялт-йолт итте утлары.
Ике йөрәк аша үтте
Бер үк яшен уклары.

Гүя күкләр икебезнең

Кавышуны телəде:
Бер дулкынга күчеп типте
Ике кеше йөрəге.
Аңламадык моны башта,
Аңлавы авыр иде.
Күзлəрдə яшен чаткысы,
Йөрəктə давыл иде.
Кушылды хислəр хислəргə,
Кушылды уйга уйлар.
Кушылды тавыш тавышка,
Кушылды җырга җырлар.
Беребез ут, беребез су,
Кирəк чакта су янды.
Сулар дөрлəп янган җирдə
Кышын язлар уянды.
Карлар чəчəк булып яуды,
Дөнья гөлгə күмелде.
Сукмакларыбыз, кушылып,
Мəңгелеккə үрелде.
Бəхетле булыр өчен соң
Кешегə күпме кирəк! —
Гомергə бəхетле итте
Син каптырган шул җилəк.

**IV**

Күп нəрсəне күреп бетермибез,
Томаланган күңел күзебез.
Пычрак итек белəн керəбез дə
Матурлыкны таптап йөрибез.
Матурлыкның җаны сыкрап кала,
Елап кала җирдə матурлык.
Гөллəр җыеп учак ягабыз бит,
Бер уйласаң, шаклар катырлык.
Уфтанабыз, ник без һаман ярлы,
Түрəлəрме талый халыкны?
Түрəлəр соң талый аламыни
Күңелебездə булган байлыкны?
Зарланабыз, без бəхетсез, диеп,
Ə бəхет ул тора мизгелдəн.
Мизгеллəрне кушып үлчəр өчен
Кирəк булыр иде зур бизмəн.

* * *

Лəкин əле күп нəрсəне
Үлчəр өчен үлчəү юк.
Йə, нəрсə белəн үлчəнə
Җаннардагы олылык?
Тугрылыкны үлчəргə дə
Əлегə үлчəүлəр юк.
Шуңа күрə бəялəнми
Олылык һəм тугрылык.
Күңелдəге матурлыкны
Кемнəр үлчəп караган?! —
Күплəр əле аера белми
Хəтта акны карадан.
Сабырлыкны үлчи торган
Үлчəү бармы — кем белə?
Сары алтын — сабырлыклар —

Тузаннарга күмелә.
Мәхәббәтне үлчи торган
Үлчәү бармы дөньяда?
Нинди хисләрдән йөрәктә
Зур мәхәббәт уяна?!

**V**

Мәхәббәтне табу җиңел,
Авыр ләкин саклавы.
Җиңел түгел гомер буе
Гел-гел бергә атлавы.

Әйттең миңа: бу йөрәктә
Башкаларга урын юк.
Яклаучым бул, саклаучым бул,
Калканым бул яуса ук.
Бирмә мине беркемгә дә,
Ят куллар үрелсә сук.
Мәхәббәтне бүлгәләргә
Беркемнең дә хакы юк.
Тибрәт сөю бишегеңдә
Моңлы сазларың белән.
Бәйлә мине йөрәгеңә
Кайнар назларың белән.
Гөлләр булып сокландыр да
Күңелемне хәйран ит.
Көзләремне язлар ит син,
Кышларымны җәйләр ит.
Бирмә мине беркемгә дә,
Бирмә хәтта үлемгә.
Сокландыр гел, ашкындыр гел,
Йолдызлар сип күңелгә.
Тик шулай тота алырсың
Йөрәк дигән оянда.
Ничек кенә яшәмә син —
Хөрлек ята һәр җанда.

**VI**

Бик сирәкләргә бирелә
Мәңге сөю-сөелү.
Юк монда батыр калулар,
Юк җиңү һәм җиңелү.

Матур яшәү — тирән сер ул,
Без төшендек шушы сергә.
Бөтенесен тигез бүлдек —
Яндык бергә, көйдек бергә.
Гел янәшә бардык җирдә.
Иелә белдек, бөгелә белдек,
Бер тәкәббер гөл булмадык.
Мәхәббәткә тезләнсәк тә,
Горурлардан ким булмадык,
Яндык, ләкин көл булмадык.
Ачу чыкса, ярсу чыкса,
Вакытында тыела белдек.
«Ярый әйттем», — диеп түгел,
Әйтмәгәнгә сөенә белдек.
Тыелалмасак, көенә белдек.
Күңелләрнең матурлыгын
Гомер буе ача белдек.

Гел биеккә менмәсәк тә,
Түбәнлектән кача белдек.
Бер үк эзгә баса белдек.
Эшебез белән, хисебез белән
Бер-беребезне гел зурладык.
Ә үзебез һичбер вакыт
Мәхәббәттән зур булмадык.
Бер-беребезгә кол булмадык.

**VII**

Баетып яшәсәң генә
Бер-береңнең күңелен,
Шиңдерми сакларга була
Гүзәл мәхәббәт гөлен.

Кулымда курай булдың син,
Күгемдә тургай булдың.
Баш очымда янып торган
Кояш белән Ай булдың.
Күңлемне аңлап тордың син,
Очканда, канат булдың.
Караңгыда калган чакта,
Яктырткыч маяк булдың.
Сусасам, коем булдың син,
Иң тәмле сыем булдың.
Газаплы да, бик татлы да
Мәңгелек уем булдың.
Кирәксә — яфрак булдың да,
Кирәксә — туфрак булдың.
Туфрак булган чакларда да
Күпләрдән зуррак булдың.
Кирәксә, гөлем булдың син,
Кирәксә, алым булдың.
Учка кыссаң, моң чыгарлык
Яралы җаным булдың.
Үзеңнең бар байлыгыңны
Күңелгә сала белдең.
Гайбәтнең буе җитмәде,
Биектә кала белдең.

**VIII**

Җирне җылытырга
Ут кирәк.
Җанны җылытырга —
Мәхәббәт.

Серле учак бар дөньяда,
Ул — гаилә учагы.
Бар аның дөрләгән чагы,
Бар тик пыскыган чагы.
Әгәр ул пыскый башласа,
Сүндермәс өчен аны,
Саласың пыскыган утка
Умырып алып җанны.
Терелә учак яңадан,
Ялкыны үрли күккә.
Хисләрнең кайнар дулкыны
Тамырлар аша үтә.
Яна башлыйсың көчәеп,
Шул учакка сыенып.
Барасың янар тауларның

Утларында коенып.
Ике йөрәктән ут алып
Учак яктык Айларга.
Без яккан учак яктысы
Төште әллә кайларга.
Йолдызлар кабызып йөрдек,
Мәхәббәт йолдызларын.
Очтык сөю канатында,
Сизми гомер узганын.

**IX**

Җырга, моңга, мәхәббәткә
Кирәк һәрчак биеклек.
Шуны аңлаганнар гына
Яши сөеп-сөелеп.

Очтык, очтык, чөнки безгә
Туктарга ярамады.
Очышта гына бәйләдек
Тәндәге яраларны.
Тауларга төшеп ял иттек
Кара төннәрдә генә.
Тузган каурыйларыбызны
Сиптек җилләргә генә.
Күпләр күзәтеп тордылар
Безнең очышыбызны.
Болытларга гына өрдек
Утлы сулышыбызны.
Аз булмады уйлаучылар,
Болар егылыр, диеп.
Йөкләре авыр, боларның
Тыны кысылыр, диеп.
Булмады түгел, еш булды
Сулыш кысылган көннәр.
Канатларга бозлар катты,
Искәндә салкын җилләр.
Бер-беребезгә тагын да нык
Сыендык андый чакта.
Икәү бергә очып кына
Җитә алдык максатка.
Ә максат безнең зур иде,
Саф иде безнең уйлар.
Күңелебез пычранмады,
Узсак та озын юллар.
Синең канатлар ныклыгы
Кими төшсә дә бүген,
Мин ышанам: бу бит әле
Очыштан туктау түгел.
Кырык язны каршыладык,
Кырык кышны озаттык.
Авыр чакта бер-беребезне
Юатырлык сүз таптык.
Яфрактай коелды көннәр,
Ә без кабат яңардык.
Йөрәкләрдә көч бар әле
Өр-яңадан янарлык.
Беләм, күпләр уйлыйлардыр:
Ниһаять, бу да сынды!
Сындырып буламыни соң
Бәгырьдән чыккан җырны.
Син күптән җырга әйләндең,

Ул җырга тик син ия.
Җырдан салынган һәйкәл син,
Урман кызы, Нурсөя.

*2006*

# ЙӨРӘК ТАВЫШЫ

*(Поэма)*

Сөю көтмәгәндә килде,
Әйтерсең кышкы яшен.
Шушы яшен учагында
Һаман җылынып яшим.

### I

Үкенү, зарлану түгел,
Бу — йөрәкнең тавышы.
Илаһи бер мәхәббәтнең
Җанда кабатланышы.
Читтә йөреп хәтеремне
Каплаган иде тузан —
Кайттым да Хәтер иленә,
Юллар яңартып узам.
Былбыллар сайрап озатмый,
Сайрар көннәре үткән.
Әллә нинди таныш караш
Күзәтә кебек читтән.
Таныш кырлар, таныш таулар,
Таныш бөтен тирәлек.
Оча еллар, мин барамын
Хәтеремә ияреп.
Чү, ниндидер җыр ишетелә,
Ниндидер таныш тавыш.
Эретә бөтен йөрәкне,
Ишетәмме әллә ялгыш?!
«Кашың кара, кашың кара,
Каралткангадыр инде;
Карыйм-карыйм, туя алмыйм,
Яраткангадыр инде».
Аның җыры. Шул җыр белән
Җаннарны өтә иде.
Турыбыздан үткән чакта,
Гел җырлап үтә иде.
Җыр юды хәтер тузанын,
Нур таралды бөркелеп.
Кулларына кояш тотып
Йөгереп килде бер егет.
Кояшын миңа сузды ул,
Бу, ди, минем йөрәгем.
Януыннан курыкмасаң,
Ал, ди, сиңа бирәмен.
Тәнем буйлап ут йөгерде,
Алмалар булып пештем.
Янган йөрәкне алырга
Җитмәде минем көчем.

### II

Үз-үземне артык сөйдем,
Әй яшьлек — тиле вакыт.
Яралап тордым җаныңны

Шуннан рәхәтлек татып.
Чакырганда чыкмый идем,
Син озак көтә идең.
Койма арасына чәчәк
Кыстырып китә идең.
Ул чәчәкне сеңлем табып
Алып керә дә өйгә,
Мине үртәп йөри башлый,
Чәчәкне үбә-үбә.
Мин күрмәмешкә салышам —
Янәсе, исең киткән!
Әй бу мәхәббәт дигәнең
Тик эгоизм икән.
Сеңлем чәчәкне бирә дә,
Мә, ди, теләсәң нишләт.
Минем горурлыгым бирми
Карарга хет бер иснәп.
Сеңлем чыгып киткәч кенә
Назлый идем мин аны.
Терелеп китә иде чәчәк,
Булгандыр ул да җанлы.
Уйлы идең, моңлы идең,
Сизгер иде зиһенең:
Минем яшерен уйларны да
Аңлый иде күңелең.
«Син олы бәхеткә лаек,
Син чибәрнең чибәре.
Каратачаксың әле син
Үзеңә әллә кемнәрне!
Синең өчен бик тар безнең
Авылның урамнары.
Диңгез артларында гына
Егетнең уңганнары.
Сиңа тиң булганнары!»
Шулай дидең, серләремне
Кайлардан белдең икән?
Күз алдыма сине китереп,
Уйлар йомгагын сүтәм.
Уйлар уратып йөртәләр
Мине синең тирәндә.
Юкса калган кебек идең
Түбәндә, бик тирәндә.
Күңелең синең бик бай иде
Хыялларга, хисләргә.
Мең төрле төс күрә идең
Кап-караңгы кичләрдә.
Күңелеңдә моң иде дә,
Телләреңдә җыр иде.
Үзем сиңа тартылсам да,
Кирелегем зур иде.
«Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә;
Айга менеп, түбән карап,
Сине күрәсем килә».
Вакытында күралмадым
Күңелеңнең байлыгын.
Бәхетлеләр аңлыймыни
Ни икәнен кайгының?!
Син минем өчен утларга
Әзер идең керергә.

Сиңа бәхет иде мине
Пәрдә аша күрү дә.
Бер сум акчаң юк чакта да
Син җаен таба идең:
Казаннан театр килсә,
Билетлар ала идең.
Миңа алган билетыңны
Ертып бетерә идем.
Үзем башка егет белән
Клубка керә идем.
И кыен булгандыр сиңа,
Ничек чыдадың икән?
Горур булып кала белдең,
Ничек сынмадың икән?
Өйгә кайткач елый идем
Кирелекләрем өчен.
Ләкин аларны җиңәргә
Һич җитми иде көчем.
Әллә бик горур идем мин,
Әллә тәкәббер идем.
Ул чагында үземә дә
Ачылмаган сер идем.
Яшьлек яшьнәде дә үтте,
Барсын соңлап аңладым:
Син «Сөям!» дигән чагында,
«Мин дә!» дия алмадым.
Мәхәббәт — Тәңре бүләге,
Баш тарттым шул бәхеттән.
Шунда үзем дә сизмәстән
Аерылдым яшьлектән.
Җырың гына калды бары,
Үтте дә китте вакыт:
«Серләремне сөйләр идем
Синең алдыңа ятып».
Юк шул, юк шул, бар да калды
Сөйләнмичә йөрәктә.
Сөйләнмәгән шул серләрең
Йөдәтә гел, йөдәтә.

**III**

Гамьнәрне ияртеп акты,
Туктап тормады вакыт.
Ниндидер әрнүле сагыш
Торды йөрәкне талкып.
Офыкларга йөгердем мин,
Болытларга үрелдем.
Үз хәлемне аңлый алмый,
Бер еладым, бер көлдем.
Ләкин мине гомрем буе
Интектерде бер сорау:
Нигә мин гел ялындырдым,
Нигә кыландым шулай?
Тәрәзәмә син чирткәндә,
Ник чыкмадым атылып?
Калсын иде бар дөньясы
Җимерелеп, ватылып.
Ә бит юкса исемеңне
Көнгә мең кабатладым.
Минме соң шашып сөймәдем,

Минме соң яратмадым?..
Минме соң утлы караштан
Наз алып очынмадым?
Минме соң синең җырыңа
Күңелдән кушылмадым?
Җан кош булып очканда да,
Һаман калдым тыелып.
Бер елый да алмадым бит
Күкрәгеңә сыенып.
Урамнардан җырлап үтсәң,
Йотылып тыңлый идем.
Эчемнән ләззәт кичереп,
Тавышсыз елый идем.
Әй ул йотылган яшьләрем,
Әй ул ярсыган йөрәк.
Уйлый идем: ул ирекле,
Ул миннән бәхетлерәк.
Мин — кыз бала. Әти-әни
Кочагында үскән гөл.
Авыл егетләре миңа,
Янәсе, һич тиң түгел.
Шушы караш, шушы фикер
Сеңдерелгән каныма.
Богау булып салынган ул
Чыныкмаган җаныма.
Әнкәйләр гел тукый торды:
Син авылда бердәнбер!
Мактау сүзе яшь күңелне
Тагы да үсендергәндер.
Көзге алларына бассам,
Киталмый тора идем.
Талдан нечкә билләремне
Йөз төрле бора идем.
Озын кара керфекләрем
Тезелеп тора иде;
Күп егетләр минем өчен
Өзелеп тора иде.
Болыт-болыт чәчләремнән
Нурлар тарала иде.
Зәңгәр күкләргә карасам,
Йолдыз ярала иде.
Авыл егетләре моны
Ничек бәяли алсын?!
Хан егете бармагында
Булырга тиеш алтын.
Тик нигә соң хан егете
Белми минем барлыкны?
Җиңелмени саклап тору
Мондый олы байлыкны!
Авыл егетләре ярый
Озаткалап куярга,
«Сөям!» дигәннәрен тыңлап,
Хисләрендә уйнарга.
Ә гомерлек яр итәргә
Асыл егетләр кирәк.
Килсен алар акбүз атта
Сине ерактан эзләп.
Күңелем сизә: асыл егет
Барыбер килми калмас.
Гүзәл гөл кайда үскәнен

Ишетми, белми калмас!

**IV**

Шулай уйлыйм, ә күңелгә
Син хуҗа һәм син хаким.
Сине бер көн күрми торсам,
Шатлык сүнә, җан ятим.
Чакырам-куам, үртим-көләм,
Әлләниләр кыланам.
«Багана синнән шәбрәк», — дип,
Баганага сыланам.
«Сиңа кияүгә чыгам», — дип
Әйтәм дә җитди төстә,
Син ышанып җиткәч кенә
Шаркылдыйм бөтен көчкә.
Артыгын соңлап булса да
Җавап таптым барсына:
Син түзгәнсең мин юләргә
Зур мәхәббәт хакына.
Татар акылы төштән соң шул,
Алдарак уйланмадым:
Син Таһирым булган чакта,
Мин Зөһрәң булалмадым.
Ә беркөн әйттеләр җилләр:
Очып китте бөркетең.
Тәкәбберлегең белән син
Бөркетеңне өркеттең.
Ул очып китте еракка,
Ә син хәзер ирекле.
Килер тиздән акбүз атта
Пәһлеван хан егете.
Бу хәбәрдән йөрәгемдә
Нидер шартлап өзелде.
Күләгәләр килеп сарды
Айдай якты йөземне.
Чумдым караңгы бушлыкка,
Белми вакыт чамасын.
Кем белгән сөю утында
Гомер буе янасын.
Кем белгән давыл ятканын
Синең яшь йөрәгеңдә.
Кем белгән юлың буласын
Йолдызлар тирәсендә.
Син миңа кагылмадың да,
Сафлыгымны сакладың.
Ә мин, юләр, ул чак моны
Куркаклык дип аңладым.
Син белгәнсең, мәхәббәтнең
Бөеклеге — сафлыкта.
Тыела алу — батырлык та,
Тыела алу — сафлык та.
«Өф!» итеп өреп очырды
Як-якка вакыт җиле.
Ике гашыйгын югалтты
Беркөнне яшьлек иле.

**V**

Күңелем иләс-миләс чакта

Килде мин көткән егет.
Кыяфәт шәп, әйтерсең лә
Кыядан төшкән бөркет.
Гәүдә төз, киемнәр ыспай,
Кыюлык та җитәрлек.
Алып менеп китәр кебек
Мине күккә күтәреп.
Хыялдагы хан егете,
Акбүз аты гына юк.
Күкрәгендә көче ташый,
Йөрәгендә — кыюлык.
Баштарак аны кусам да,
Соңнан җиңелә төштем.
Әллә ничек бик тиз генә
Язмыш белән килештем.
Ул егет акыл утырткан
Төпле белемле иде.
Сокланып каравын күрү
Миңа күңелле иде.
Яшь чагында, тиле чакта
Матурлык — иң зур байлык.
Сине гел мактап торсалар,
Шатлыктан булмый айнып.
Ул мине Айга, Кояшка,
Йолдызларга тиңләде;
Галәмгә менеп төшкәндәй,
Галәм серен сөйләде.
Белемле, чибәр егетне
Тыңлавы кызык иде.
Тик аны үрти алмадым,
Күңелем боек иде.
Гел янымда басып торды
Теге авыл егете.
Күрәсең, «кире кызыйдан»
Өзелмәгән өмете.
Ә бу егет бик ошады
Әти-әниләргә дә:
Тотындылар җайлап-майлап
Мине аңа димләргә.
Белем дисәң белеме бар,
Кесәсе дә бай кебек.
Күрче әнә, үзеңне гел
Тора бүләккә күмеп.
Юк дисәң дә, алданабыз,
Яратабыз бүләкне.
Белмибез, бүләк хакына
Сатабыз бит йөрәкне.
Йөрәгең белән сатыла
Мәңгелек мәхәббәтең.
Йөрәк урнында йөртәсең
Аның тик җәрәхәтен.

**VI**

Шунда никтер синең хакта
Аңа әйтә алмадым.
Хәер, син каядыр киттең,
Бер хәбәр дә салмадың.
Былбыл булып очар идем,
Бәлки, синең янына.

Шушы уйлар гел ут салып
Торды минем җаныма.
Юк, оча да алмас идем,
Бу соңрак килгән уйлар.
Тартты минем күңелемне
Билгесез ерак юллар.
Ашыктырды «хан егете»,
Мин үзем дә ашыктым.
Китеп бардым авылымнан,
Шушыдыр дип язмышым.
Нәкъ шул көнне син кайткансың
Акча эшләп туй өчен.
«Уф!» сөйли дә алмыйм хәтта,
Калмады һичбер көчем.
Акчаларың таптый-таптый
Тәгәрәп елагансың.
Аннан, соңгы җырың җырлап,
Авылны урагансың.
Син киткәнсең, җырың калган,
Йолдызларга эленеп.
Йөрим хәтер сукмагыннан,
Шул җырыңа күмелеп.
«Китеп бардың еракларга,
Ут төртеп йөрәгемә.
Сүндерә алмый ул утны
Давыллар, җилләр генә.
Ташкыннар алып киттеләр
Мәхәббәт күперләрен.
Югалттык матур чакларын
Давыллы гомерләрнең».

**VII**

Их бер көн алдан кайтсаң да,
Яки сизенсә йөрәк —
Сиңа таба чабар идем,
Туй күлмәгемне сөйрәп.
Миңа гел шулай тоела:
Уйнадык гел качышлы.
Уйный торгач, икебез дә
Юлын җуйды, ялгышты.
Очрашырбыз дип яшәдем,
Тотты бары шул өмет.
Һәммәсен җыйдым йөрәккә,
Елар чакларда көлеп.
Үткәндәге кайнар көннәр
Буып алса тыннарны —
Учлап-учлап суга сиптем
Иң-иң кайнар уйларны.
Акты сулар ярсып-ярсып,
Актылар үргә таба.
Кояш баеды һәр көнне,
Җанымда яна-яна.
Салават күпере суздым
Елгалардан тауларга.
Кавышырга юл булсын дип
Парын җуйган ярларга.
Кулъяулык чиктем матурлап,
Сайлап кына җепләрен.
Әйттем кошларга: бәйләгез

Аның канлы йөрәген.
Диңгез өстеннән очканда,
Кулъяулыгым югалган.
Канлы йөрәгең бәйләргә,
Ахры, насыйп булмагандыр,
Ахры, насыйп булмаган.

**VIII**

Язмышым кушуы белән
Кайларга илтмәсен юл,
Сорыйлар иде кешеләр:
— Күзләреңдә нинди моң?
Югалттыңмы әллә берәр
Бик кадерле кешеңне? —
Ятларга сер бирмәс өчен,
Кыса идем тешемне.
Яшәдем табынып шулай
Яшерен мәхәббәткә.
Җилләргә дә ачалмадым
Мин йөрәгемне хәтта.
Ләкин күзләрдәге моңны
Яшерсәм дә тирәнгә,
Күзләләр күрә иделәр
Хәтта балкып көлгәндә.
Булды юкса тормышымда
Кояшлы, якты көннәр.
Моңны таратмакчы булып
Карады әллә кемнәр.
Рәхмәт инде иремә дә,
Үзен гел тота белде:
Төрле сораулар яудырып
Актармады күңелне.
«Китәм, китәм!» — дигән чакта
Өзеп ике араны,
Тотып кала иде мине
Аның сөеп каравы.
Ә күзләрдәге моңнарны
Бик-бик төпкә яшердем:
Анда синең белән үткән
Иң саф, иң пакь яшьлегем.

**IX**

Күрсәм кошларның тезелеп
Киткәнен туган якка,
Әйтә идем: китерегез
Бер хәбәр аның хакта.
Кошлар әйтте: синең исем
Язылган анда ташка.
Укып үтәбез очканда
Һәр язны сезнең якка.
Озак торган минем исем,
Бик тирән уелганмы?
Әллә инде бик еш кына
Яңартып торылганмы?
Яңгырлар да юалмаган,
Ашамаган кояш та.
Язылган булгандыр, ахры,
Бик каты кыя ташка.
Кошлар очып килгән саен,

Сорый идем һаман да:
— Әйтегезче, минем исем
Бармы әле тауларда?
— Бар! Бар! — дип китәләр иде
Кошлар миңа һавадан.
Яшь кызга әйләнә идем
Шатлыгымнан яңадан.
Ә беркөнне исемемне
Укыдым Ай йөзеннән.
Әллә юләрләнәмме дип
Шикләндем үз-үземнән.
Әй бу ярсулы йөрәкнең
Юкка очынулары! —
Юып төшерә бер шатлык
Күпме борчылуларны.
Тиеп кенә киткән иде
Җырыңның бер канаты.
Яшьлек исен, яшьлек хисен
Өр-яңадан яңартты:
«Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, чәчәгем.
Сөямен сине, чәчәгем,
Юк сине онтачагым».

**X**

Еллар коштай очып үтте,
Кипте күздә яшьләрем.
Әйтәм сиңа: гомрем буе
Сине сөеп яшәдем.
Төшләремә керә идең
Ак күлмәк кигән килеш.
Син куасың, мин качамын,
Шулай уйныйбыз, имеш.
Чаптым, чаптым бертуктамый,
Карамый як-ягыма.
Мәхәббәтең килеп тотты,
Качсам да кая гына.
Хисләрең кайнар җил булып
Уралды билләремә.
Кояш-йөрәк учыма төште
Иң кара төннәремдә.
Ялвара идем Аллага:
Оныттыр шуны тизрәк.
Юкса читлегеннән чыгып
Очачак минем йөрәк.
Шулай диеп ялварсам да,
Килмәде онытасым.
Синнән хәбәрләр көттем мин,
Тартып куйса да кашым.

**XI**

Мәхәббәт күтәрде бүген
Исемем язылган тауга.
Икебез исемен бергә күрү
Әй рәхәт булды җанга.
Күңелдә булган юшкыннар
Эреде гүя рәшә.
Әйтерсең син дә торасың
Минем белән янәшә.

Әллә җил, әллә сулышың
Чәчләремә кагылды.
Сүнеп барган хәтер уты
Өр-яңадан кабынды.
...Син мине велосипедка
Утыртып йөртә идең.
Синең кап-кайнар сулышың
Муенны өтә иде.
Рәхәт иде дә ул сулыш,
Ул назның назы иде.
Дөнья гүяки тоташтан
Мәхәббәт язы иде.
Булмаса да бер үк суга
Ике мәртәбә кереп,
Була икән мәхәббәттә
Бер назга ике эреп.
Кабатлана бер үк нәрсә
Өр-яңа төсләр белән.
Кайта бәхетле мизгелләр
Өр-яңа хисләр белән.

**XII**

Тау башында басып тордым,
Үткәннәремне уйлап:
Таулар биек булсалар да,
Тәкәббер түгел, тыйнак.
Күтәреп торалар алар
Күкнең ничә катламын.
Ләкин көтми алар бер дә
Кемнәрнеңдер мактавын.
Монда киңлек, монда хөрлек,
Монда җанның балкышы.
Саклана гади ташларда
Күпме гашыйк язмышы.
Никадәрле киң күңелле,
Серле, хәтерле таулар:
Икебезне бер кочакка
Сыйдыра алган алар.
Карап тордым офыкларга,
Ургылып акты еллар.
Чалынып үтте колакка
Син җырлап үткән җырлар:
«Безнең авыл уртасыннан
Сулар ага ургылып:
Калырсың инде, калырсың
Күңелемдә нур булып.
Алларың булалмадым,
Гөлләрең булалмадым.
Гомерлеккә пар итәрлек
Тиңнәрең булалмадым».
Кошларда синең җырларың,
Колакта синең тавыш.
Болытлар булып агыла
Күңелемдәге сагыш.
Үзем дә аңлап җиткермим,
Йөрәкне нидер телә.
Йөрисе килә тауларда,
Иңнәрне куеп иңгә.
Хәер, бу бер хыял гына,

Атылган инде йолдыз.
Юк инде, күптән юк инде
Элекке тәкәббер кыз.

**XIII**

Төшкән чакта кулъяулыгым
Бәйләп куйдым кыяга.
Мәхәббәтнең бөеклеген
Сөйләсен ул дөньяга.
Соңгы сүзем: һәрбер кеше
Җан сөйгәненә барсын.
Таштагы безнең исемнәр
Бер дастан булып калсын.

*2005*

## СӨЮ БИТ УЛ КАРТАЮНЫ БЕЛМИ

*(Туплам)*

**I**

«Ярат!» диеп яраттырып булмый,
«Оныт!» диеп оныттырып булмый.
Янган йөрәкләрне изү ачып
Җилдән генә суыттырып булмый.
Очар кошны тыеп торып булмый,
Хисне учка җыеп торып булмый.
Мәхәббәтне яшереп калып булмый,
Бер чыбыктан учак ягып булмый.

**II**

Сине күрү белән, яз җилләре
Битләремә килеп бәрелде.
Моңа кадәр татылмаган бер наз
Сыйпап үтте минем тәнемне.
Әзер түгел идем мин бу язга,
Мин оныткан идем яз исен.
Уйлый идем: күңел ишекләре
Күптән ябык диеп наз өчен.
Хыял атларымны уятырга
Җитә калды керфек кагуың.
Тойдым кинәт йөрәк-учагымның
Өр-яңадан дөрләп януын.
Язгы җилдә тылсым көче бармы? —
Алып атты иңнән елларны.
Җан атылды күккә тургай булып,
Оныттырып сагыш-моңнарны.
Басып торам юллар беткән җирдә,
Яз җиленнән битне сыйпатып.
Әллә язгы җилдән, белмим нидән,
Күзләрдән яшь тама тып та тып.
Булмый аны сөртеп туктатып.

**III**

Еш кына шундый төш күрәм:
Мин бер бакчада, имеш.

Агачта, өске ботакта,
Үсә ят, матур җимеш.
Үрелергә тора кулым,
Гүя ул миңа тиеш.
Күрәм юкса: өзәр өчен
Өлгермәгән бу җимеш.
Нәфес-шайтан котырта бит:
Өз дә ал, торма куркып.
Син өзмәсәң, барыбер аны
Кошлар китәчәк чукып.
Буйсынып нәфес-шайтанга
Ыргылмак булам өскә.
Йөрәгемне учка кысып,
Тыелып торам көчкә.
Кайчак хәлсезләнеп бетәм,
Үземне тыя-тыя.
Җимеш, «төшәм-төшәм» диеп,
Җилдә тирбәлеп куя.
Бәлки, аның үзен тизрәк
Өздерәсе киләдер.
Минем кайнар учларымда
Өлгерәсе киләдер.
Юк әле, өзмим, ярамый,
Үссен әле җимешем.
Кичерәм эчемнән генә
Тыелу сөенечен.

**IV**

Йөзләреңә Ай нурлары кунган,
Гөлләр матурлыгы ягылган.
Күзләреңә төннәр каралыгы,
Күкләр серлелеге салынган.
Энҗе итеп җыеп алыр идем
Керфек очындагы нурларны.
Йолдыз итеп сибәр идек күккә
Кара төндә әнә шуларны.
Юк, кирәкми, киметәсем килми
Синең күзләрдәге серләрне.
Сокландырсын алар миннән башка
Тагын-тагын әллә кемнәрне.
Ачылып кына килгән Ай гөленә
Кагылырга әле иртәрәк.
Ачылсын ул җәйләр җылысыннан
Һәм балкысын, күзне иркәләп.

**V**

Язда түгел, җәйдә түгел,
Кышкы салкын буранда
Әллә нинди тиле бер хис
«Тибенеп» куйды җанда.
Сискәнеп китте бар тәнем,
Ниндидер хәбәр көтеп —
Исерткеч яз исе тоеп
Уянган аю кебек.
Һәм чынлап та хәбәр килде
Бер гүзәл кош сынында.
Әйтте ул: «Язлар китердем,
Ятма иренеп, чык монда.
Картайдым, дип, муртайдым, дип,

Үз-үзеңне алдама.
Синең һәрбер тамырыңда
Дөрли-дөрли ут яна».
Бу кошчыкның сүзләренә
Ышандым мин, ышандым.
Ак чәчәкләргә әйләнде
Ап-ак карлы кышларым.

**VI**

Сине онытыр өчен,
Карурманга киттем:
Баскан эзләремнән
Чишмә булып типтең.
Сине онытыр өчен,
Диңгезләргә чумдым:
Диңгез төпләрендә
Энҗе-мәрҗән булдың.
Сине онытыр өчен,
Кара төнгә качтым:
Күктә Ай булдың да
Төн капкасын ачтың.
Сине онытыр өчен,
Томаннарга кердем:
Ефәк яулыгыңны
Муеныма элдең.
Барсын эшләдем мин,
Сине онытыр өчен.
Җитми икән, җитми
Онытырга көчем.

**VII**

Картаер дип уйламагыз,
Вакыт юк картаерга.
Зөһрәләр булган урында
Әйләнәм мин Таһирга.
Ширин бар җирдә мин — Фәрһад,
Ләйлә булганда — Мәҗнүн.
Үз яшемне беләм, ләкин
Мәхәббәт белән яшь мин:
Сүнмәдем, сүрелмәдем һич,
Күп әле, күп кайнарлык.
Дәрт-дәрманым иң кимендә
Өч йөрәкне яуларлык.
Мактана дип санасагыз,
Әйдә, шулай санагыз.
Әмма артык якын килеп
Ялгыш үзегез янмагыз.

**VIII**

Айлар биек, айлар биек,
Баскычлар юк менәргә;
Җырларымнан баскыч үрәм
Озын кышкы төннәрдә.
Зөһрә кызның көянтәсен
Салам да иңнәремә,
Йөгерә-йөгерә сулар сибәм
Айдагы гөлләремә.

Ай нурларында коенам
Гөлләр белән бергәләп;
Онытыла бөтен кайгым,
Бәхетем була түгәрәк.
Айлар биек, айлар биек
Менә алмаганнарга.
Мәхәббәттән биек түгел
Йолдызлар да, айлар да.

**IX**

Чиксезлекнең ерак ноктасыннан
Карап тора кебек синең күзләр.
Яна-яна чиксезлеккә очам,
Сузылып кала арттан ап-ак эзләр.
Кисеп ташлыйм вакыт аермасын,
Башка монда вакыт үлчәмнәре.
Еллар кысмый синең күкрәгеңне,
Чиксезлекнең биек түшәмнәре.
Синең белән тигезләшер өчен,
Биеклектә эреп таралырмын.
Йолдыз җилләрендә җилгәрелеп,
Яшь-яшь булып кабат яралырмын.
Ә әлегә чиксезлекләр аша
Синең күзләр карый миңа таба.
Мин очамын офыкларны ертып,
Узган елларымны яга-яга.

**X**

Мин бер яңа чишмә ачтым,
Беркем белмәгән чишмә.
Аның суларын әлегә
Чәчәкләр генә эчә.
Сандугачлар коеналар
Бу чишмәнең суында.
Чишмәгә мактау, дан ява
Сандугачлар җырында:
«Чишмә, чишмә, дәртле моң бар
Синең агышларыңда.
Үз моңнарыңа кушкансың
Урман тавышларын да.
Җилләр тавышы, гөлләр тавышы —
Синең тавыш күптөрле.
Тамчыларың күккә сипсәң,
Балкый салават күпере.
Синдәге моң, синдәге дәрт
Безнең җаннарга сеңгән.
Үзең җирдән аксаң да син,
Тавышың күккә менгән».
Менә шундый чишмә таптым,
Гүзәл чишмә, саф чишмә.
Әлегә аның суларын
Тик гөлләр генә эчә.

**XI**

Әгәр дә мин синең яшьтә булсам,
Чыгып китәр идек болыннарга.
Җәйнең рәхәт, иркә йомшак җиле

Кереп тулар иде куеннарга.
Чабар иде гөлләр безгә каршы,
Бәхетле көн белән котлар өчен.
Таулар тартыр иде түбәсенә,
Безне биеклектә тотар өчен.
Ак болытлар ак кораблар булып
Алып китәр иде еракларга.
Акчарлаклар азык ташыр иде
Без утырган ап-ак корабларга.
Әгәр дә мин синең яшьтә булсам,
Турыгыздан җырлап үтәр идем.
Тәрәзәңнән чыгар идең дә син
Җырларыма ияреп китәр идең.
Әгәр дә мин синең яшьтә булсам,
Яулар идем сине зур көрәштә.
Юк, юк, сөю картаюны белми,
Без икебез әле бер үк яшьтә.

*2005*

## БҮГЕН, БӘЛКИ, НӘКЪ ШУЛ ВАКЫТТЫР

Уйларың күп синең, гамьнәрең күп,
Йөрисең гел чумып уйларга.
Әйдә әле, кара кайгыларың
Адаштырып кайтыйк урманда.

Кара каен булып үссен алар,
Кемдер кисәр, бәлки, утынга.
Уй-моңнардан җирдә һәрбер кеше
Тик үзенчә генә котыла.

Нәрсә генә булып үссәләр дә,
Урманнарда урын җитәрлек.
Кирәк булса, диңгез аръягына
Аждаһалар китәр күтәреп.

Йә убырлы карчык очрап куяр
Һич көтмәгән аулак җирдә бер.
Үги кызны сынагандай сынап,
Алтын-көмеш төяп җибәрер.

Әллә ниләр булып тора җирдә,
Могҗизалар барга ышаныйк.
Кайгыларны җилгә җилгәрик тә
Калыйк әле бераз бушанып.

Күңелләрдә урын барын күреп,
Кояш кереп аны яктыртыр.
Ишекләрне киереп ачып куйыйк,
Бүген, бәлки, нәкъ шул вакыттыр.

*2004*

* * *

*Нурсөягә*

Орчык кадәр генә калдың инде,
Тик йомгагың гына зурая.

Һәрбер көннең яңа мәшәкате
Орчыгыңа синең урала.
Хәлсезләнеп бара кулларың да,
Җитез бөтерелми орчыгың.
Уйлар арасына урала да
Юкка чыга кайчак җеп очың.
Хәтер төпкеленнән яшь чагыңны
Уйлар чыгаралар актарып.
Күзләреңнең яшел учагында
Якты нурлар ала шаярып.
Йөзләреңдә җыерчыклар языла,
Була әллә нинди бер мизгел.
Битләреңнән сыйпап үтеп китә
Яшьлегеңнән килгән җитез җил.
Тик бу мизгел бик тә кыска була,
Савыла башлый моңнар җеп булып.
Урап ала язмыш пәрәвезе,
Буламыни аннан котылып.
Көнне — төнгә, язны көзгә ялгап
Эрлисең син, туктап тормыйсың:
Орчыгыңа үз язмышың белән
Минем язмышны да урыйсың.
Синең орчык әгәр туктап калса
Бөтерелүдән көннең берендә —
Озакламас, шул ук бер мизгелдә
Өзелер минем гомер җебем дә.

*2004*

* * *

Бер-беребездән ераклаштык бугай,
Шулай тиешледер, ахыры.
Чәчәк тә бит биек үскән саен
Түбәндәрәк кала тамыры.

Бии-бии җилләр кубызына,
Тартыласың син гел югары.
Керфегеңдә чык тамчысы уйный,
Йөзләреңдә кояш нурлары.

Сабагыңа сандугачлар кунса,
Җырланмаган яңа җыр отып —
Сандугачка ияреп очмакчы син
Чәчәк икәнеңне онытып.

Очам диеп ләкин талпынганда,
Ачылганда күккә бар юллар —
Исеңә төшерә чәчәк икәнеңне
Җиргә ябышып үскән тамырлар.

Кинәт сиңа бик күңелсез була,
Йөзләреңә төшә күләгә.
Ә бит чәчәк булып туулар да
Сирәкләргә генә эләгә.

*2004*

* * *

Озын, авыр юлларны без
Бергә-бергә үттек.
Мәхәббәт законнарына
Төзәтмәләр керттек.

Элеккеге законнарны
Сыздык, боздык, ерттык.
Моңарчы беркем йөрмәгән
Үз юлыбызга чыктык.

Таптык та без, югалттык та —
Бөтенесе булды.
Тик кабатлап булмас инде
Яңадан бу юлны.

*2005*

* * *

Мин — Таһир,
Зөһрәмне эзләдем.
Мин — Мәҗнүн,
Ләйләмне эзләдем.
Югалттым юлларда,
Агыздым суларга
Яшьлекнең иң матур
Кояшлы көннәрен.
Ләйләдәй гүзәлнең,
Зөһрәдәй чибәрнең
Янымда икәнен белмәдем.

*2005*

## СИНЕҢ БЕЛӘН БӘЙЛӘП ЯЗМЫШЛАРНЫ

Ялгышларым бик күп булды минем,
Саный китсәм, җитмәс бармакларым.
Бер абынган түмгәккә дә абынып,
Ялгышларны шактый кабатладым.

Ялгышларга гел этәрә торды
Кешеләргә артык ышануым.
Үзем генә беләм, буш сүзләрнең
Җаннан суырып күпме көч алуын.

Кешеләрдән гел яхшылык эзләп
Ничә мәртәбәләр ялгышынды.
Бер баскычка гына менсәләр дә,
Дусларымның йөзе алышынды.

Утта янмый һәм суларда батмый
Бара алуым да ярамады.
Бәргәләнә-бәргәләнә йөрәк
Гомер буе бик әз канамады.

Бер нәрсәдә, шөкер, ялгышмадым,
Югалтмадым иң зур табышымны:
Барлык ялгышларны кечерәйттем мин,
Синең белән бәйләп язмышымны.

*2004*

## ЯКЫНДАГЫ БӘХЕТЕҢ

Эзлибез бәхетне еректан,
Сизмибез гомерләр үткәнен.
Белмибез бәхетнең иң зуры
Үзеңнең яныңда икәнен.

Иң гүзәл гөлләр дә ямь бирми,
Күзеңә күренми матурлык;
Хыяллар җилкетми йөрәкне,
Булмаса өеңдә татулык.

Барасы юлларың уңса да,
Эшләрең булса да мактарлык,
Кызыгын тапмыйсың тормышның,
Көтүчең булмаса шатланып.

Җылытмый кояшның нурлары,
Җилләрдә суына кочагың.
Тапмыйсың җаныңа җылылык,
Булмаса мәхәббәт учагың.

Менсәң дә биеккә-биеккә,
Тапсаң да патшалар тәхетен,
Кимсенеп кысылыр йөрәгең,
Булмаса гаилә бәхетең.

Юлларда арыгач, талчыккач,
Өеңә кайтулар әй рәхәт —
Чөнки син беләсең өеңдә
Елмаеп көткәнен Мәхәббәт.

*2005*

* * *

Керфекләрең арасыннан
Саркып таңнар ата.
Кояш йөрәгеңнән чыгып
Йөрәгеңдә бата.

Болыт-болыт чәчләреңә
Йолдыз нуры төшкән.
Күкнең бөтен матурлыгы
Гүя сиңа күчкән.

Йөзләреңнең балкышыннан
Туа җиргә көннәр.
Күзләреңнең карасына
Сыйган күпме серләр.

Ике кашың арасында
Сөю сукмагы бар.
Ул сукмактан уза алыр
Бары сиңа тиң яр.

Гүзәллекнең үзе булып
Тугансың син җиргә.
Сөеп һәм сөелеп яшә,
Кайгы күрмә бер дә.

*2004*

* * *

Кулъяулыкка күз нурыңнан
Пар кыңгырау чиккәнсең.
Пар кыңгырау — ике йөрәк,
Кушып әйбәт иткәнсең.

Бер кыңгырау чыңлаганда,
Икенчесе дә чыңлар.
Йөрәкнең берсе сызласа,
Икенчесе дә сызлар.

Пар кыңгырау — ике йөрәк,
Чыңласын да сызласын.
Сөеп-сөелеп үтсен гомер,
Заяларга узмасын.

*2004*

* * *

Алсу, Алсу!
Җанда язгы ташу.
Бу ташу бит синнән башланды.
Салмак кына агып яткан елга
Кинәт ярларына ташланды.
Ярсу агым уйнак дулкыннарны
Һаваларга кадәр күтәрде.
Болытларга кушылып акты елга,
Гүя кушты күккә җирләрне.

Офыкларда салават күпере балкып
Урап алды сихри матурлык.
Ул күпердә синең игезәктәй
Пәйда булды серле яктылык.

Мин үрелдем сиңа. Буй җитмәде,
Бу — хисләрне генә дөрләтте.
Һәм мин шунда күкрәгемнән алып
Сиңа таба аттым йөрәкне.

Инде бар да синең хөкемеңдә,
Инде бар да синең теләктә —
Йә ал аны кайнар учларыңа,
Йә басып кит минем йөрәккә.

*2004*

* * *

Тып-тып басып юлның ташларына,
Бер кыз үтеп бара урамнан.
Күзләренә күкләр төсе тулган,
Чәчләренә җилләр уралган.

Янып торган көләч йөзләрендә
Яз кояшы үпкән эзләр бар.
Сыгылмалы сылу сыннарында
Хисне назлый торган төсләр бар.

Карамаска ничек тырышсам да,
Әйләнәм дә карыйм шул якка.
Аяк тавышлары бер җыр булып
Ишетелә минем колакка.

Сүзсез генә мин дә җырлап барам,
Сүзләр артык мондый вакытта.
Сөенәмен җанны җырлатырлык
Гүзәл затлар җирдә барлыкка.

Тып-тып басып юлның ташларына,
Бер гүзәл кыз бара урамнан.
Якынаеп булмый гүзәл кызга,
Еллар аякларга уралган.

*2004*

* * *

Син минем белән мавыгып
Алган идең бераzга.
Сусаган чагың булгандыр,
Күрәсең, сөю-назга.

Хисләремнең чишмәсеннән
Назларым эчтең ятып.
Искә төшсә дә исертә,
Әй бу бәхетле вакыт.

Әй бу белеп алданулар,
Әй бу самими хисләр,
Әй бу өзелгән өметләр,
Әй бу өндәге төшләр!

Ник соң онтылмый берсе дә,
Ник бар да җанга якын?
Кайчан бу тиле йөрәккә
Баш булыр икән акыл?!

*2004*

* * *

Мин сиңа таба йөгерәм,
Син чабасың аңа.
Сиңа дигән чәчәкләрем
Учларымда яна.

Йөзләренә очкын чәчри,
Керфекләрем көйри.
Туктар идем, ниндидер көч
Сиңа таба сөйри.

Учлар пешә, йөзләр пешә,
Утлы гөлләр кулда.
Чәчәкләрне сиңа бирү —
Тик шул гына уйда.

Сукмакларны ялкын кисә,
Якынайсам сиңа.
Учымдагы чәчәкләрнең
Көлен сибәм юлга.

*2004*

## КИТТЕМ ӘЛЕ

Бер кыз минем һәр сүземне
Кирегә борып тора:
«Син матур!» — дим, ә ул миңа:
«Алдашма!» — дип тондыра.

«Синдәйләр юк бу дөньяда,
Син бердәнбер», — дисәм дә,
Ышанмыйча көлә башлый,
Санап мине исәргә.

Ярсыйм, шашам, бәргәләнәм,
Сикерәм үрле-кырлы.
Ничек итеп ышандырыйм
Шушы үз сүзле кызны.

Ачуымнан кайчак аны
Тукмап ташлыйсым килә.
Тукмап ташлау гына түгел,
Тотып ашыйсым килә.

Әйе, мин матур, дигәнче
Кыйнап торасым килә.
Кыйнап булса да сүземә
Ышандырасым килә.

Юк, юк, аңа моңа кадәр
Әйтелмәгән сүз кирәк.
Киттем әле, шул кызыйны
Сурәтләрлек сүз эзләп.

*2004*

* * *

Үрләрнең иң биегенә басып,
Ал яулыгың болгап җилләргә —
Омтыласың күкләр киңлегенә
Теләгәндәй очып китәргә.

Хыялларым белән урап алам
Сыгылмалы, нечкә билеңнән —
Алып китәм сине мәңгелеккә
Балачагың үткән илеңнән.

Илтеп куям таныш түгел җиргә,
Мәхәббәт һәм яшьлек иленә.
Килеп керү белән пар сандугач
Килеп кунар синең иңеңә.

Җырлап торыр алар сөю җырын,
Моңнар тулар синең җаныңа.
Чәчәкләрнең барлык төре булыр,
Теләгәнен сайлап ал гына.

Яшьлек иле ул — гүзәллек иле,
Анда ага кәүсәр чишмәсе.
Учларыңа алып аның суын,
Тәмләп кенә шуны эчәрсең.

Тамырларың буйлап ага башлар
Татылмаган серле кайнарлык.
Әйтсәң иде: монда үткән көннең
Һәр мизгелен бәхет санарлык.

*2004*

* * *

Әллә кайчан онытылган хисләр
Төшәләр дә кинәт исемә,
Бөтереп алып минем билләремнән
Ыргыталар ялкын эченә.

Яна башлыйм яшьлек дәрте белән,
Тамырларда ага ут-ялкын.
Карурманнар аша сикереп үтәм,
Айга тиеп китә канатым.

Очып барган кошлар төркеменә
Барып керәм ярып һаваны.
Хисләр яңгырында коендырып,
Гөлгә күмәм шәрә даланы.

Диңгезләрнең ярсу дулкыннарын
Хисләр уты белән сүндерәм.
Зур ташларны, җирдән умырып алып,
Таулар түбәсенә менгерәм.

Үз-үземне аңлый алмый башлыйм,
Аң-зиһенне тоташ ут ялмый.
Офыкларга барып тоташа ул,
Андый утка чикләр булалмый.

Әллә кайчан кичерелгән хисләр
Кабатланып тора гел шулай.
Ут сүнмәсен моның йөрәгендә,
Янсын әле, янсын, ди бугай.

*2004*

## КАРАШЛАРЫҢ АДАШТЫРА

Кояш чыга, кояш бата
Ике кашың арасына.
Мәхәббәтнең сере ята
Күзләреңнең карасында.

Керфегеңә кунган чыклар
Күзләремне камаштыра.
Карый алмыйм күзләреңә,
Карашларың адаштыра.

Таң нурлары җем-җем итә
Битләреңнең алмасында.
Карыймын да шул нурларга,
Коенам шатлык дәрьясында.

Иренең — чәчәк, шул чәчәккә
Чыклар булып кунар идем.
Әкрен-әкрен шунда сеңеп,
Мәңге юкка чыгар идем.

*2005*

* * *

Хатлар яза алмыйм, үпкәләмә,
Сөйләшәсе килә утырып.
Йөрәктәге хисләр өермәсен
Хатка буламыни сыйдырып?!

Хатлар яза алмыйм, үпкәләмә,
Авылның бит була мең күзе.
Укылыр да хатым, озын телләр
Меңгә төрләндерер бер сүзне.

Хатлар яза алмыйм, үпкәләмә,
Серләремне сөйлим җилләргә.
Җилләр синең тәрәзәңнән кереп
Иркәләрләр кара төннәрдә.

Хатлар яза алмыйм, үпкәләмә,
Хат язарга бармый кулларым.
Яшен булып күкрәрмен дә күктә,
Көтмәгәндә китереп сугармын.

Күкләр күкрәп яшен килгән чакта,
Барсын ташлап чык син урамга —
Танырмын да сиңа атылырмын,
Әзер булсаң әгәр шуңарга.

*2005*

## ТОРМЫШЫМНЫ МИНЕМ ЯЗ ИТТЕҢ

Ялгыш кына карап бер үттең,

Сөю гөлләренә су сиптең.
Шиңеп барган гөлләр терелде,
Сабаклары күккә үрелде.

Ялгыш кына карап бер үттең,
Күңелемне минем нур иттең.
Сүнеп барган шатлык чаткысын
Җанга сыялмаслык зур иттең.

Ялгыш кына карап бер үттең,
Гади тормышымны сер иттең.
Күңелемә тулган хисләрне
Төсләргә бай матур җыр иттең.

Ялгыш кына карап бер үттең,
Шәфәкъ нурларына ут төрттең.
Янды дөнья шәфәкъ утында,
Син дөньяма башка төс керттең.

Ялгыш кына карап бер үттең,
Сөю көткән җанга наз сиптең.
Калкып чыкты гүзәл чәчәкләр,
Тормышымны минем яз иттең.

*2005*

## БУЛМЫЙ КИЧЕРЕП

Кичереп була авыр кайгыларны,
Кичерүе булса да читен,
Кайгылардан өстен итә сине
Киләчәккә булган өметең.

Кемдер сине, батырырга теләп,
Упкыннарга таба этәрә.
Калкып чыккач кичерәсең аны,
Җиңүдән соң күңел нечкәрә.

Тормышта бит була төрле хәлләр:
Юлда ташлап китә юлдашың.
Карурманда юлны табар өчен,
Бер уч нуры җитә кояшның.

Кичерәсең тагын юлдашыңны,
Ташласа да авыр минутта.
Адашмыйча чыга алган кеше
Ул мәкерне инде онытa.

Саф кешенең күңеле олы була,
Кичерә ала хәтта ялганны.
Кичерә алуы белән бәхетле ул,
Кичерүе белән саф җанлы.

Бу дөньяда бары бер нәрсәне —
Хыянәтне булмый кичереп.
Мәхәббәттә булган хыянәтләр
Гел агуын тора эчереп.

*2005*

* * *

Уемда — син, җанымда — син,
Тутырдың бар дөньямны.
Синең исемеңне әйтеп
Уятам мин һәр таңны.

Синең күңелеңә охшатам
Чиста, киң офыкларны.
Офык читендә сакта мин,
Җибәрмим болытларны.

Ә анда төсләр дулкыны
Агыла да агыла.
Күк капкасы көнгә мең кат
Ачыла да ябыла.

Булсам да офык сакчысы,
Ирегеңне чикләмим.
Гүзәллеккә капка ачып,
Аны бер дә бикләмим.

Җыя күңелең барлык төсне,
Офыкның чикләре киң.
Йолдызда тамыр җәеп, син
Күкләрдә үскән бер гөл.

Төнге учак булып янып,
Күкләргә үрли уем.
Назларга телим дә гөлне
Күкләргә җитми буем.

*2005*

## СЕР

Гап-гади бер тауда
Ак мәрмәр кыя бар.
Ул кыя эчендә
Яшерен оя бар.
Белмибез ояда
Кайнаган тормышны.
Яшидер күк анда
Бик серле төн кошы.
Килә ул төннәрен
Тын гына кыяга.
Һәм чума тиз генә
Яшерен ояга.
Мәрмәр тау төн кошын
Көтәдер, күрәсең:
Чистарта, матурлый
Ул оя тирәсен.
Төн кошы — серле кош,
Серләр күп тормышта.
Кем күргән бу кошны
Һавада очышта?

Ул оя ниндирәк,
Үрелгән гөлдәнме?
Кыяны һәм кошны
Берәрсе күргәнме?
Сайрый ул төн кошы
Ниндирәк вакытта?
Ни өчен оясы
Төрелгән мамыкка?
Кытыклый күңелне
Менә шул серлелек.
Сер бетсә дөньяда,
Ни эзләр кешелек?

*2005*

* * *

*...гә*

Җәй алып килдең син җиргә,
Гөлләр төяп кочагыңа.
Күк йөзенә йолдыз сиптең,
Чумырып алып учларыңа.

Ул йолдызлар кемнәрнеңдер
Нур сипкәндер йөзләренә,
Йә төшкәндер энҗе булып
Гашыйкларның эзләренә.

Май аеның серле төне
Салган сине бишегеңә
Һәм газаплы олы сөю
Биргән синең өлешеңә.

Эленгән ап-ак бишегең
Айның ныклы ыргагына.
Кулың сузсаң, зәңгәр күктән
Нур коела кулларыңа.

Ул нурларны, йомарлап, син
Ыргытасың төн эченә.
Нур йомгагы тияр беркөн
Бәхетленең өлешенә.

*2005*

## ӘЙТЕР ИДЕМ

Беркем коенмаган бер күл эзлим,
Саф суында килә коенасым.
Арып-талып суда коенып туйгач,
Ярларына чыгып егыласым.

Тирән күлләр тып-тын күренсә дә,
Ия алар бер тылсымлы көчкә.
Шул тылсымның сихри көче сине

Сиздермичә генә суыра эчкә.

Мин күл эзлим бер коеныр өчен,
Тик Ай гына йөзгән тирән күлне.
Якты Айга карап йөзәр идем
Куркытмаска тырышып җәйге төнне.

Кайда ул күл — кара урмандамы,
Сәхрәләрдә — кайнар комнардамы?
Әллә инде болын-кырлардамы,
Әллә бары хыял-уйлардамы?

Беркем коенмаган серле күлдә,
Җиргә йолдыз яуган чакта төндә,
Чистарынып, бер сафланып чыксам,
Әйтер идем: әзер мин үлемгә.

*2005*

## ЯРАТТЫРДЫМ

Башка берничек тә түгел,
Яратып яраттырдым.
Кирәк чакта тургай булып
Күкләрдә сайрап тордым.

Агымсулар булып актым,
Кермәсме дип йөзәргә.
Әверелдем чәчәкләргә,
Үрелсен дип өзәргә.

Салават күпере булып
Офыкларга элендем.
Сокланган карашын күрсәм,
Чын күңелдән сөендем.

Диңгезләр булып ярсыдым,
Дулкыннар булып чаптым.
Йомшак җилләргә кушылып
Якты моң булып актым.

Хисләрем янар тау иде,
Туктаусыз кайнап тордым.
Ялынып түгел, табынып түгел,
Яратып яраттырдым.

*2005*

## ӘЙТЕРСЕҢ СИН

Чәчәк атмас инде дигән идем,
Чәчәк аткан әле карт юкәм.
Тәрәзәмә бәрелә чәчәкләре,
Сөендерим әле ди микән.

Саргылт чәчәкләргә карыймын да,

Сөенечтән күзләр яшьләнә:
Димәк, әле синең белән, юкәм,
Яшәргә дә безгә, яшәргә.

Күкрәгемә чәчәк исе тула,
Тәрәзәне ачып җибәрсәм.
Чәчәкләрнең хуш исләре белән
Үпкәләрне һәр көн җилләтәм.

Һәм яшәреп киткән кебек булам
Юкәләрнең йомшак исеннән.
Һәр чәчәген үбеп чыгар идем,
Килсә бу эш минем көчемнән.

Рәхмәт, юкәм, чәчәкләрең өчен,
Йомшак назың өчен мең рәхмәт.
Әйтерсең син юкә генә түгел,
Җирдән үсеп чыккан Мәхәббәт.

*2005*

## БОЛЫННАР БУЛЫРЛАР ЧӘЧӘКЛЕ

Чәчебез чәчләргә бәйләнгән,
Башыбыз сөюдән әйләнгән.
Нигә соң, нигә соң куркабыз
Язмышны язмышка бәйләүдән?

Тормышның һәр көне — зур байлык,
Байлыкны кадерлик, югалтмыйк.
Гөл булып үсик тә тауларда,
Тирбәлик төннәрен айларда.

Йолдызлар сибәрбез юлларга,
Гашыйклар чыгарлар җыярга.
Дөньяны матурлап бизәрбез
Гаҗәеп тылсымлы нурларга.

Болыннар булырлар чәчәкле,
Аланнар булырлар җиләкле.
Эләрбез күкләрнең түренә
Сөюдән тулышкан йөрәкне.

*2005*

* * *

Тау башында басып тора идем,
Бит очымнан яшен чеметеп алды.
Яшен бик тиз шаярды да качты,
Ә битемдә уелып бер эз калды.

Күпме кызлар шулай шаярдылар,
Битне түгел, чеметеп йөрәгемне.
Санап кына бетерерлекмени
Сөю уты салган «миңнәремне».

*2005*

* * *

Синең белән очрашырмын диеп
Итми идем өмет.
Аккош булып очып киткән идең,
Күккә каурый элеп.

Серле каурый синең хәлләреңне
Тора иде сөйләп:
Нурлар сибеп торса як-якка ул,
Хәлең әйбәт, димәк.

Кайчагында тама иде аннан
Кара салкын тамчы.
Ул тамчылар була иде бик тә
Авыр, тозлы, ачы.

Җилле көндә ул каурыйны читкә
Очыра иде җилләр.
Булгандыр ул, бәлки, үз-үзеңне
Табалмаган көннәр.

Ә беркөнне бу ак каурый
Яшеннәрдә янды.
Салкын тамчыга ияреп,
Көле битемә тамды.
Хәбәрчебез булып безнең
Күктә кояш калды.

*2005*

* * *

Әйләнәсең дә киләсең
Хәтерем юлларыннан.
Үтәсең, чиләкләр асып,
Агымсу буйларыннан.

Чиләкләреңдә чайкала
Әллә су, әллә моңнар —
Сулар түгел, моңнар түгел,
Чайкала бугай еллар.

Сибелә көннәр тамчы булып,
Сибелә дә түгелә.
Агымсулар борыла-сарыла
Офыкларга күмелә.

Син һаман хәтер юлыннан
Киләсең миңа таба.
Якыная башладыңмы —
Ай күрә, кояш ала.

Әйләнәсең дә киләсең,
Чыңлый чиләкләр генә.
Йолдызлар коела күктән
Зәңгәр чиләкләреңә.

*2005*

* * *

Искиткеч бер чәчәк үсә
Гади генә бакчада.
Мондый чәчәк сатылмыйдыр
Хәтта бик күп акчага.

Дөнья тора шаккатырып:
Гүзәллекнең юк чиге.
Көн дә карыйм бу чәчәккә,
Исәнме һәр керфеге?!

Екмаганмы җил-давыллар,
Тимәгәнме кыраулар?
Һәр көн мине интектерә
Менә шундый сораулар.

Торган саен матурланды
Минем бәхет чәчәгем.
Мин аны беркемгә әйтми,
Зур сер итеп яшәдем.

Беркөн килсәм — ул чәчәгем
Юк иде урынында.
Салкын җилләр туй ясады
Ул көнне куенымда.

Гел шулай, бәхет гөлемне
Йолка да ала кемдер:
Әллә үзем озак уйлыйм,
Әллә башкалар өлгер.
*2005*

* * *

Күктә без кабызган йолдыз
Күптән инде сүнгән.
Яшьлекнең яшел сукмагын
Башка эзләр күмгән.

Сөюнең шаһиты — Ай да
Хәтерләми безне.
Элеккечә көләч түгел,
Боек аның йөзе.

Арабызда калкып чыккан
Текә-текә таулар.
Шул таулар артында калган
Без кабызган таңнар.

Очырган төрле тарафка
Безне вакыт җиле.
Арага җилләр керде дип
Гаеплик соң кемне?

Сайрар кошлар да киткәннәр
Еракларга очып.

Шаулы мәхәббәт илендә
Бүген тып-тын бушлык.

Көтүче чыбыркысы да
Шартлап куймый хәтта.
Ябылган, ныклап ябылган
Без керәсе капка.
*2005*

## КҮҢЕЛ ПӘРДӘЛӘРЕН КҮТӘРЕП

Минем өчен барлык кызлар матур,
Ямьсезләре булса арада,
Болын гөлләреннән төсләр җыеп,
Матурлыклар сибәм аларга.

Һәрберсенә: «Син иң гүзәл!» — димен,
Нык ышанып әйтәм үземә.
Күңелләрдә яткан матурлыклар
Чыга шунда кызлар йөзенә.

Бер сокланып карасаң да кайчак,
Очкын кабына кызлар күзендә.
Бит очлары алма булып пешә,
Шаккатасың хәтта үзең дә.

Һәрбер кеше тик үзенчә матур,
Матурлык ул җирдә җитәрлек.
Аны бары күрсәтергә кирәк,
Күңел пәрдәләрен күтәреп.

*2005*

## ЯЗ КОЯШЫ

Язны һәркем көтеп ала,
Яз кояшы тансык.
Куябыз яз кояшына
Тәнебезне ачып.

Ап-ак тәннәр, йомшак тәннәр
Тәгәриләр комда.
Әле уңга борыла алар,
Әле сулга.

Ә кояш ап-ак тәннәргә
Әкрен генә сеңә.
Талларга элгән күлмәкләр
Җилфердиләр җилдә.

*2005*

* * *

Әллә артык матур идең,
Никтер сине яраттым.
Синең өчен сугыша-сугыша
Күпме борын канаттым.
Күпме якалар ертылды,
Өзелде күпме җиңнәр.

Капка төбегездә узды
Күпме йокысыз төннәр.
Беләкләрдә ул чагында
Көч бар иде җитәрлек.
Алып китә ала идем
Өегез белән күтәреп.
Синең өчен гөлләр өздем
Чәчәкле бакчалардан.
Юлым койма аша булды,
Йөрмәдем капкалардан.
Морҗагыз аша төшеп тә
Урларга була иде.
Язмышың белән төрлечә
Уйнарга була иде.
Урламадым, уйнамадым,
Хисләр артык пакь иде.
Йодрыгым каты булса да,
Йөрәгем йомшак иде.
Давыл булып үтте яшьлек.
Давыл эзсез узамы?
Күмде яшьлегебез эзен
Давылларның бураны.

*2005*

* * *

Күп хатын-кыз үз-үзенә
Көн саен гашыйк була.
Андыйларның йөрәгеннән
Дәртле наз ташып тора.

Дөньяга да карый алар
Алсу күзлекләр аша.
Һәм дөнья да гашыйкларга
Бар матурлыгын ача.

Күкләр якты, йөзләр көләч,
Һәр агачта былбыллар.
Сөю-сөелү турында
Агыла якты моңнар.

Үз-үзенә гашыйк кызлар
Булсын әйдә, күп булсын.
Аларның йөз яктылыгы
Башкаларга да кунсын.

Үз матурлыгыңны күрү
Күңел күзләрен ача.
Үзеңне сөйгәндәй сөйсәң,
Дөнья матур лабаса.
*2005*

## ШАЯРУ

Бер кыз мине һич яратмый,

Нишләргә дә белгән юк.
Әллә егылып үлим микән,
Юкса күптән кызлар өчен
Егылган юк, үлгән юк.

Пожалуй, шулай итәрмен,
Ләкин ничек үләргә:
Кыядан сикерер идем,
Кирәк тауга менәргә.

Агымсуга чумар идем,
Бик салкындыр сулары.
Дер-дер калтырап ятармын,
Котны ала шулары.

Ул кызны әле күргән юк,
Тик беләм — ул бик чибәр.
Очрашсак, бәлки, чибәркәй
Мине күрү шатлыгыннан
Үзе тәгәрәп үләр.

*2005*

## АУЧЫ

Чибәр кыз бара урамнан,
Бик горур гына басып.
Аның һәр чәч бөртегеннән
Матурлык тора ташып.

Үкчәләре асфальт юлны
Тишәм-тишәм дип бара.
Түшендәге «алмалары»
Төшәм-төшәм дип бара.

Артта ике «тәлинкәсе»
Баралар биеп-биеп.
Тәлинкәләргә байлыкны
Салганнар өеп-өеп.

Аяклар — алтын багана,
Озыннар һәм төп-төзләр:
Теләсәң-теләмәсәң дә,
Шуларга төшә күзләр.

Ә кыз бара, әйтерсең ул
Урамга юри чыккан.
Җитмәсә әле, кулына
Бер нәни көзге тоткан.

Туктап карап алгалый ул
Кулындагы көзгегә.
Сөенеп куя: күпме байлык
Йөртә бит ул үзендә.

Көзге әйтә: сиңа тиңнәр
Юк әле, юк, гүзәлем.
Ә син бар, тукталып калма,
Юлда булсын күзләрең.

Бу дөньяда һәркем аучы,
Киек эзли һәммәбез.
Тик кораллар гына башка,
Һәм төрлечә хәйләбез.

Гүзәл кыз бара урамнан,
Юктыр кебек бер гаме.
Озын керфекләр каплый шул
Күзләрдәге ятьмәне.

*2005*

## ЯШЬЛЕК УЛ — ЯШЕЛ ҖИМЕШ

Яшьлектә бар да килешә,
Хәтта бераз юләрлек.
Булсын кайчак үткәннәрдән
Бер кычкырып көләрлек.

Каршы килмик, чабып барыйк,
Мәхәббәтне күтәрмик.
Шатлыктан күзләр чыланса,
Сөйгәннәрдән сөрттерик.

Йөрәкләрне күккә чөеп,
Яшен ташы иттерик.
Сөю юлын озынайтыйк,
Айга кадәр җиткерик.

Батырсалар, өскә калкыйк,
Батыручыга тотынып.
Яшьлек бит ул — яшел җимеш,
Яшьлек тик бер йотымлык.

Кайнар мәхәббәткә сусап,
Иреннәрне киптермик.
Бакчабызда гөлләр үссен,
Күбрәк су сиптерик.
Яшьлекнең яшел җимешен
Сусыл җимеш иттерик.

*2005*

* * *

Гомеремнең моңсу бер чорында
Көтмәгәндә сиңа юлыктым.
Ак болытлар алды моңсулыкны,
Сагыш барын җирдә онытылым.
Аҗаганнар булып төннәр янды,
Баш очыннан йолдыз атылды.
Зың-зың итеп куйды йөрәк сазым,
Кыллар булып хисләр тартылды.
Гомеремнең моңсу бер чорында,
Кимеп барган чакта егәрлек,
Торып бастым да мин пәһлевандай,
Күк гөмбәзен тордым күтәреп.
Күк гөмбәзен чөеп уйнадым мин,
Ай-йолдызлар куйды чайкалып.

Зөһрә кызның көянтәсен алып,
Су ташыштым аңа шатланып.
Битләремнән үбеп алды Зөһрә,
Сыйпап китте битне Ай җиле.
Миннән бәхетлерәк бер кеше дә
Булмагандыр җирдә ул көнне.
Хыял атым кешнәп куйды кинәт,
Тотын, диде, минем ялыма.
Ялындырып тормадым мин һич тә,
Урап тоттым ялын кулыма.
Тау-ташларны сикереп кенә уздым,
Болытлардан яшен кабыздым.
Мәхәббәте сүнгән йөрәкләргә
Яшен тамчылары тамыздым.
Гомеремнең моңсу мизгелендә
Көтмәгәндә сиңа юлыктым.
Мин дөньяда картлык барлыгын да,
Үлем барлыгын да оныттым.

*2006*

* * *

Арабызда чиксезлекләр ята,
Вакыт томанына төренеп.
Чәчәк булсаң, ерак еллар аша
Өзеп алыр идем үрелеп.

Ярсу диңгездәге дулкын булсаң,
Йөзеп китәр идем каршыңа.
Чөйсен дулкын ташлы кыяларга,
Түзәр идем барсы-барсына.

Вулкан булсаң, янар тауга менеп
Басар идем иң кайнар җиргә.
Эрер идем янар таулар белән,
Һәм кушылыр идек без бергә.

*2006*

## ӘЛИНӘГӘ

Әле кайчан гына син бит
Нәп-нәни кызчык идең.
Гомер җебе уралмаган
Гап-гади орчык идең.

Ни арада үскәнсең дә,
Ни арада җиткәнсең;
Син бит хәзер чәчәк аткан
Алмагачтай икәнсең!

Күзләреңдә кояш нуры,
Битләрең пешкән алма.
Карыйм да сиңа сокланып,
Әйтәмен: сөбханалла!

*2006*

* * *

Нигәдер шулай тоела:
Язын кошлар килгәндә,
Туктап ял итәрләр кебек
Кунып минем иңнәргә.

Беләм юкса, кошлар юлы
Биектә, бик биектә.
Кошларга тидерә алмам
Йомарлап кар чөеп тә.

Очкан инде безнең кошлар
Күптәнге язлар белән.
Хисләр аккан ташкыннарда,
Ургылып, бозлар белән.

Ә шулай да борыннарга
Килеп керсә яз исе —
Кызулый башлый йөзләтә
Йөрәкләрнең тибеше.

Яз исен бер сулау белән
Үзгәрә бөтен халәт.
Былбыл булып сайрый башлый
Тәндәге һәр күзәнәк.

*2006*

## СЕЗГӘ

Сез әле яшь кызлар кебек:
Зифа буй, утлы караш.
Сезнең йөзегезгә үзе
Яктылык салган кояш.

Яратыр өчен яралган
Сыгылып торган гәүдә.
Карыймын да әйтеп куям:
— Йә Алла, Ходавәндә!

Сез әле теләсә кемнең
Уйларын чуалтырлык.
Уйларын чуалтырлык та,
Башларын югалтырлык.

*2006*

* * *

Сулышыма утлар капты — янмадым,
Иңгә таулар авып төште — аумадым.
Калдым диңгез эчләрендә — батмадым,
Бөтереп алды агымсулар — акмадым.

Үргә үрләп күпме борын канаттым,
Учларымда карлы бозлар кайнаттым.
Син булганга, яраттырып яраттым,
Кешеләрдән үз-үземне санлаттым.

Рәхмәт сиңа, гөлчәчәкләр сайлаттың,
Җан сөйгәнне мин үземә караттым.
Син булганга, олы итте үз халкым,
Мәңге бергә яшик әле, талантым.

Кирәк икән — булырсың син канатым,
Кирәк икән — булырсың син пар атым.
Әгәр инде әҗәл алса җанымны,
Минем өчен син калырсың, талантым.

*2006*

## ЕЛМАЙ, ӘЙДӘ

*Люциягә*

Джоконда елмаюы кебек,
Елмаюың синең бик серле.
Шушы серне ачар өчен генә,
Мин җәлләмәс идем гомерне.

Күкрәгеңнән бәреп чыга да ул
Керфегеңә еленә нур булып.
Күз сирпесәң, шул елмаю нуры
Чыга башлый тышка ургылып.

Коенамын шушы серле нурда,
Коенгандай кәүсәр суында.
Өр-яңадан яшьлегемә кайтып,
Гөлләр җыям сиңа болында.

Синең елмаюга торырлыгын
Таба алмыйм ләкин гөлләрнең.
Абагалар чәчәк атар диеп,
Урманнарга барам төннәрен.

Ә син һаман серле елмаясың,
Серен ача алмыйм мин аның.
Елмай, әйдә, елмай, кагылмасын
Кайгылары сиңа дөньяның.

*2006*

## СҮЗСЕЗ ҖЫР

Керфекләрең арасыннан
Агыла якты нурлар.
Нурлар түгел, дулкын-дулкын
Агыла сүзсез җырлар.

Тыңлыйм шул сүзсез җырларны,
Күңел күкләргә аша.
Хисләр яшен булып уйный,
Күк белән җир тоташа.

Сандугачлар туктап кала
Сайрауларыннан кинәт.

Җыр дулкыннарына көйли
Үзенең тибешен йөрәк.

Бу халәт — бары бер мизгел,
Үтеп китә тиз генә.
Күк капкасын җилләр яба,
Сүзсез җырым өзелә.

*2006*

* * *

Матурлыгын белми йөргән кызлар сирәк,
Тик аларга «син матур» дип тору кирәк.
Күрә алсаң әгәр күңел байлыгын да,
Булып китә алар тагы да чибәррәк.

Сүз — күзләргә нурлар булып тула ала,
Сүз — йөзләргә шатлык булып куна ала.
Сүз көчлерәк бөтен төрле дарулардан,
Сүз коткара хәтта каты авырулардан.

Һәрбер кызга «син чибәр», дип әйтеп торсак,
Сүзебезгә аларны без ышандырсак,
Ямьсезләр дә чибәрләнеп китәчәкләр —
Ямьсез була аламыни гөл-чәчәкләр?!

*2006*

* * *

Хисләр давылында оча яфрак,
Бер югары менә, бер төшә.
Оча ала икән, очсын әйдә,
Яфракка да очу килешә.

Кем белә бит, бәлки, аны давыл
Болытларга кадәр күтәрер.
Юкка гына кошлар очамыни?! —
Җир гүзәл дә, ләкин күктә сер.

Оча яфрак хисләр давылында,
Ак болытлар аны тибрәтә.
Югарырак менгән саен, яфрак
Ошый бара ярсу йөрәккә.

*2006*

**ИКЕНЧЕ БҮЛЕК**

# Гомернең мизгелләре

*Каләм очына уралган*
*Тормышның бар кылы.*
*Шул кылларда үз җырымны*
*Уйныйм гомрем буе.*

## ЧОРЛАР КҮЛӘГӘСЕ

*(Туплам)*

### I

Даһиларның күләгәсе озын,
Кәрлә булсалар да үзләре:
Гасырлардан гасырларга сузыла
Канлы күләгәле эзләре.
Ул эзләрне яңгыр юа алмый,
«Ашый» алмый хәтта кояш та.
Канлы күләгәдән бөрешеп кала
Биек тауда яткан ак таш та.
Күләгәләр эзен
Йөрәк каны белән
Гали затлар күпме юганнар.
Шәһит киткәннәрнең сөягеннән
Калкып чыккан таулар — курганнар.
Хәтер аланына якты төшми,
Күләгәләр анда мәңгелек.
Яктыртырга теләп бу дөньяны
Шәһит киткәннәрнең йөри җаны,
Күңел күкләренә шәм элеп.

### II

Утырткannар, онытканнар
Бер биек баганаы.
Ни өчен һәм кем утырткан? —
Һич белүче юк аны.
Ул инде озак утырып
Тәмам каралып беткән.
Башына каргалар куныд,
Аны «яратып» киткән.
Ә багана бик тә горур,
Гүя дөнья кендеге.
Иң зур горурлыгы аның —
Әнә шул биеклеге.
Күләгәм нинди озын, дип
Мактана бу багана.
Чөнки бердәнбер багана
Ул шәп-шәрә далада.
Мәгънәсезлеккә һәйкәлдәй
Тора кара багана.
Ни өчендер яшеннәр дә
Кагылмыйлар аңарга,

Хәер, мондый баганалар
Утыртыла һаман да.

**III**

Төн ул — көннең күләгәсе,
Юк төннән зур күләгә.
Сокландыра алмый күзне
Төнлә гүзәл гөлләр дә.
Караңгылык каплый җирне,
Төн кочагы салкынча.
Караңгылык һәм салкынлык
Җанны үзенә кыса.
Төн-күләгә — ярсыз диңгез,
Арыйсың йөзә-йөзә.
Салкын диңгез дулкыннары
Килеп бәрелә йөзгә.
Кысыла тыннар, арый куллар,
Йөзеп ярсыз диңгездә.
Тау итеп өям төннәрне,
Һич йокы керми күзгә.
Бу таулар инде күптәннән
Ишелер иде башка.
Ярый әле, көн туа да,
Тотынып калам кояшка.

**IV**

Бәхеткә ияреп йөри
Бәхетнең күләгәсе.
Күпме качма, аңарга син
Бер килеп эләгәсең.
Бәхет, серле урман кебек,
Һаман үзенә тарта.
Карамыйбыз шул без артка
Бәхеттән шашкан чакта.
Эченәрәк кергән саен
Күләгәләр куера.
Кояш сүнә, сукмак бетә,
Бәхет юлы җуела.
Урман бетүгә башлана
Борчулар «биләмәсе».
Бәхет артыннан йөри шул
Бәхетнең күләгәсе.

**V**

Җәйге кич.
Күктә йолдызлар
Һәр гашыйкка җитәрлек.
Зөһрә кыз суга йөгерә,
Көянтәсен күтәреп.
Шыбыр-шыбыр йолдыз ява
Кызның чиләкләренә.
Чиләкләргә сыймаганы
Куна беләкләренә.
Йолдызларын сибә Зөһрә
Гашыйкларның юлына.
Төшә иң якты йолдызлар
Бәхетлеләр кулына.
Тын кичтә йолдыз яуганын

Ай күзәтә елмаеп.
Кемгәдер йолдыз җитмәсә,
Йөзе кала моңаеп.
Ә җирдә хәрәкәт бара,
Кинәт җил исеп куя.
Яфраклар сөйләшә башлый,
Энҗеләр коя-коя.
Гади бер төн, ә күпме сер.
Җанга тынычлык сара.
Айның ап-ак күләгәсе
Елгадан агып бара.

**VI**

Күләгәләр, күләгәләр,
Минем игезәгем сез.
Гомер буе җитәкләшеп
Дөньялар гизәбез без.
Мин сезне кайчак күрмим дә,
Йөрсәгез дә тагылып.
Сезне һич яратмасам да,
Куйгалыйм мин сагынып.
Балачакның күләгәсе
Кайларда калды икән?
Суларга акты микән ул,
Болытлар алды микән?
Ә яшьлегем күләгәсен
Яшеннәр яндырдымы?
Әллә аны фәрештәләр
Күкләргә алдырдымы?
Кайчак бик озынаясыз,
Кайвакыт кыскарасыз.
Баш очымда кояш торса,
Бөтенләй югаласыз.
Җирдә яши ак һәм кара,
Димәк, сез дә кирәкле.
Күләгәм агара алмый,
Алмаштырып күлмәкне.
Күләгә чын йөзебезнең
Бер караңгы халәте.
Үз-үзен аңларга җирдә
Бик сирәкләр сәләтле.

**VII**

Җәйге көн.
Кояш кыздыра.
Гөлләр беткән әлсерәп.
Гөлләргә дәрт өстәр иде,
Җилләр исә бик сирәк.
Чәчәкләр ыңгырашалар
Тын гына, өнсез генә.
Башлары түбән иелгән,
Елыйлар сүзсез генә.
Кинәт бер болыт чыкты да
(Зур да түгел, кечкенә).
Ташлады үз күләгәсен
Болытларның өстенә.
Җил исеп куйды, гөлләрне
Назлы кул белән сыйпап.
Чәчәкләр башын күтәрде,

Күзләре алды уйнап.
Ә болыт, кечкенә болыт,
Озак торды эленеп.
Шул арада үлеп барган
Болын җитте терелеп.
Чәчәкләр уйный башлады
Йөгерешеп җилләрдә.
Бер болыт, кечкенә болыт,
Сулыш өрде гөлләргә.
Юкса яңгыр да яумады,
Тик җилләр уйнап алды.
Бик күпләр бу үзгәрешне
Хәтта сизми дә калды.
Әзме җирдә яхшы эшләр
Кала шулай күмелеп.
Дөньяларны тотып тора
Менә шундый игелек.

**VIII**

Халкыбызның каны кайда гына,
Нинди генә яуда акмаган?!
Безнең данлы үткән юлыбызны
Чорлар күләгәсе каплаган.
Ничә гасыр кара күләгәдә
Якты кояш күрми барулар,
Чәчәк атам-атам дигән чакта,
Чәчәк ата алмый калулар;
Озын булып үсеп җиттек дигәч,
Буын сыегаеп авулар,
Күләгәгә ут төртергә теләп,
Шул утларда үзебез янулар;
Караңгыда юлны югалтулар,
Юл табудан өмет өзүләр,
Йөрәкләрне учка кыса-кыса
Чәчрәп чыгар чакта түзүләр, —
Кечерәйтте безне, сыегайтты,
Рухыбызга сукты, имгәтте.
Кояшсыз да яшәп була икән
Дип уйларга безне өйрәтте.
Кара күләгәнең каралыгы
Йөзебезгә безнең ягылды.
Татар — хәтәр дигән яманатны
Юалмады еллар агымы.
Юкса халкым күпме утлар кичте,
Иң беренче керде яуларга.
Үзен түгел, канлы империяне
Бөек җиңү белән данларга.
Сугыш бетте, җиңү килде илгә,
Безнең батырлар да данланды.
Күләгәләр инде таралыр дип,
Тагын бер кат халык алданды.
Бу күләгә куера гына төште,
Түбәнәйде авыр болытлар.
Йөзгә бәреп ачы җилләр исте,
Тарайдылар тагын офыклар.
Яшен утлары да яндырмады,
Таратмады көчле җилләр дә,
Җиде катлы күккә менсәк тә без,
Шул күләгә басты иңнәргә.
Юк, юк, канлы кара күләгәне

Бармабыз без мәңге өстерәп.
Кайнар кояш аны бер яндырыр,
Кояш күләгәдән көчлерәк.
Орлыклар бар безнең, тамырлар бар,
Дым алабыз җирдән, яңгырдан.
Кара күләгәләр янган чакта,
Без калкырга тиеш тамырдан.
Һәм үсәргә тиеш,
Башны күккә терәп,
Капламаслык итеп күләгә.
Вакыт җитте, кояш нуры эчеп,
Буын ныгытырга безгә дә.

**IX**

Толларның күзендә,
Ятимнәр йөзендә
Сугышның шәүләсе бар һаман.
Күңелдә шом яши,
Җәен дә җан өши —
Сугышлар булмасмы яңадан?
Сызлаган тәннәрен
Уалый төннәрен
Сугышта өтелгән ветеран.
Түш тулы орденнар,
Тән тулы яралар
Кительгә тагылган барлык дан.
Сугышлар бетәр дип,
Ил алга китәр дип,
Алданып яшәгән елларны —
Бәйрәмдә бирелгән
Матурлап төрелгән
Бүләкләр, шәраблар юармы?
Бәйрәмнәр тиз үтәр,
Гадәти көн җитәр,
Яз назлар өр-яңа гөлләрне.
Тик толлар күзеннән,
Ятимнәр йөзеннән
Сугышның шәүләсе китәрме?

**X**

Җир әйләнә.
Җир әйләнгән саен
Урый үзенә яңа болытларны.
Яшен уты телгәләсә генә,
Теленеп төшә болыт сыныклары.
Тик яшеннәр кабына да сүнә,
Ә болытлар йөри урап-урап.
Болытлардан төшкән күләгәләр
Җирнең матурлыгын китә урлап.
Үсеп чыга атом «гөмбәләре»,
Аларның бит күләгәсе авыр.
Уралсалар Җирнең күчәренә,
Әйләнүдән Җир тукталып калыр.
Ярдәм көтә бездән һәрбер чәчәк,
Табигатькә гел яктылык кирәк.
Күләгәләр артык күбәйсәләр,
Кешеләрдән калыр бары өрәк.
Күләгәнең явыз мәкерлесе

Туплар көпшәсендә качып ята.
Һәм каплый ул кояш яктылыгын
Һич көтмәгән-уйламаган чакта.
Дөнья фани диеп уфтанабыз,
Фанилыкны тизләтәбез үзебез.
Ераклыкка карый алмый башлый
Күләгәләр аша безнең күзебез.
Күләгәләр яткан чүлмәкне без
Су төбеннән үзебез алып ачтык.
Күләгәләр чыкты ургып-ургып,
Күләгәләр чыкты ташып-ташып.
Хәзер инде чүлмәктәге җенне
Буйсындырып булмый теләсәк тә.
Алып бара кара күләгәләр
Зәңгәр күкне каплап киләчәккә.

*2005*

## ЕЛМАЕП, КӨН ҖАНЫ ЯРАЛДЫ

*(Туплам)*

Җирдә күпме җаннар йөри
Иясез шатлык булып.

*Р.Фәйзуллин*

### I

Сузылып офыкта атты таң,
Елмаеп, көн җаны яралды.
Көн җаны кояшка әверелеп,
Нур булып дөньяга таралды.

### II

Янды, янды, офыкларда
Төсләр янды.
Күкрәгемә сыя алмый,
Хисләр янды.
Янды, янды, яшен булып
Яшьлек янды.
Учларымда шул яшеннең
Ташы калды.
Һич суынмас, учта чакта
Ул гел янар.
Бәлки, очкын алыр аннан
Җансыз җаннар.

### III

Кайчагында күкнең йөзен
Каплый кап-кара болыт.
Йөзләрдән елмаю кача,
Тәнгә йөгерә суык.
Таралмый болыт җилдә дә,
Яумый яңгыр булып та.
Аның шушындый халәте
Шомландыра, куркыта.
Иңнәрне баса башлый ул
Озак торуы белән.

Алып атып булмый ләкин
Ул авырлыкны иңнән.
Уйлана башлыйсың шунда:
Ник таралмый бу болыт? —
Әллә без оныткан җаннар
Килгәннәрме җыелып?
Шулайдыр, әйе, шулайдыр,
Кыска бит безнең хәтер.
Бу җаннар җыелып бездән,
Бәлки, дога көтәдер?!

**IV**

Исә җилләр, исә җилләр,
Җилләрнең эше тыгыз:
Аларның да җаны, ахры,
Минем җандай борчулы да,
Минем җандай тынгысыз.
Исә җилләр, исә җилләр,
Урап кырны, басуны.
Җилләрнең дә йөрәкләре,
Ахры, һәрчак ашкынулы,
Ахры, һәрчак ярсулы.
Исә җилләр, чәчәкләрнең
Башын сыйпап сак кына.
Аларның да күңелләре
Гүзәллеккә омтыладыр,
Матурлыкка тартыла.
Исә җилләр, исә җилләр,
Җилләр һәрчак ирекле.
Кайсыбызның гына җаны
Сөйми икән хөрлекне дә
Сөйми икән ирекне?!

**V**

Бер карыйсың, тургай булып оча,
Бер карыйсың, уйный дулкын булып,
Бер карыйсың, камыш эчләрендә
Елагандай итә сулык-сулык.
Ашкындыра яки моңландыра,
Дәртләндерә яки уйландыра,
Шатландыра яки кызгандыра,
Йөрәкләрне безнең сызландыра.
Тетрәндерә, хисләндерә дә ул,
Биләп ала кайчак бөтен аңны —
Иңнәреңдә пар канатлар үсә,
Күңелеңә керсә җырның җаны.

**VI**

Таулар биек, таулар биек,
Карыйм башымны чөеп.
Зөһрә кызның чиләкләре
Китә тауларга тиеп.
Таулар башында зур кыя,
Кыя өстендә бөркет.
Кыяга якын килмиләр
Башка кош-кортлар, өркеп.
Тау башына менәр идем,
Баскычлар юк менәргә.
Тау өстендәге таш тәхет

Бары бәхетлеләргә.
Таулар биек, таулар биек,
Торалар күккә тиеп.
Алар горур, беркемгә дә
Тормый башларын иеп.
Ташларын киссәләр дә,
Башларын киссәләр дә,
Таулар тау булып калалар,
Гасырлар кичсәләр дә.
Аларның җаннары горур,
Таулар шуңа биекләр.
Бәлки, тауларның җаныннан
Яралгандыр бөркетләр.

**VII**

Җирдә җансыз нәрсә бармы? —
Була утның да җаны.
Җылысын гына тоябыз,
Күрмибез генә аны.
Утны саклау кирәклеген
Җибәрәбез онытып.
Китәбез янган учакта
Кулыбызны җылытып.
Һәм онытабыз ут турында,
Уйны били башка гамь.
Җилфердәп яна-яна да
Сүнә беркөн учак-шәм.
Оясыз калган кош кебек,
Күккә оча ут җаны.
Җылысы кими бара, дип,
Без сүгәбез дөньяны.

**VIII**

Тәрәзәбезгә ябышып,
Бер күбәләк үлгән.
Кергәндер ул өебезгә
Куркып салкын көннән.
Канатлары булганнарга
Тар булгандыр өй бик.
Тарткандыр аны үзенә
Урамдагы киңлек.
Чуар чәчәк-күбәләккә
Сулышымны өрдем —
Сулышым белән бар җылымны,
Бар назымны бирдем.
Тырыша торгач, күбәләгем
Бер кыймылдап куйды:
Җаны, ахры, минем җанның
Йомшак назын тойды.
Очып китте күбәләгем,
Канатларын җилпеп.
Ахры, һәр җан иясенә
Кирәк наз һәм ирек.

**IX**

Киштәләрдә тезелеп тора китап,
Һәрберсенең тынып калган җаны.

Сабыр итеп, тәмам саргаешып
Көтә алар безнең кагылганны.

**X**

Яфрак шаулап торганда,
Кошлар сайрап торганда,
Бар җәнлекләр тырышып
Үзенә оя корганда;
Аландагы чәчәкләр
Биегәндә җилләрдә,
Тамырларга дым алып
Ишелеп яңгыр килгәндә;
Саркып чыккан чишмәләр
Тыныч кына акканда,
Без борынлы тукраннар
Агач чукып ятканда —
Бик тыныч урман җаны,
Матур шәфәгы, таңы.
Җырлап утыра һәр агач,
Данлап гүзәл дөньяны.
Җиләкле аланнарны
Машиналар изгәндә,
Үткән-сүткән кешеләр
Гөлләр башын өзгәндә,
Бәйрәмнәрдә урманга
Исерекләр тулганда,
Яшьләр куак төбендә
Яман эшләр кылганда,
Балта, пычкы тавышы
Киткән чакта яңгырап,
Урман җаны сызланып
Куя кинәт калтырап.
Бетә шунда тынычлык,
Төшә урман хафага.
Дошман кергән илгә, дип,
Һәрбер яфрак чаң кага.

**XI**

Каләмемне төрттем ак кәгазьгә,
Ак кәгазьгә кинәт җан керде.
Кош ясадым шушы кәгазьдән мин,
Тик бу кошка өем тар иде.
Тәрәзәмне ачып җибәрүгә
Очып чыгып китте бу кошым.
Күзләремне зәңгәр күккә текәп
Карап тордым аның очышын.
Озакламый юкка чыкты кошым,
Менде әллә артык югары.
Әллә берәр җансыз бәндә күреп
Җанлы итәргәме уйлады.
Басып тордым тәрәз каршында мин,
Уйлар давылына күмелеп.
Үтеп китте ашыга-ашыга бер кыз,
Нәрсәдәндер бик нык сөенеп.

**XII**

Әйләнә дә әйләнә
Бертуктамый Җир шары.

Юкса җиңел түгелдер
Галәмнең дә юллары.
Бәлки, ул да арыйдыр,
Һичбер хәле калмыйдыр.
Бәлки, бераз тукталып
Ял итсә дә ярыйдыр.
Хәер, шундый язмышы,
Әйләнми юк чарасы.
Җир әйләнми башласа,
Нишләр адәм баласы?
Көннәр бетәр буталып,
Төннәр бетәр буталып.
Калыр барлык тереклек
Яшәвеннән тукталып.
Бер туктагач кузгату
Авыр хәтта арбаны.
Туктамасын, әйләнсен,
Җир — кешелекнең җаны.
Безнең җаннар береккән
Мәңгегә шушы җанга.
Сүнмәс тереклек уты,
Җир әйләнеп торганда.

*2005*

## БЕЗ ТАБИГАТЬ БАЛАЛАРЫ

*(Туплам)*

Җырлагыз сез күңлегезгә Тәңре нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк шулай ук ауларым.

*Г.Тукай. «Кошларга»*

**I**

Җирләр, сулар, күкләр белән
Без мәңгегә береккән.
Без бетәбез, аерылсак
Менә шушы берлектән.

**II**

Кил әле, Яз, җылы алып,
Хисләр китте суынып.
Җылыныйм әле наз тулы
Кочагыңа сыенып.
Кил әле, Яз, җилләр алып
Җилләним бер җилеңдә.
Яз һавасы тулып калсын
Бушап калган күңелгә.
Кил әле, Яз, гөлләр алып,
Бер чәчәгеңне өзим.
Карармын аңа сокланып
Талганчы ике күзем.
Кил әле, Яз, йөзләремә
Яктылыгың ягып кит.
Сагыш күрсәң күзләремдә,
Еракларга алып кит.
Кил әле, Яз, хуш ис төяп,
Исләреңнән исерим.
Иң бәхетле язларымны
Тагын искә төшерим.

Кил әле, Яз, хәер, килмә,
Кошларга да хәбәр ит.
Кайтсалар, харап булырлар...
Бездә шундый хәлләр бит.

**III**

Кош-кортларны утта яндыралар,
Кошлар чире, имеш, таралган.
Ә бит җирдә һәрбер җан иясе
Яшәр өчен диеп яралган.
Җылы яктан кайтыр кошларны да
Мылтык тотып көтеп торалар.
Канат очларына язлар төяп
Килер микән быел торналар?
Җир белән күк арасында шартлап
Өзелмәсме аккош юллары?
Мәңгелеккә тынып калмас микән
Урманнарда кәккүк моңнары?
Сыерчыклар әгәр сайрамаса,
Буш калсалар барлык оялар?
Яңгырамаса былбыл тавышлары,
Моңсыз калса әгәр дөньялар?!
Кем эретер каткан җаныбызны,
Калмабызмы мәңге кышларда?
Ә бүгенгә хәтта каргалар да
Куркып утыралар очарга.

**IV**

Җиргә һәрчак афәт янап тора,
Тыныч яшәп булмый, ахыры.
Әле анда, әле бу якларда
Өзелә шартлап җирнең тамыры.
Җир тамыры галәмнәргә түгел,
Безнең күңелләргә тоташкан.
Җир йөзендә һәрбер җан иясе
Аерылмаслык булып укмашкан.
Кош-кортлары, киек җәнлекләре,
Бөҗәкләре, хәтта еланы —
Әйтерсең лә алар җанлы аркан
Бәйдә тотар өчен дөньяны.
Берсе бетсә — икенчесе бетә,
Тормыш тора җанлы чылбырдан.
Бозыла фикер, хәтта бер-ике сүз
Алып ташласаң да шигырьдән.

**V**

Елгаларда кара сулар ага,
Каян килгән мондый каралык?!
Савытларга алсаң елга суын,
Язу карасына ярарлык.
Агуланган хәлсез балыкларны
Зур дулкыннар ата ярларга.
Акчарлаклар өстән карап уза,
Акчарлаклар тими аларга.
Ә кешеләр җыя сөенә-сөенә,
Ашар өчен җыя ачлары,
Ә туклары сатар өчен җыя,
Тукларның шәп эшли башлары.

Елга ярсый, кара суларыннан
Котылырга тизрәк телиме?!
Яр буеннан ташлар умырып ала
Котырынган дулкын өеме.
Карап торам суның агышына,
Кара суга кушылып уй ага.
Чистартмакчы булып елга суын,
Саф чишмәләр кушыла елгага.
Табигатьтә шулай көрәш бара,
Күрми аны күңеле сукырлар.
Һаваларга кара аждаһадай
Күтәрелә кара дулкыннар.

**VI**

Йорт казлары бергә җыелды да
Очып китте ерак илләргә;
Ашыкмагыз әле, ашыкмагыз,
Алай була алмый, дияргә.
Тормыш бит бу! Ә тормышта безнең
Көтелмәгән хәлләр җитәрлек.
Тыныч кына яшәп яткан чакта,
Давыл ала сине күтәреп.
Исеңә төшә канатларың бары,
Күкрәгеңә гайрәт, көч тула.
Никадәрле сабыр җаннарның да
Сабырлыгы шартлап бер сына.
Кайчагында җилләр кагылса да,
Алмаларын коя алмагач;
Оча алырыңа ышанасың,
Канатыңа утлар кабынгач.
Йорт казларын, тыйнак йорт казларын,
Шомлы хәбәр күккә күтәрде.
Казларның бу кыю очышлары
Шаккаттырды җирдә күпләрне.
Ачып куйды күкләр капкаларын
Бу тәвәккәл, кыю казларга.
Китте казлар, «кыйгак-кыйгак» диеп,
Әллә көзгә, әллә язларга.
Бу казларның гүзәл очышлары
Хәтеремдә калды уелып.
Их! Халкым да, дәррәү күтәрелеп,
Бер күрсәтер микән кыюлык?!

**VII**

Кош чире таралу сәбәпле,
сыерчык ояларын җыеп алырга.

*Телевизордан тапшырылган хәбәр*

Алып ташларга әмер бар
Сыерчык ояларын.
Сыерчыклар беләм микән
Бу яман хәбәр барын?
Яз инде борын төбендә,
Тиздән кошлар килерләр.
Килерләр дә дөнья буйлап
Оя эзләп йөрерләр.
Капкадан капкага кунып
Сайрарлар өзеп-өзеп.
«Кешеләр! Сез нишләдегез,
Бу нинди бәгырьсезлек.

Без бит сезне сагынып кайттык,
Юлда таңнар аттырдык.
Тизрәк алып кайтыйк дидек
Сезгә яз һәм матурлык.
Әгәр сезгә кирәкмәсә
Матурлык һәм хозурлык,
Без китәрбез урын эзләп
Берәр оя корырлык.
Җир тар булса — күкләр иркен,
Күкләр бит җиде катлы.
Менәрбез җиденче катка,
Без бит кошлар — канатлы.
Һәм киткәннәр алар очып
Билгесезлеккә таба.
Күтәрелгәннәр биеккә,
Кояшта яна-яна.
Кайтмаган алар әйләнеп,
Рәнҗүләре зур булган.
Шул көннән урман-кырларда
Иң матур бер җыр тынган.

**VIII**

Бер кош килеп минем тәрәзәмә
Шундый матур итеп сайрады.
Әй ул тавыш, әй ул моңлы тавыш! —
Йөрәкләрне тәмам айкады.
Тәнемдәге бөтен күзәнәкләр
Уяндылар кинәт бу моңнан.
Хәтта кешеләр туктап тыңладылар
Ашыга-ашыга барган юлыннан.
Көтмәгәндә бүләк алган кебек,
Җан ашкынып куйды ирекә.
Онытылып тордым беразга мин,
Күтәрелдем гүя биеккә.
Күңелемә кинәт шом йөгерде,
Тәрәзәмне ачтым тиз ара:
Өемә кер, кошчык, өемә кер,
Кошларга бит быел ау бара.
Юк, кермәде кошчык, очып китте,
Күреп калдым бары шәүләсен.
Ә беркөнне таптым мин ул кошның
Юл буеннан үле гәүдәсен.

**IX**

Кышлар үткән. Яз җитмәгән әле,
Сайрамыйлар кошлар, урман тын.
Яфракларга чык тамчысы булып
Сеңеп калган әнә төнге моң.
Яз гөлләре умырзаялар да
Күзен ача алмый утыра.
Ботакларга сарган пәрәвездәй
Урман өсләрендә шом тора.
Таратмакчы булып бу тынлыкны,
Бер сызгырдым ярып урманны.
Уянмады урман, яфраклар да
Ялгыш селкенеп тә куймады.
Бар агачлар муенын күккә сузып
Көтә иде очар кошларны:

Килерләрме икән, килерләрме,
Исән чыкканнармы кышларны?
Урманнарда былбыл сайрар микән,
Аккош кайтыр микән күленә?
Яман хәбәр барып җитмәгәнме
Ерактагы кошлар иленә?
Бар табигать бүген зур борчуда:
Нәрсә уйлап тапкан кешеләр?
Чирлибез дә, терeләбез дә бит без,
Без бит кошлар — сезнең төслеләр.

**X**

Быел язлар килмәс дигән идем,
Килде, шөкер, килде быел да.
Күп булгандыр инде киртәләр дә
Яз китерүче кошлар юлында.
Килде кошлар яшеннәрдә янып,
Ә күпләре үлде очышта.
Ялгадылар алар яз җылысын,
Яз сулышын безнең сулышка.
Язлар юлын кошлар гына белә,
Тик кошлардан гына курка кыш.
Килер юлын җуяр язлар, әгәр
Бетсә генә җирдә соңгы кош.

**XI**

Шатланам да, кайгырам да,
Күңелдә төрле уйлар:
Ярый кошлар укый белми
Һәм радио тыңламыйлар.
Кайчагында күп белүдән
Белмәвең хәерлерәк.
Кошлар оча баш очымнан,
Бәхетле язлар теләп.
Кошлар тавышы дәртләндерә
Моңсуланган җаннарны.
Яшик әле бергә-бергә,
Без һәммәбез дә җирдә
Табигать балалары.

*2006*

## ЙОКЫСЫЗЛАР ДА КИРӘК

*(Туплам)*

**I**

Менә тагын төнгә керәм,
Төнгә түгел, күлгә керәм.
Ә күл тирән, ә күл шомлы,
Суы салкын, кыса тынны.
Мин шул судан йөзеп барам,
Тыгыз суны сөзеп барам.
Арганлыкны сизеп барам,
Көчкә-көчкә түзеп барам.
Менә-менә батам димен,
Төпкә төшеп ятам димен.

Мәшәкатьле бу дөньяга
Инде кабат кайтмам димен.
Шулчак кинәт нидер була, —
Офыкларда таң сызыла.
Хәлсезләнгән юлаучыга
Әйтерсең лә нан сузыла.
Үреләмен шушы нанга,
Өмет нуры тула җанга.
Кара төнне куган өчен
Рәхмәт укыйм гүзәл таңга.
И йокысыз озын төннәр,
Көчне суыра торган җеннәр,
Сез караңгы булган саен
Якты тоела миңа көннәр.

**II**

Йокы чүлмәгемне, ахры,
Урлаганнар җеннәр.
Керфеккә керфек какмыйча
Үтә бик күп төннәр.
Комга күмгән күмерләрне
Җилләр ачкан кебек.
Көйри башлыйм, дөрли башлыйм,
Таңга утлар биреп.
Интегәләр якыннарым
Минем бу холкымнан.
Белмим, йокы тамырларым
Кайларда йолкынган?!
Мөгаен, мин үлгәчтен дә
Утырырмын торып.
Ачармын каберем тактасын,
Тырнак белән кырып.
Шаккатмассыз, кайтып килсәм
Кәфенемне сөйрәп.
Димәк, җирдә минем кебек
Йокысызлар да кирәк.

**III**

Йокысызлык белән тынгысызлык —
Өлешемә тигән көмешем.
Торып утырам җәйге таңнан алда,
Булмаса да гәрчә бер эшем.
Мин тормасам, гүя таңнар атмый,
Кояш чыкмый гүя оядан.
Каләм белән сызып офык читен
Туып килгән көнгә эз салам.
Беләм юкса, берни миннән тормый,
Берни бирми минем талпыну.
Ләкин рәхәт көннең бишегенә
Иң беренче булып кагылу.
Яңа көн ул — яңа туган сабый,
Мин кисәмен аның кендеген.
Көлеп туса әгәр сабый җиргә,
Йөрим мин бәхетле дип бүген.

**IV**

Шәһәр йоклый. Беркем уянмаган.

Урамнарда әле тынычлык.
Каргалар да чүп-чар актармыйлар,
Чыркылдамый хәтта бер чыпчык.
Чү, кемдер бар: берәү тәрәзәдән
Чыгып килә кысылып-кысылып.
Йөге авыр, ләкин «ярдәм ит» дип
Беркемгә дә булмый кычкырып.
Әллә ялгыш, әллә юл уңайдан,
Милиция килде «ярдәмгә».
Машинада урын тапты алар
Тәрәзәдән чыккан адәмгә.
Ә икенче чатта «Мерседес»тан
Төште ике «төнге күбәләк».
Утырдылар алар өй янында
Бәхәсләшеп, нидер бүлгәләп.
Һәм чумдылар подъезд эчләренә
Йокы «симертергә» иркенләп.
Мендәр асларында доллар артты,
Намус кими барды көн-көнләп.

**V**

Төннең нәкъ уртасы,
Эленгән күктә Ай.
Шәһәрне күзәтә
Ай — уяу полицай.
Кайдадыр дөп тә дөп
Сугыша үсмерләр.
Кайдадыр яшь кызны
Акыртып көчлиләр.
Ялгыз Ай — полицай
Торса да постында,
Корылган пистолет
Юк аның учында.
Шәһәрдә мең тыкрык,
Шәһәрдә мең урам.
Урамда иң киме
Биш-алты хулиган.
Фонарьлар ватылган,
Хәрәкәт тукталган.
Кем — угры, кем — туры —
Һәммәсе буталган.
Кап-кара юрганга
Уралып-уралып
Йоклыйдыр күк шәһәр,
Тип-тигез тын алып.
Ә юрган астында
Икенче бер тормыш.
Барсы да бар монда —
Һәм солых, һәм сугыш.

**VI**

Төн елгасы кара,
Төн елгасы тирән.
Күккә ага бу су,
Пычрак җыеп җирдән.
Бу елгада ага
Биек-биек йортлар.
Баганасы белән

Чума анда утлар.
Чайкый дулкынында
Һәммәбезне елга.
Кат-кат чайкый-чайкый
Гөнаһларны сыга.
Ә без пычранабыз,
Көн тудымы кабат.
Дөнья куган чакта,
Онытыла савап.
Гомер бакый шулай
Төн елгасы ага.
Безнең һәрбер гөнаһ
Күк ишеген кага.

**VII**

«Тук-тук», «тук-тук» атлый берәү
Төнге урам буйлап.
Үкчәсе белән асфальтны
Каты гына кыйнап.
Һәрбер тукылдавы аның
Гүя морза хәрефе.
Кисәтә кебек ул безне:
«Дөнья бик хәвефле!»

**VIII**

Ишетелә башлады
Себерке тавышы.
Чаж да чож, чаж да чож —
Киң аның карышы.
Ялый ул асфальтны
Кытыршы тел белән.
Бер төндә шәһәрне
Никадәр чүп күмгән.
Дөньяда күп юкса
Акыллы машина.
Бер түгел, биш тияр
Һәр кеше башына.
Ә бездә һаман шул —
Көрәк тә себерке.
Йөртәбез гел кулда,
Шул безнең «ил күрке».
Карыйм да карт әби
Себергән урамга.
Кысып чал чигәмне
Чумамын уйларга.

**IX**

Ашкынган дөньяның,
Ярсыган дөньяның
Ярсуын басарга төн кирәк.
Талчыккан дөньяның,
Арыган дөньяның
Аруын басарга төн кирәк.
Төн кирәк яшьләргә,
Төн кирәк картларга
Бер-берсен күрмичә торырга.
Төн кирәк гашыйкка,
Төн кирәк карчыкка

Намазын иркенләп укырга.
Тилергән көннәрне,
Тилмергән көннәрне
Онытырга төн кирәк, төн кирәк.
Уйларны сүндереп,
Бар эшне бүлдереп
Ял итеп алырга төн кирәк.

**X**

Йокысызлар бер мин генә түгел,
Һәркемнең бар ише, әшнәсе.
Йокысызларны үз артына җыя
Төннең театрсыз сәхнәсе.
Ул сәхнәдә һәркем үз ролендә,
Шуңа күрә юк һич үпкәләш.
Кочагың киң, кесәң калын булса,
Бер кияүгә була дүрт кәләш.
Ямьсезлектән рәнҗеп ятканнарны
Төн матурлый, гүзәл иттерә.
Кәрләләрне кинәт үстерә дә,
Түбәләрен күккә җиткерә.
Картлар китә яшьлекләрен эзләп,
Күрмәгәндә бала-чагасы.
Кемнең килмәс яшьлек юлларыннан
Агач атка менеп чабасы.
Төннең вазифасы җирдә бик зур,
Бик күп эшләр аның иңендә.
Иң-иң якты уйлар туа кайчак
Гомернең иң кара төнендә.
Бушка үткән көннәр булып тора,
Көн сабагы киселә тамырдан.
Ярый әле йокысыз төннәрем бар
Ул көннәрне түләп алырга.

**XI**

Йокысызлык әҗәл чире кебек,
Әҗәлләргә дәва кем тапкан?
Ходай миңа җан өргәндә, ахры,
Әҗәл чире белән яраткан.
Учлап-учлап эчкән дарулар да
Файда бирми миңа нигәдер.
Кулга каләм алып утырам өчтә,
Каләм генә хәлне беләдер.
Кыштыр-кыштыр, кыштыр-кыштыр итеп
Кәгазь белән каләм сөйләшә.
Каләм очларында кара яна,
Бер яктан да якты төшмәсә.
Ут кабызып төнне куркытмыймын,
Каләм уты көчле шәмнәрдән.
Уйларымны шул утларга ягып
Котылып торам бераз гамьнәрдән.
Әҗәл чире миндә, әҗәл чире, —
Йокысызлык миндә тумыштан.
Кара төннәр кочагына кереп
Кача алмыйм шаулы тормыштан.

*2002*

## ЙӨРӘГЕНДӘ БАРА КҮТӘРЕП

*(Туплам)*

**I**

Көлү белән елау һәрчак бергә,
Яшәү белән үлем шикелле.
Кычыткан да, гүзәл чәчәкләр дә
Бер туфракта үсә түгелме?
Кайгырырга яки шатланырга
Тормышта бит сәбәп җитәрлек.
Үзенең гамен, төяп, һәрбарчабыз
Йөрәгендә бара күтәреп.

**II**

Сатып алдым кесә телефоны,
Бар акчамны кырып-себереп.
Больницадан, мәйтәм, чыгам әле
Әллә үлеп, әллә терелеп.
Китеп барсам теге дөньяларга,
Байлык әрәм калыр барыбер.
Карчыгымның сандык төбе тирән,
Үлемтеккә акча табылыр.
Карчыкка да алдым бер телефон, —
Шалтыратып кына торабыз.
«Кайчан яттың, ни ашадың» диеп,
Сәгать буе гәпләр корабыз.
Хатын белән, хәер, кызык түгел,
Барып чыгам әллә кайларга.
«Мин бизнесмен, мин крутой» димен,
Юлыкканда яшьрәк кызларга.
Шәп икән бу кесә телефоны,
Оныттыра бөтен дөньяны.
Әбрәкәйгә чыккан чагында да,
Үзем белән алам мин аны.
Барыбер үләрмен дип кергән идем,
Инде менә терелә башладым.
Ә бу комсыз кесә телефонын
Мин «фахишә» диеп атадым.

**III**

Шулай әтәчләнеп йөргән чакта
Тотып алды кинәт йөрәгем.
Фәрештәләр белән шашма диеп
Типкәләде гүя җеннәрем.
Очып төште кесә телефоным
Әллә кая — ерак почмакка.
Суык тәнле, ямьсез карт убырлар
Кереп тулды минем кочакка.
Көннәр белән төннәр кушылып акты,
Йөзеп йөрдем ап-ак томанда.
Фәрештәләр күрсәм, елмайдым мин,
Елмаерлык хәлем булганда.

**IV**

Тишкәләнеп бетте инде тәнем,
Ничек түзәдер бу тамырлар.
Көн дә кереп аны актаралар,
Әйтерсең лә анда алтын бар.

Ә кем белә, бәлки, алтын бардыр,
Ирләр йөрәгендә ни ятмас?!
Юкка гына, бер дә юкка гына
Асыл затлар безне яратмас.
Юк-барларны алар үз итмиләр, —
Күзе очлы асыл затларның.
Тамырларда, бәлки, саклнадыр
Алтыннардан артык чакларым.
Эзли икән тамырларны айкап,
Димәк, әле өмет сүнмәгән.
Розалардан тамган ал чык кебек
Бер ал тамчы тамды энәдән —
Тамырда бар, димәк, эзләгән.

**V**

Өн белән төш арасында
Уйлар яктырып ала,
Күңел барлык күренешне
Үзенә сеңдереп кала.

**VI**

Тагын менә хастаханә,
Тагын дарулар исе.
Монда син бер сарык кына,
Монда син түгел кеше.
Һәр нәрсәгә өркеп карый,
Курку хас шул бу затка.
Бүре күзләре күрә ул
Һәр караңгы почмакта.
Уйламагыз сарыкларның
Пошынуы урынсыз,
Акыллары булмаса да,
Түгел алар борынсыз.
Һавада бит бүре исе! —
Бөркелә ул җил белән.
Бүре кемне сагалыйдыр,
Кем белә бит, кем белә!
Курку да бар, өмет тә бар
Һәр сарык күңелендә:
«Бәлки әле, бу ач бүре
Миңа тимәс бүгенгә,
Миңа тимәс бүгенгә!»

**VII**

Коридорда ята бер авыру,
Палатада урын җитмәгән.
Урынсызлык, шушы урынсызлык
Кем башыннан гына үтмәгән.
Күпләрнең бит әле өендә дә
Сузылып ятарлык та урыны юк.
Өстәл асларында үссәң әгәр,
Каян булсын инде горурлык.
Без татар дип мактанабыз кайчак,
Мактанырга ләкин урын юк.
Чәчебез белән җир себерә-себерә,
Маңгай беткән инде кырылып.
Милләтебез язгы кардай эри,

Миллэтебез бара кырылып.
Сирэгэя барган саен лэкин
Җир тарая — безгэ урын юк.

**VIII**

Әй наданнар, берни белмилэр дип,
Табибларны эчтэн сүгэбез.
Ә үзебез, борын җебесэ дэ,
Табибларга йөгереп килэбез.
Табиблар да, бэлки, авырыйдыр
Кайчагында бездэн ныграк та.
Тик без килгэч, үзен оныта ул,
Чире кача аның еракка.
Кайчак безгэ күп тэ кирэк түгел,
Кирэк бары сине аңлаучы.
Ә бит тормыш безнең сыртыбызга
Сугып тора көнгэ йөз камчы.
Зарланасы килэ кайчагында,
Хэтта каты авырып аласы.
Бер жэллэүгэ, бер назлауга мохтаҗ
Гомер буе адэм баласы.
Бик күплэр бит эттэй сүгелеп йөри,
Җан бөрешэ җылы, наз юкка.
Зарлы йөрэклэрен учына салып
Килэ алар, килэ табибка.
Ә бит күплэр табибка да бармый,
Күмелеп йөри зары-моңына.
Алма булып өзелеп төшэ алар,
Түзми үзенең авырлыгына.

**IX**

Күптэн очрашмаган ике туган
Очраштылар ташлап эшлэрен.
Бу тэкэббер бэндэлэрне бүген
Очраштырды үлем түшэге.
Икесе дэ яши иде юкса
Бик якында, бер үк калада.
Бүре булып бер салкынлык кына
Ята иде ике арада.
Алтын-көмеш бүлешмэде алар,
Бер-беренэ гайбэт чэчмэде.
Тик кайсыдыр эйткэн бер авыр сүз
Бэгырьлэрен кимереп яшэде.
Һэм, ниһаять, бүген авыр хэбэр, —
Берсе киткэн каты авырып.
Больницага чапты икенчесе,
Кырык эшен читкэ калдырып.
Бер-беренең күкрэгенэ ятып
Елаштылар горур туганнар.
Күңеллэре белэн моңа алар
Күптэн инде эзер булганнар.
Берсе үлде, икенчесе калды,
Тик бушады барыбер эчлэре.
Җанны җанга ялгый алган өчен
Рэхмэт сиңа, үлем түшэге.

**X**

Бәйрәм алды. Хастаханә.
Өйгә җыена яшьләр.
Йөз кат көзгегә каралган,
Йөз кат таралган чәчләр.
Менә-менә егетләре
Килеп җитәр йөгереп.
Килеп җитәр, алып китәр,
Затлы туннарга төреп.
Кызлар назланып алырлар
Чамасын белеп кенә.
Ялалары сызласа да,
Торырлар көлеп кенә.
Өч кенә көнгә булса да
Онытылыр бар гамьнәр.
Бокалларда шампан ташыр,
Гөрләп торыр бәйрәмнәр.
Бик бәхетле бүген кызлар,
Шул ярсыта аларны:
Тауның кайнар чишмәседәй
Уйнап ага каннары.
Бу кызларга читтән генә
Карап тора карчыклар.
Аларның бәйрәме үткән,
Алар инде артыклар.
Ләкин алар көнләшмиләр
Бу бәхетле кызлардан.
Бары бәйрәм уңаеннан
Йөрәк кенә кузгалган шул,
Йөрәк кенә кузгалган.

**XI**

Кунак килгән, ишек кага,
Тышта буран ыжгыра.
— Ачыгыз, ач, бүләгем бар,
Юкса монда туңдыра.
Йорт иясе дәшә эчтән:
— Ача алмыйм, гафу ит.
Хуҗаларым больницада,
Бүләкләрең шунда илт.
Кунак, зур капчыгын асып,
Хастаханәгә китә.
Керфегенә бәсләр куна,
Сакалын җил селкетә.
Барып җитә, ә ишеккә
Язу куелган: грипп!
Ничек кермичә китәсең
Авылдан тикле килеп?!
Берни белмәгән шикелле
Бара ул басып кәс-кәс.
Ишекләрдән үткәрүче
Пароль була күчтәнәч.
Тапкач эзләгән кешесен,
Күңеле бик хуш була.
Ләкин күчтәнәч тутырган
Капчык кына буш була.
Хәер, ансы мөһиммени?!
Һәр яңа көн — күчтәнәч!
Зур шатлык — гомер күмәчең
Кимерелеп бетмәгәч.

Ул күмәч зурмы, түгелме,
Белми аны бер кеше.
Шул белмәүгә яшеренгән
Мәңгелек яшәү көче.

**XII**

Дөнья минсез кала язды
Кинәт кенә бүген.
Ишек тә кагып тормыйча
Килеп керде үлем.
Бугазымнан алды да ул
Сулышымны буды.
«Әллә бу бер террористмы»
Дигән уйлар туды.
Тик янымда беркем дә юк,
Күренми шул әҗәл.
Сөйләшеп утырыр идек,
Күренмәве бик жәл.
Хәер, аның вакыты юк,
Бик ашыга иде.
Башка берне тондырды да,
«Китәм инде» диде.
Әйләнде, тулганды дөнья,
Таулар ауды күктән.
Хәл кергәч белдем: бу әле
Репетеция икән.

**XIII**

Тәрәзәгә бер кош килә дә
Палатама минем күз сала:
«Тагын монда эләктеңмени,
Ярамый бит болай, и бала!
Килми икән каләмдәшләрең,
Син рәнҗемә берүк аларга.
Кайгы күрү кирәк кешегә
Башкаларның хәлен аңларга.
Димәк, алар әле бәхетле,
Бәхетлеләр өчен куаныйк.
Җыр китердем сиңа мин бүген,
Җырларыбыз белән юаныйк».
Кош сайрады тәрәз төбемдә,
Җыры сеңеп калды күңелгә.
Ятам аның җырын кабатлап,
Яшь тәгәри никтер яңактан.

**XIV**

Менә мин дә бераз аруландым,
Табиблар да кирәк икән лә.
Йомшак кулын суза алар сиңа,
Упкыннарга төшеп киткәндә.
Кесә телефонын эзләп таптым.
Ни хәлең бар, «нәни фахишәм»!
Дөрес, инде синең тавышың беткән,
Тик мин исән әле, мин исән.

*2002–2003*

## ТУГАН ЯК ТӨСЕ

*(Туплам)*

**I**

Туган якларыма кайтып барыш,
Яшел әле кырда бодай, арыш.
Урманнардан, кыр һәм басулардан
Күзләремә тула яшел балкыш.
Якынайган саен авылыма,
Таныш тавыш ишетелә ныграк.
Дулкын-дулкын булып кайнар тавыш
Җанга тула тамырларым буйлап.
Шушы тавыш мине биләп ала,
Мин кушылам аңа эчтән генә.
Туган якларымның тавышы да
Тора, ахры, кайнар хистән генә.
Тиктомалдан йөрәк ярсый башлый,
Күмелеп яткан хатирәләр ташый.
Һәр хатирә әверелә дә кошка,
Юлларыма ап-ак каурый ташлый.
Каурыйларны җыям учларыма,
Каурый түгел, гүя моңнар җыям.
Туган якларымның моңнарына
Никадәрле кайнар уйлар сыйган!
Хәер, нигә кайнар булмасын ул,
Суынырга юк бит аның хакы.
Без яшьлекне ягып калдырдык бит
Җылытырга туып үскән якны.
Туган якларыма кайтып барыш,
Өлгермәгән әле кырда арыш.
Изүләрне киереп ачып куям —
Йөрәгемә тула кайнар тавыш.

**II**

Болытларга яшен тамыр җәйде,
Яшен тамыры кандай кып-кызыл.
Кызыл җепне йомгак итеп урап
Булыр төсле, күккә тик сузыл.
Укмаштырды җилләр болытларны,
Һаваларда төсләр куерды.
Ниндидер көч кара йодрык белән
Яшен болытына тондырды.
Күкрәде күк. Кара калын тавыш
Дер селкетте биек тауларны.
Ә аннары ташлар коелгандай
Бүлгәләнде тавыш, таралды.
Сибелеп китте бөтен тирә-якка
Кызыл, сары, зәңгәр тамчылар.
Йокымсырап яткан барлык гөлләр
Сискәнешеп торып бастылар.
Кинәт кенә булды болар барсы —
Әйтерсең лә тик бер минутта.
Төсле челтәр булып эленеп калды
Салават күпере ерак офыкта.
Уйнады да тынды зур оркестр,
Дирижеры әллә ялгышты —
Озак кына ишетелеп торды
Чәчәкләрнең флейта тавышы.

**III**

Су буенда көй өйрәнә
Сынган камыш.
Кыл булып күккә сузылган
Нәзек тавыш.
Камыш эчендә гүяки
Нәни бер кыз
Ыңгырашып аваз сала
Чиртеп кубыз.
Көй көчәеп китә кайчак,
Көрәя моң.
Һаваларга агыла башлый
Аксыл дулкын.
Сайрар кошлар моң-дулкында
Йөзә башлый.
Җыр елгасы ярга сыймас
Булып ташый.
Сынык камыш бер тына да
Тагын сыза.
Ниләр булды икән соң бу
Камыш-кызга?
Нәни кызчык, сынык камыш —
Моң оясы.
Әллә китеп югалганмы
Су анасы?

**IV**

Кызыл алма җырлый икән
Карап кичке кояшка:
— Син батасың, мин каламын
Төнгә, сиңа алмашка.
Эчтем синнән кызыл нурлар,
Кызыл җырлар, ал җырлар.
Мин җырлармын ул җырларны,
Һәрбер уяу җан тыңлар.
Аккан сулар алып китәр
Җырларымны еракка.
Җилләр элеп куяр аны
Былбылы юк куакка.
Җилфер-җилфер итеп торыр
Яфракларда җырларым.
Ал нурларга манырмын мин
Төннең кара уйларын.
...Шулай дип җырлаган алма,
Уянганчы таң кошы.
Таралган җиһанга аның
Сопрано тавышы.

**V**

Эзләдем сине, эзләдем,
Таба алмадым озак.
Син үтәр дип, сукмакларга
Җырлардан кордым тозак.
Шул тозакның өсләренә
Иң матур гөлләр аттым.
Гамьсез генә барган чакта,
Син шунда китереп бастың.
«Зың» итеп куйды йозагым,
Чыгарып тимер чыңы.

Сизми дә калдым, үзгәрде
Синең җаныңның моңы.
Тоткын мәхәббәт тавышы,
Билгеле, елак иде.
Тозагым кулда булса да,
Син миннән ерак идең.

**VI**

Сикереп торды бер карт солдат,
Ишетеп җиңү маршы.
Үзе кинәт бөгелеп төште,
Үрә катып калды бары
Буш өйнең ишеге төбендә
Картның тонык тавышы.
Озак торды үрә катып
Бу тавыш шыксыз өйдә.
Аннан, солдат каешы табып,
Үзен-үзе элеп куйды
Почмактагы бер чөйгә.
Сузылды тавыш солдатның
Ябык муены булып.
Ыңгыраша да алмыйча,
Шыксыз өй калды тынып.

**VII**

Урман авызында сынык усак,
Ватык гармун кебек тавышы.
Яфрак булып өзелә каты җилдә
Тамырлардан килгән сагышы.
Тик яфраклар җиргә төшеп җитми,
Җилләр ала барсын күтәреп.
Җиде төскә мана җилләр аны,
Салават күпере аша үткәреп.
Очып китә усак яфраклары,
Кошлар кебек тезелеп, чөй ясап.
Жырлый башлый башка тавыш белән
Давылларда сынган бу усак.
Көй җәелә катлам-катлам булып,
Көй тарала күккә, киңлеккә.
Күзе барлар аны күрә ала,
Колаклары барлар ишетә.
Ә мин шушы сынык усак җырын
Әйләндерәм серле келәмгә.
Һәм уйларны төяп җибәрәмен,
Таралсын дип бөтен галәмгә.

**VIII**

Елга — ярсу симфония,
Дирижеры — таллар.
Мең төскә бай музыканы
Сыйдыра алмый ярлар.
Күккә сикерә миллион тамчы,
Нурга манып ярны.
Сибелә җиргә музыканың
Барлык ноталары.
Ә ноталар бик күп монда,
Түгел җиде генә.

Һәрбер тавыш бер төс булып
Сеңә күңелемә.
Күккә суза муеннарын
Басудагы гөлләр.
Тавышны төсләргә манып,
Нота яза җилләр.
Иң югары ноталарны
Ала былбыл гына.
Барып куна былбыл җыры
Таулар кыегына.
Елга-таулар, басу-кырлар —
Мәгърур симфония.
Таулар җырлый, алар да бит
Бас тавышка ия.

**IX**

Көтмәгәндә бер болытны
Яшен килеп кисте.
Таралды бөтен һавага
Тәмсез көек исе.
Бу ис йөрде җир өстендә
Булып кара шәүлә.
Кемнәрнеңдер гөнаһлары
Яндымы соң әллә?

**X**

Тауларның иң биегендә
Кызынып яттым.
Кулларны җәеп як-якка,
Болыт булып актым.
Күкнең зәңгәр диңгезендә
Чайкадым җанны.
Беразга бөтен тәннәрем
Җиңеләеп калды.

**XI**

Урманда аю, бүреләр
Беткән инде, беткән.
Тик тимер тешле аждаһа
Кимерә аны төптән.
Тимер аждаһа тавышы
Ачы, шомлы, зәһәр.
Һәрбер яфрак дер калтырап
Укый аңа каһәр.
Кара урманнар юк хәзер,
Ул агарып бара.
Кытыршы тел белән гүя
Ул яланып бара.
Кошлар оя корыр өчен
Урын таба алмый.
Тузган ояларның җирдә
Мамыклары ауный.
Ул мамыклар мышык-мышык
Елап ята төнлә.
Тишелмәгән йомыркалар
Ауный тирә-юньдә.

**XII**

Туган якларымнан китеп барыш,
Урылып беткән инде бодай, арыш.
Шәрәләнеп калган басу-кырлар,
Башка уйлар инде, башка сагыш.
Басу-кырга юеш җилләр хуҗа,
Юеш җилләр елак җырлар суза.
Җилләр тавышын ераккарак куып,
Тезелешеп ак торналар уза.
Кабалана-кабалана яшәп,
Гомер агышын ашыктыра кеше.
Җыр-моңнарга яңа төсләр өстәп
Кызулана җирнең әйләнеше.

*Баулы, 2003*

## ҮТКӘННӘРНЕҢ КАЙТАВАЗЫ ДА ЮК

Гел ашыктым. Белмәгән шул йөрәк
Алда нинди юллар көткәнен:
Балачакның баллы сукмакларын
Йөгереп кенә үтеп киткәнмен.

Кая инде артка борылып карау,
Ашкынулар алгач бөтереп.
Агымсулар юлны бүлсә әгәр,
Ярдан ярга чыктым сикереп.

Яшьлегемнең яшел урамында
Бик аз гына урап йөрелгән.
Яшен кебек яшьнәп килгән яшьлек
Кызлар кочагында эрегән.

Ә ул кызлар, ә ул кызлар инде
Мәхәббәтне күптән оныткан.
Хәтерләми алар яшьлеген дә,
Кочакларын җилләр суыткан.

Үткәннәргә карап уйланамын —
Яшьлек инде көлгә күмелгән.
Ичмасам, бер кайтаваз да килми
Ашкынулы сөю иленнән.

*2004*

## КАПКАЛАРНЫ АЧТЫМ МИН БҮГЕН

Күңел капкаларын ачып куйдым,
Ябылып ятулардан туелган.
Җырлый-җырлый җилләр килеп керсен
Һәм аерсын авыр уемнан.

Хәтер төпкелләрен актарсын да
Тузан катламнарын кубарсын.
Онытылган хатирәләр булса,
Бөтенесен өскә чыгарсын.

Була бик еш: сөеп туялмаслык
Гүзәл гөлләр кала күмелеп.
Тузаннарын җилләр килеп какса,
Карыйсың ул гөлгә сөенеп.

Капкаларны ачтым. Сайрар кошлар,
Очыгыз, оч сез дә иреккә.
Нинди генә матур тавышлар да
Тоныкланып кала читлектә.

Сезнең урын иркен урманнарда,
Сезнең өчен кысан бер күңел.
Җырлый-җырлый җилләр керсен әле,
Капкаларны ачтым мин бүген.

*2004*

## БӘЙРӘММЕ УЛ, ТҮГЕЛМЕ?

Туган көннәр кемгә — бәйрәм,
Кемгә — юк.
Шакымагыз, минем йөрәк
«Өйдә» юк.

Чыгып китте, ләкин кая? —
Белгесез,
Бәлки, аңа булгандыр бик
Күңелсез.

Туган көндә өен ташлап
Кем китәр?!
Йөрәк, сине аңламаслар
Бик күпләр.

Сорау арты сорау китәр:
— Ник качкан?
Мондый хәлнең булганы юк
Һичкайчан.

Саран диеп, карун диеп
Сүгәрләр.
Бәйрәменнән кача бары
Юләрләр.

Ни әйтәбез кешеләргә,
Әй, йөрәк?
Җиргә туу бәхетме ул,
Бир сөйләп.

*2004*

## ИПИ КИБЕТЕ

Тәрәз каршында
Ипи кибете.
Кер дә сайлап ал
Теләсәң күпме.
Агы кирәкме,
Яки карасы?
Йомшак һәм тәмле

Алар барчасы.
Ипи исләре
Җилгә тарала.
Ипи исеннән
Хәтер яңара.

Сугыштан соңгы
Иписез еллар...
Тырный җаннарны
Гүя ач җанвар.
Ул җанвар мәңге
Эчтә утыра.
Хәтта кайвакыт
Тәмам котыра.
Ничек онытылсын
Җанда ут чаклар.
Иснәр өчен дә
Ипи юк чаклар.
Сагышлы еллар,
Каргышлы еллар,
Коммунизмга
Барышлы еллар.
Тәрәз каршында
Ипи кибете.
Балачагымны
Кабат терелтте.
Кайтамын, имеш,
Мин кыр ягыннан.
Ике кесәгә
Борчак салынган.
Ачлык бураны
Эчләрдә дулый.
Хәтер давылын
Туктатып булмый.
Кайтып киләмен,
Кесәдә борчак.
Ашыйсы килә
Борчакны учлап.
Куллар кесәгә
Керергә тора.
Борчак авызда
Эрергә тора.
Үземне тыеп
Чабамын өйгә:
Бер уч сеңелгә,
Бер уч әнигә.
Өйдә бит әле
Апалар да бар.
Яңа борчакны
Алар да ашар.
Ә эчтә дулый
Ачлык бураны.
Күзләр яшьләнә,
Күрмим юлларны.
Кинәт бер шәүлә!..
Котларым качты.
Сыртыма төште
Сигезле камчы.
Елан чаккандай
Киттем тәгәрәп.

Корсакка басты
Бригадир Гарәф.
«Әһә! — диде ул. —
Борчак урладың?!
Үтерәм барлык
Борчак бурларын!
Нәселегезне
Корытачакмын!
Исән калсагыз,
Утыртачакмын!»
Сигезле камчы
Эшкә керештe.
Һәр суккан саен
Тәннәр бөреште.
Кесәләрдәге
Борчак чәчелде.
Йотты үләннәр
Ачы яшемне.
Бик озак яттым
Аунап чирәмдә.
Кошлар җыйналды
Минем тирәмдә.
Борчакларымны
Чүпләде алар.
Нигәдер очып
Китмәде алар.
Белмимен өйгә
Ничек кайтканны.
Әнием төнлә
Эзләп тапканмы?!
Бәлки, әнигә
Кошлар әйткәндер,
Тәрәзәбезгә
Борчак сипкәндер.
Кошлар бит бездән
Мәрхәмәтлерәк.
Очыра аларны
Канат һәм йөрәк.
Тәрәз каршында
Ипи кибете.
Балачагымны
Кабат терелтте.
Каргышлы еллар,
Сагышлы еллар,
Коммунизмга
Барышлы еллар,
Кадерсез еллар,
Бәгырьсез еллар,
Җаннарны әле
Бик озак тырнар.
Юкса табында
Гел ипи тора;
Балачак яше
Гел кипми тора.
Чөнки йөрәктә
Курку бар һаман —
Кайтмас дип булмый
Иписез заман.
Хокуксыз илдә,
Каргышлы илдә

Яманлык бик тиз
Әйләнеп килә.
Тәрәз каршында
Ипи кибете.
Балачагымны
Кабат терелтте.

*2004*

## БУ ЮЛЫ СИН ХАКЛЫ ИДЕҢ

Кояш кунган иде йөзләреңә,
Күкләр сыйган иде күзләреңә.
Түзалмадым: син бик чибәр, дидем.
Көнләшәдер синнән гөлләр, дидем.
Утлы карашыңны миңа атып:
Ялганлама, мин бик ямьсез, дидең.
Йоклатмакчы булып күңелемне
Алдашасың, син бик әрсез, дидең.
Әйтерсең лә мине яшен сукты,
Күкрәгемдә утлы давыл купты.
Ишеткән юк иде мондый җавап,
Яңгырады ул җанда кабат-кабат.
Әллә мине күзләр алдыймы дип,
Матурлыкны аңлый алмыйммы дип
Карадым мин сиңа тагын бер кат,
Юк, алдамый күзләр, сүзләрем хак.
Бөтен җирең синең килгән иде,
Юан толымнарың билдән иде.
Ходай сиңа матурлыкның барсын
Бер дә жәлләмичә биргән иде.
Күз алдыма килеп баскан чакта
Сылу гәүдәң, кояш кунган йөзең,
Яңгырап куя иде колагымда
«Мин бик ямьсез!» диеп әйткән сүзең.
Ә беркөнне тагын очраштык без,
Башың түбән иеп атлый идең.
«Күрәсеңме, мин бик ямьсез», — дидең,
Һәм бу юлы син бик хаклы идең.

*2004*

* * *

Үзе күктә,
Күләгәсе җирдә,
Әйтерсең лә оча ике бөркет.
Оясына посты бар куяннар,
Җирдәге шул күләгәдән өркеп.

Канатын да какмый үтте бөркет,
Эзе генә ярылып күктә калды.
Көне буе дер-дер калтырарга
Куяннарга шул да җитә калды.

Шушы куркак куяннар хәлендә
Без дә яшәп ятабыз гел өркеп.
Яшеренәбез күләгәдән өркеп,
Болай гына очса да бер бөркет.

*2004*

* * *

Ирләр иртәрәк китәләр,
Бу — билгеле хакыйкать.
Ирләр җаны аша үтә
Җирдәге күпме афәт.

Алар баш очыннан уза
Ут та, туп та, яшен дә.
Ирләр йөрәгенә тама
Хатын-кызлар яше дә.

Ирләрдә кан кайнаррак,
Хисләр дә тирәнрәк.
Күз яше дә суыта алмый,
Ирләр бит елый сирәк.

Ирләр иңендә ил гаме,
Ирләр — дөньяга терәк.
Дөнья исән калсын өчен,
Шартлап ярыла йөрәк.

Ирләр иртәрәк китәләр,
Булса да өч йөрәкле.
Хатын-кызны тотып тора
Мең төрле мәшәкате.

*2004*

* * *

Чәчәктәй үсеп чыгалар
Матур кызлар язларын.
Ләкин тотып буламыни
Һавадан кыр казларын.

Күкләргә ятьмә чөйсәң дә
Ефәк җепләрдән үреп —
Ятьмәне җиргә атарлар,
Тавышларына төреп.

Башны күккә чөя-чөя
Күпме генә карама —
Безгә каурый ташлап киткән
Казлар булмас арада.

Бу казлар башка язлардан,
Бу казлар бүтән төрле.
Алар оя корыр өчен
Сайлыйлар бүтән күлне.

Безнең казлар очкан инде,
Эзләре дә калмаган.
Башка казлар очып бара
Тезелешеп һавадан.

*2004*

## КҮЛӘГӘ ҺӘМ КОЯШ

Аландагы зур усак төбенә
Сузылып яткан ялкау күләгә.
Исе китми, усак яфраклары
Аннан шырык-шырык көлгәнгә.

Бераз гына черем итеп ала,
Ләкин бик сак аның йокысы.
Кояш күчсә — ул да шуыша башлый,
Кыенрак менә шунысы.

Кояшны һич сөйми, ләкин ансыз
Тора алмый үзе бер көн дә.
Яши алар фәрештә һәм иблис
Яшәгәндәй безнең күңелдә.

*2004*

* * *

Ялкауга мендәр кирәк,
Түрәгә мөнбәр кирәк.
Гашыйкларга кавышырга
Йолдызлы төннәр кирәк.

Ачларга икмәк кирәк,
Тукларга хикмәт кирәк.
Хакыйкатьне сөючегә
Куркусыз йөрәк кирәк.

Баш булгач, бүрек кирәк,
Тоткынга ирек кирәк.
Бөеклеген күрсәтергә
Халыкка хөрлек кирәк.

*2004*

* * *

Бик бай иде.
Шәп яшәде —
Хатын арты хатын алды.
Беркөн барсын оттырды да
Бернәрсәсез калды.
Асылынырга бауны хәтта
Күршесеннән алды.

* * *

Шәфәкъ вакыты.
Кояш байый.

Һәм җитәр эңгер-меңгер.
Учка салсаң, сыеп бетә
Бөтен яшәлгән гомер.

*2004*

## ШӘҺӘР ЧӘЧӘК АТАЧАК

Урамдагы һәр чокырга
Утыртып чыксак чәчәк —
Казаныбыз иң-иң гүзәл
Шәһәргә әйләнәчәк.
Чүп-чарларны кошлар итеп
Очырсак һаваларга —
Һәрбер турист исе китеп
Карар иде аларга.
Җимерек йортлар янына
Тезеп куйсак чыршылар,
Ул чыршыларны әйләнеп
Җырлап йөрсә җырчылар —
Әй мактарлар иде безне,
Дан китәр иде ерак.
Кунаклар йөрерләр иде
Татарча гына җырлап.
Онытылыр иде Парижлар,
Канар утраулары.
Казанга агылыр иде
Бөтен дөнья байлары.
Рәссамнар кәгазь кошларның
Рәсемен ясар иде.
Атаклы җырчылар килеп
Күңелне ачар иде.
Хәер, булыр, бар да булыр,
Юлларда гөлләр үсәр.
Һәр чокырда су җитәрлек —
Үсмичә кая китәр.
Күрербез әле, күрербез,
Казан чәчәк атачак.
Һәр чәчәк төбен «матурлап»,
Берәр шешә ятачак.

*2004*

## КИРӘК КҮҢЕЛ ӨЧЕН

Энә белән кое казыйм,
Шундый минем эшем.
Суы чыкмаслыгын беләм —
Казыйм күңел өчен.

Тауларга таба үрмәлим,
Җитмәсә дә көчем.
Тәгәрим дә тагын менәм —
Кирәк күңел өчен.

Яшь кызларга гашыйк булам,
Ташлап бөтен эшем.
Кабынулар һәм янулар
Кирәк күңел өчен.

Офыкларның ал төсеннән
Эзлим яшьлек төсен.
Таба алмасымны беләм —
Эзлим күңел өчен.

Җырлыйм кайчак, булмаса да
Һичбер тыңлар кешем.
Үз тавышыңны ишетү дә
Кирәк күңел өчен.

*2004*

* * *

Без инде көрәшеп туктадык,
Көрәшкә калмады көчебез.
Кармакка эләккән балыктай
Селкенми, тын гына яшибез.

Чәйнибез кармакның җепләрен,
Бәлки, бер өзелер җебебез.
Ирекле йөзүгә сусадык,
Бары тик без шуны телибез.

Кемнәрдер түзмичә ыргыла,
Өзмәкче булалар кармакны.
Андыйлар ычкына иреккә,
Кармакта калдырып саңакны.

Тик саңак өзелеп калгачтын,
Тын бетә, буыла сулышың.
Теш белән шартлатып өзәргә
Көч җитми кармакның корычын.

Яшибез гел шулай тын гына,
Авызда нык корыч кармаклар.
Әз генә читкәрәк тартылсак,
Ертыла, өзелә саңаклар.

*2004*

## БҮЛӘК

Бер кош килеп минем тәрәзәмә
Шундый матур итеп сайрады.
Безнең авыл кошы булды, ахры,
Моңы йөрәкләрне айкады.

Тәнемдәге бөтен күзәнәкләр
Уяндылар кинәт бу моңнан.
Юмарт җилләр армый ташып торды
Мең чәчәкнең исен болыннан.

Әйтерсең лә авылыма кайттым,
Баш әйләнеп китте хуш истән.
Рәхмәт, кошкай, моңнар өләшкәндә
Калдырмадың мине өлештән.

Көтмәгәндә гүя бүләк алдым,
Бүләкнең дә шундый зурысын.

Ыграк ачыйм әле тәрәзәмне,
Якты язлар өемә сыенсын.

Күкрәгемә язлар оя корсын,
Гел үз итеп, һәрчак яратып.
Иң беренче яшеннәрен язлар
Йөрәгемнән алсын һәрвакыт.

*2004*

* * *

Көтә кеше гомер буе,
Бәхет килер дип көтә.
Бәхет кошы бик биектән
Күренми очып үтә.

Көтә кеше гомер буе,
Кайнар мәхәббәт көтә.
Сөю килә дә җаннарны
Канлы җәрәхәт итә.

Көтә кеше гомер буе,
Дан һәм дәрәҗә көтә.
Дан-дәрәҗә килә, ләкин
Кешене җансыз итә.

Көтә кеше гомер буе,
Байлык килер дип көтә.
Байлык килә дә өеңә
Тик кунак булып китә.

Көтә кеше гомер буе,
Көтә, гел өмет итә.
Өмете өзелгәч кенә,
Кеше дөньядан китә.

*2004*

* * *

Син яшь былбыл.
Сайра бер дә тынмый,
Яңгыратып кара урманны.
Күтәр әле күкнең биегенә
Авырайган безнең уйларны.

Якынайсын бераз кояшкарак
Безнең хисләр, безнең өметләр.
Болытлардан югарырак булыйк,
Көнләшсеннәр әле бөркетләр.

Көнләшсеннәр офык артындагы
Каф таулары — әкият таулары.
Биеклекләр, чиксез киң офыклар
Кайнарласын безнең каннарны.

Күтәр, былбыл, күтәр җырың белән,
Безнең җаннар менсен биеккә.
Без бит бары хыял белән генә,

Хөр җан белән генә иректә.

*2004*

* * *

Бөтен нәрсә тора бәхеттән,
Бәхетең булса, була барсы да:
Биек-биек алтын сарайлар
Килеп баса синең каршыңа.

Килә байлык, килә дәрәҗә,
Нәрсә алма — шуннан уңасың.
Мәҗлесләргә барсаң әгәр дә,
Һәрвакытта түрдә буласың.

Кайгылардан башың иелми,
Күкрәк киереп горур йөрисең.
Биеклеккә бәхетең менгерә,
Зур көч куеп үзең менмисең.

Бар да тора, әйе, бәхеттән,
Бәхетлеләр очмый тәхеттән.
Тик бәхетне каян аласы?
Шуны белми адәм баласы.

Эзли җирдән, эзли күкләрдән,
Кайдан уза бәхет юллары?
Кешегә бит күп тә кирәкми,
Бәхет кенә кирәк нибары,
Бәхет кенә кирәк нибары.

*2004*

## ЯРДӘМ СОРАП

Авырлыклар билне бөккән чакта,
Нинди генә уйлар килми башка;
Кайвакытта ирләр генә түгел,
Елый таулардагы каты таш та.

Давыл йота көчле бөркетләрне,
Һаваларда калмый эзләре дә.
Күз яшьләре яна шарт-шорт итеп
Яшеннәрнең утлы күзләрендә.

Зәңгәр күктә җилләр чайкаса да,
Агарталмый кара болытларны.
Җылыталмый учак уты гына
Эчкә оялаган суыкларны.

Җирдән, судан, ерак галәмнәрдән
Кеше күңеле күпкә катлаулырак.
Тынгысыз җан сакта тора һәрчак,
Тик Алладан гына ярдәм сорап.

*2004*

## ҖАН ХӨРЛЕГЕ

Тормышта гел шулай булып тора:
Көтелмәгән эшләр чыгып тора.
Менә-менә эшлим дигән эшне
Көтмәгәне бәреп егып тора.

Юкка чыга корган уй-хыяллар,
Вәгъдәләрең үтәлмичә кала.
Әкрен-әкрен суыра сине язмыш
Үзенең кысан кочагына таба.

Без ирекле, без хөр, дип йөрибез,
Алданабыз шулай гомер бакый.
Тик ирекле берни юк бу җирдә —
Вакытыннан алда таң да атмый.

Ә шулай да үз сукмагы белән
Атлый бара кеше көне-төне.
Тормыш кысанлыгын ера-ера
Алга таба илтә җан хөрлеге.

*2004*

## ЮК ИНДЕ

Мәхәббәт сүзендә мең төс бар,
Мәхәббәт сүзендә мең ямь бар;
Юк инде сөюдә янасы,
Хисләрне төсләргә манасы.

Болында мең төрле гөлләр бар,
Гөлләрдә мең төрле серләр бар;
Юк инде серләрне ачасы,
Ябылган болыннар капкасы.

Төннәрдә мең төрле балкыш бар,
Күлләрдә мең төрле аккош бар;
Юк инде, йөзалмыйм күлләрдә
Зур гомер утыра иңнәрдә.

Як-якка күпме юл сузылган,
Йөгерә-йөгерә уз шуннан;
Юк инде, юк инде, юк инде —
Узасы юлларым узылган.

*2004*

## ТАПМАДЫМ

Еракта-еракта,
Хыяллар илендә,
Балачак сукмагы югалган.
Эзлимен — табалмыйм,

Телимен — баралмыйм,
Сукмакның очлары чуалган.
Табаным эзләрен
Күмгәнме кылганнар,
Кая соң, кая соң
Җиләкле урманнар?
Кая без аунаган
Кояшлы аланнар?–
Әйтерсең һәммәсен
Себереп алганнар.
Суларын без эчкән
Чишмәләр кая соң?
Дәвалый иде бит
Алар җан ярасын.
Барсы да башкача,
Барсы да үзгәргән.
Карыймын-карыймын —
Ышанмыйм күзләргә.
Имәннәр корыган,
Каеннар каралган.
Без йөргән сукмаклар
Як-якка таралган.
...Актардым-актардым
Хәтерләр катламын —
Хыяллар иленнән
Үземне тапмадым.

*2004*

* * *

Җәйге иртә. Җилләр йоклый әле,
Кош сайрамый хәтта, урман тын.
Чык тамчысы булып җыелып тора
Яфракларга сеңгән төнге моң.

Чәчәк таҗларында бал корты юк,
Җәнлек эзләре юк сукмакта.
Тынлык тавышы эчкә бер шом салып
Ишетелә ерак-еракта.

Уятырга теләп карурманны,
Бер сызгырдым ярып һаваны.
Сискәнешеп куйды бар агачлар,
Уянмаган яфрак калмады.

Куакларда кошлар сайраштылар,
Аланнарда гөлләр тирбәлде.
Иртәнге нур көзге күк йөзенә
Нота белән язды көйләрне.

Бер горурлык күчте күңелемә —
Уяттым бит кара урманны!
Изге эштер, уятсаң да хәтта
Йокымсырап яткан бер җанны.

*2004*

* * *

Сиздермичә генә

Җәйләр узып киткән.
Офык күзләренә
Сөрмә сызып киткән.

Ә көз — җиткән кыз ул,
Алмалары сутлы.
Сутлы алмаларның
Эчкәйләре утлы.

Карыйм алмаларга,
Алмаларда чык бар.
Кулларыңны сузсаң,
Учка тамар утлар.

Алмаларга үреләә,
Җилләр әрсез бик тә.
Алма җыючылар
Йөри никтер читтә.

Сиздермичә генә
Җәйләр үтеп киткән.
Чык тамчысы тама
Һәр алмадан иртән.

Утлы алмаларны,
Сутлы алмаларны
Килеп табарлармы,
Җилләр кагарлармы?!

*2004*

* * *

Сәясәт җилләре безне
Төрле якка бора.
Шул җилләргә карап күпләр
Исемен алмаштыра.
Исем үзгәргәч, җисем дә
Алмашына бик тиз.
Бар нәрсәне алмашырга
Яратабыз шул без.
Кемдер илен алмаштыра,
Ә кемнәрдер динен.
Иман кача, кыйблаң бетә,
Алмашына телең.
Алмашына җырлар, моңнар,
Алмашына гадәт.
Коела тешләр, чит-ятларның
Сагызларын чәйнәп.
Таркалабыз, вакланабыз
Әкрен-әкрен шулай.
Татарлыктан ваз кичәргә
Чыгып тора гел җай.
Милләтебез муенына
Салына шулай элмәк:
Өнсез генә, күндәм генә
Бәргәләнә милләт.
Онытырбыз, бәлки, тиздән
Татар исемен дә.
Ярым айлар тирбәнмәсләр

Күкләр бишегендә.
Сәясәт җилләре һаман
Бәрә йөзебезгә.
Ә без тышаулар ясыйбыз
Никтер үзебезгә.

*2004*

## ЯНАР ЙӨРӘК ТУРЫНДА ЛЕГЕНДА

Шундый бер йөрәк булган —
Гел янып, дөрләп торган.
Ялкыннары көн һәм төн
Күкләргә үрләп торган.
Янма, дигәннәр аңа,
Тукта, дигәннәр аңа.
Һич булмаса, төннәрен
Йокла, дигәннәр аңа.
Тыңламаган бу йөрәк,
Йокламаган бу йөрәк.
Бәргәләнгән, сугылган,
Ялкыннардан буылган.
Кызганнан-кыза барган,
Сызганнан-сыза барган.
Ялкыннарын күкләргә
Сузганнан-суза барган.
Йөрәк уты белән ул
Җылытам, дигән, дөньяны.
Ләкин аңламаганнар,
Санламаганнар аны.
Аптыраган табиблар,
Аптыраган халыклар.
Ут капмасын суга дип
Куркышканнар балыклар.
Чакыртканнар сихерче,
Әйткәннәр: киңәш бирче.
Нигә һаман яна ул,
Утны каян ала ул?
Сихерче уйга калган,
Йөрәк янган да янган.
Озак уйлана торгач,
Сихерче аңлап алган:
Бу гади йөрәк түгел,
Бу бит шагыйрь йөрәге.
Сихерчеләр барында
Шагыйрьнең юк кирәге.
Сихерче бик тиз генә
Аңгырайткан халыкны:
Бер көтүгә туплаган
Халык белән сарыкны.
Һәм шагыйрьнең йөрәген
Алган да үзе белән —
Кадаклаган кыяга
Сихерле сүзе белән.
Йөрәк инде янмаган,
Ул бары тик канаган.
Таулардагы еланнар
Аның канын ялаган.
Бөркетләр уйга калган,

Карап канлы йөрәккә.
Каргалар каркылдашкан
Җыелып бер төбәккә.
Канаса да, бу йөрәк
Чыгармаган зар-моңын.
Җырлаган сүзсез генә
Ирек турында җырын.
Тик бөркетләр аңлаган
Йөрәкнең сүзсез җырын.
Эзли башлаган алар
Аны коткару юлын.
Әйткән шунда карт бөркет:
— Йөрәк каный нилектән? —
Аны ташка кадаклап
Аерганнар иректән.
Без дә менә бөркетләр
Көчле бары иректә.
Чыпчыкка әйләнәчәк,
Хөр булмаса бөркет тә.
Әйдә, аны коткарыйк,
Кыядан чукып алыйк.
Ирекле булсын йөрәк,
Җырга да хөрлек кирәк.
Һәм бөркетләр җыелып
Тотынганнар зур эшкә:
Чукыганнар кыяны
Һәр иртәдә, һәр кичтә.
Бергәләшеп тотынгач,
Йөрәк чыккан иреккә.
Бөркетләр ул йөрәкне
Күтәргәннәр биеккә.
Инде җырла, дигәннәр,
Бер дә тынма, дигәннәр.
Әйт халкыңа сүзеңне
Һәрбер җырда, дигәннәр.
Җырлаган йөрәк һәр көн,
Басып ак болытларга.
Таралган аның җыры
Иң ерак офыкларга.
Ләкин теге сихерче
Йоклаткан булган барсын.
Йөрәк, күп тырышса да,
Уяталмаган халкын.
Йөрәк сызланган, арган,
Моңнары җиргә тамган.
Хәлсезләнгәчтен, йөрәк
Кояшка кушылып янган.
Сихер көче беткәчтен,
Халыклар да уянган.
Ләкин алар җанына
Нур сибүче булмаган.
Җанда ут тергезүләр
Катлаулы шул, хикмәтле.
Искә төшергән халык
Көн-төн янган йөрәкне.
Йөрәк турында сүзләр
Йөргән телдән телләргә:
Кемнәрдер күргән, имеш,
Аны чит-ят илләрдә.
Кемдер әйткән: ул — тургай,

Кояшка менеп киткән.
Яна-яна сайрап ул
Җырында эреп беткән.
Сүзләр төрле, сүзләр күп:
Имеш, ул булган бөркет.
Аны күргәч, патшалар
Качалар, имеш, өркеп.
Кемдер әйткән: ул үлгән,
Үлгәнен кояш күргән.
Легендалар йөрәкне
Йөз терелткән, йөз күмгән.
Янар йөрәк турында
Сүзләр гел артып торган.
Серле йөрәк үзенә
Чакырып, тартып торган.
Легендалар тагын да
Туар әле, күрерсез.
Шагыйрь йөрәге җырда,
Ә җырлар бит үлемсез.
Йөрәк уты — шундый ут,
Ул һәр җырның җанында.
Халык үлмәс, ил бетмәс,
Йөрәк уты барында.

*2004*

* * *

Тишек кесәдән коелган
Алтын тәңкәләр кебек
Коелып кала көннәрем,
Юл тузанына күмелеп.

Коела айлар, коела еллар,
Коела бөтен байлык.
Коелып калганын күрсәң дә,
Булмый шул җыеп алып.

Бишмәт тузды, гомер узды,
Ямап булмый кесәне.
Калды бары йөрәк кенә —
Алтынның зур кисәге.

Ул да төшеп калыр беркөн,
Кесәдә калмас берни.
Таптап китәрләр ансын да,
Йөрәк икәнен белми.

Бәлки, белеп тә таптарлар,
Әзме тапталган йөрәк!
Бездә бит йөрәкләр түгел,
Алтыннар кадерлерәк.

*2004*

## ОНЫТТЫМ ШУНЫ НИШЛӘП

Урамда бер бала да юк,
Кая китеп беткәннәр?

Әллә инде болыннарга
Чәчәк итеп сипкәннәр?!

Юкса көн дә шундый матур,
Уйнап кына торырлык.
Кояш көлә, һич сәбәп юк
Өйләрдә утырырлык.

Туплар да сикерми бүген,
Очмый кәгазь уклар да.
Ничектер боегып калган
Катлы-катлы йортлар да.

Этләр йөри аптырашып,
Аларга да ямь беткән.
Әйтерсең барлык баланы
Җилләр күтәреп киткән.

Бу ни хәл дип торган чакта,
Килеп әйтте бер песнәк:
— Бүген Беренче сентябрь!
Оныттың шуны нишләп?

*2004*

## УРАП БАРАМ КАЛӘМ ОЧЫНА

Көтмәгәндә хисләр өермәсе
Билләремнән бөтереп ала да
Чөя мине көчле кулы белән
Чиксезлеккә таба — һавага.

Очып йөрим болытлардан өстә,
Каера алмый җилләр канатны.
Бер яктан — Ай, ә бер яктан Кояш
Сыйпап китә минем яңакны.

Керфек очларымда нурлар уйный,
Күзгә тула күкләр яктысы.
Ут йомгагы булып йөрәгемне
Чорнап ала яшен чаткысы.

Ак канатлы фәрештәләр белән
Әйлән-бәйлән уйныйм, тилерәм.
Йолдызлардан йолдызларга басып,
Галәм юлы буйлап йөгерәм.

Чәчләремне Ай нурлары тарый,
Күкләр яме тула җаныма.
Диңгездәге ярсу дулкын кебек
Кагылам чиксезлекнең ярына.

Гомеремнең шундый мизгелләрен
Урап барам каләм очына —
Шигыремә хисләр өермәсе,
Күкләр биеклеге кушыла.

*2004*

## МИЗГЕЛ

Һәр иртәне сөенеп каршы алам,
Һәр яңа көн — яңа бер өмет.
Күзләремне ачып җибәрүгә,
Көн яктысы тула бөркелеп.
Күкрәгемне тутырып бер суласам,
Киңәйгәндәй була сулышым.
Бәлки, бу көн бәхет пәрдәләрен
Ачып куяр димен тормышның.
Шулай булсын, юлчы юлдан уңсын,
Эштәгеләр эштән уңсыннар.
Һәр кешегә бәхет капкаларын
Фәрештәләр ачып куйсыннар.
Уйларының очын җуючылар
Эзләгәнен табып сөенсен.
Мәхәббәтне юк дип йөрүчеләр
Олы мәхәббәткә тиенсен.
Һәрбер көннең яңалыгы була,
Охшаш булмый көннәр көннәргә.
Көчсезләргә көч өстәсен бу көн
Гомер баскычыннан менәргә.
Яхшылыкка юмарт булсын бу көн,
Ишекләрне кайгы какмасын.
Максатына барган һәрбер кеше
Өмет белән алга атласын.
Кайчагында хәтта язмышыңны
Хәл итә дә куя бер көнең.
Биеклеге, түбәнлеге сыя
Шул бер көнгә бөтен гомернең.
Бер көн бары мизгел генә димик,
Көнләп санап булмый мизгелне.
Яшик әле бүген тотам диеп
Кулларыма бәхет тезгенен.

*2004*

* * *

Балачакның баллы эзе инде
Күптән кояшларда янгандыр.
Калса, бары яшьлек җырым гына
Болытларга эленеп калгандыр.

Һавадагы кошлар юлы белән
Тезелешеп көннәр үткәндер.
Ул көннәрне энҗе-мәрҗән итеп
Диңгезләргә җилләр сипкәндер.

Агымсулар җитезлеген алып
Дулкыннарга илтеп салгандыр.
Гомер атым ак күбеккә баткан,
Чаба-чаба ул да аргандыр.

Кинәт кенә туктап калып булмый
Кызу чабып барган җиреңнән.
Акбүз атның тезгененнән тартып
Карап торам гомер үреннән.

*2004*

* * *

Бетми торып бу дөньяда
Гаделсезлек,
Үсә, арта барачак гел
Бәгырьсезлек.

Гаделсезлек, бәхетсезлек,
Бәгырьсезлек
Тудыра җиргә әшәкелек,
Кадерсезлек.

Божра булып ялганганнар
Болар бар да.
Ә шәфкатьне дулкын бәреп
Аткан ярга.

Бәргәләнә, чәбәләнә,
Гүя балык.
Мин ышанам, суга төшәр
Ул, көч табып.

*2004*

* * *

Кеше җиргә яшәр өчен килә,
Ә без көрәшәбез.
Өлешеңә дигән көмешең дә
Тими көрәшләрсез.

Тартышабыз бер-беребез белән,
Һәрчак нидер кирәк.
Симез калҗаны да ала гел-гел
Кемнән кем көчлерәк.

Калыная барган саен кесә,
Йодрыклар да үсә.
Ул йодрыклар көчсез бәндәләрнең
Башларына төшә.

Көчсезләр дә яшәр өчен туган,
Гомер бит бер генә.
Шул бердәнбер булган гомергә дә
Пычрак куллар үрелә.

Гел көрәшә, гел тартыша кеше
Шулай гомер бакый.
Көрәшә торгач чынлап яшәр өчен
Вакыты да калмый.

Ә бит кеше яшәр өчен туа,
Моңа һәркем хаклы.
Көрәшәбез, чөнки хакыйкать ул
Җиңүчеләр яклы.

*2004*

## ПОРТРЕТЛАР

Бер кулына бала җитәкләгән,
Бер кулында сыра шешәсе,
Авызында сигареты көйри
Бу — заманның «гүзәл» бикәсе.

Сумка аскан, арба тарткан булса,
Арбасында булса капчыгы —
Ак шәленнән танып алырсыз сез,
Бусы булыр татар карчыгы.

Көн-төн әгәр «джип»ларда чапса,
Нәни сумка булса кулында —
Ашыга, димәк, бу «гүзәл» зат шулай
Сөяркәсе көткән урынга.

Аякларын көчкә-көчкә сөйрәп
Кайтса берәү үзенең өенә —
Тормыш арбасын ул гомер буе
Тарта, димәк, ялгыз көенә.

Очып-очып йөрсә яшь гүзәл зат,
Иркәләтеп битен җилләрдән —
Димәк, әле аның канатлары
Мәхәббәттән бер дә көймәгән.

Урам гүя зур бер галерея,
Портретлар төрле стильдә.
Пумалаңны бары селтә генә,
Портрет калыр кәгазь өстендә.

*2004*

## ЮЛ БАШЫ

Без һәр көн кабат туабыз,
Тугач, дөнья куабыз:
Тегесе юк, бусы җитми,
Бөтен булмый дөньябыз.
Өең булса, көең булмый,
Ничек яшисең көйсез?
Бик күп сораулар каршында
Торабыз кайчак сүзсез.
Хакыйкатькә юлларны да
Гел кармалап эзлибез.
Тормыш вак-төяге белән
Томалана күзебез.
Батабыз да чүп-чарларга,
Юкка чыга олылык.
Иң самими хисләребез
Бетә юлда коелып.
Бетә шәфкать һәм мәрхәмәт,
Бетә җанда юмартлык.
Усаллык керсә күңелгә,
Үлә эчеңдә шатлык.
Алла безнең һәммәбезне
Олы итеп яраткан.
Ярдәм итешеп яшәргә
Куллы итеп яраткан.
Байлык, бәхет, олылыкны

Эзлибез никтер читтән.
Ә бит барсына юл китә
Үзебезнең йөрәктән.
Биеклеккә, олылыкка
Акыл, йөрәк — юл башы.
Хәзинәңә ачкыч тапсаң,
Дөньяда җитә барсы.

*2004*

## АК МОҢНАР

Уңыш миңа шундый авыр килә,
Җиңү килә озак көттереп.
Учка җыям бәхет орлыкларын,
Ялкыннарда җанны өттереп.

Киләчәкнең бүгенгедән һич тә
Җиңел булмаслыгын белсәм дә —
Ак уйларны төйнәп куяр өчен,
Ак кулъяулык йөртәм кесәмдә.

Очрап куйса татылмаган хисләр,
Йөрәк дигән сандык гел ачык.
Керсен алар серле сандыгыма,
Йөрмәсеннәр читтә адашып.

Дулкын-дулкын булып бәрелә йөзгә
Үткән елларымның сулышы.
Шөкер әле, җилләр аударалмый
Мәхәббәттән корган куышны.

Күзләремә эңгер эленсә дә,
Ят итмиләр әле ак уйлар.
Чиксезлекнең ерак офыгына
Таралалар җаннан ак моңнар.

*2004*

* * *

Без мылтыклардан куркабыз,
Дерт итеп куя йөрәк.
Ә бит мылтыклардан түгел,
Кешедән курку кирәк.

* * *

Туганда ул бик зур булып туды,
Пәһлеван булыр дип көттеләр.
Ләкин ул бер кәрлә булып үсте,
Акланмады көткән өметләр.

* * *

Агымсулар аша чыга кеше,
Җиңә алмый аны мең дулкын.
Барсын җиңдем диеп тынычлангач,

Кабып йота аны бер упкын.

* * *

Ялганнар күбәйгән саен,
Чынга ышану кими.
Чөнки кеше ялганнардан
Чынны аера белми.

* * *

Чын шагыйрьләр күп булалмый алар,
Чын шагыйрьләр туа йөзгә бер.
Шул йөзгә бер туган шагыйрьләрнең
Булсак иде берсе без дә бер.

* * *

«Аерса безне аерыр
Бары тик үлем генә» —
Шулай дигән идең берчак
Җан өреп күңелемә.

Аерылдык. Икебез дә
Әлегә исән-саулар.
Араларда үлем түгел,
Арада тора таулар.

* * *

Карый-карыйм — күрә алмыйм
Һавадан кошлар эзен.
Ярый әле үткенлеген
Җуймаган күңел күзем.
Кошлар юлы — ап-ак агым,
Агымда яшьлек чагым.

* * *

Яна-яна арыдым инде
Мәхәббәт утларында.
Вакыт җитте ашкынудан,
Янудан тукталырга.

Аңладым мин: мәхәббәт ул
Пүчтәк кенә эш икән.
Шушы «пүчтәк» кенә эштә
Безнең бөтен көч икән.

*2004*

## ИКЕ ТАВЫШ

Язган шигырьләрем ошамаса,
Кәгаземне атам йомарлап.
Очалмаган кошлар тавышы белән
Ята кебек алар кыйгаклап.

Йөрәкләргә килеп бәрелә дә
Әрнүләрдән туган бу тавыш —
Һич көтмәстән кайнар божра булып
Тынны буа башлый бу сагыш.

Әйтерсең мин хисләремне түгел,
Көннәремне ертып ыргытам.
Болай да бит гомер шундый кыска,
Болай да бит гомер бер тотам.

Ә идәндә йомарланган кәгазь
Һич кимеми, никтер ул арта.
Күккә карыйм, кошлар тавышы булып
Шат авазлар керә колакка.

Ике тавыш ике якка тарта,
Үткәннәрнең тавышы көчлерәк.
Шушы тавышларның тартышыннан
Бер ярылыр, ахры, бу йөрәк.

*2004*

## КАРТ ЮКӘ

Тәрәзә каршымда карт юкә,
Ул инде миннән нык өлкәндер.
Аның да башларын чалартып
Гыйбрәтле күп хәлләр үткәндер.

Тәрәзә каршымда карт юкә,
Шәһәргә күчкән ул урманнан.
Ботаклар чуалган, сыгылган
Ниндидер билгесез уйлардан.

Тәрәзә каршымда карт юкә,
Әле кыш. Юкәне бәс сарган.
Бәсләрен тын белән эретсәң,
Яз исе килер күк аңардан.

Тәрәзә каршымда карт юкә,
Күзәтә шау-шулы урамны.
Ә бәлки, исенә төшерәдер
Яшьлеген үткәргән урманны.

Тәрәзә каршымда карт юкә,
Һәр көнне аңарга күз салам:
Язларны, җәйләрне, көзләрне
Гел бергә каршылыйк без һаман.

Тәрәзә каршымда карт юкә,
Тын гына, моң гына яз көтә.
Бәсләргә төренгән бөреләр
Былбыллар тавышын ишетә.

*2004*

## УРАМ ШАВЫ

Тәрәзәдән урам шавы керә,
Күнегелгән инде моңарга.
Ашкындырып тыныч күңелемне
Урам тавышы сеңә уйларга.

Тәрәзәдән урам шавы керә,
Көндезен дә керә, төнен дә.
Коена шәһәр тавыш дулкынында,
Йөзә йортлар тавыш күлендә.

Тәрәзәдән урам шавы керә,
Әйтерсең лә урман шавы ул.
Тавыш тынса, шәһәр үләр кебек,
Тавыш, ахры, шәһәр җаны ул.

Тәрәзәдән урам шавы керә,
Урам шавы — вакыт агышы.
Ияреп шул шәһәр тавышына,
Гомерләрнең үтеп барышы.

*2004*

## НИ БУЛДЫ

Кичә генә җылы, аяз иде,
Кара төнгә сыенып кыш килгән.
Йөгереп кенә сиңа барыйм дисәм,
Казан урамнарын кар күмгән.

Кар астында калган бөтен шәһәр,
Сиңа илткән юллар югалган.
Карап торам кара буран аша,
Уй-хисләрем тәмам чуалган.

Бара алмыйм бураннарны ерып,
Күзләремә тула салкын кар.
Торараштай катып басып торам,
Богауланган гүя аяклар.

Мин бит кышка әзер түгел идем,
Көтмәгәндә килде кар-буран.
Безнең эзләр җәйдә калды инде,
Ул эзләргә буран ау корган.

Үз-үземне аңлый алмыйм әле,
Буран гынамы соң сәбәпче:
Нәрсә булды миңа, нәрсә булды,
Әгәр белсәң, йөрәк, йә, әйтче?

*2004*

## ИРЕКЛЕ ИЛ

Бомжлар йөри шәп-шәрә,
Андыйлар күп урамда.
Яшерен җиргә гәзит яба

Алар, кеше узганда.
Кайчагында җил чыга да
Гәзитне алып ата.
Хатын-кызлар очрап куйса,
Сүз куба шушы хакта.
Тфү! Оятлары качкан,
Күрегез бу ирләрне!
Булса иде хет, ичмасам,
Күрсәтердәй җирләре.
Менә безнең байлыгыбыз
Түштә генә ике пот.
Һәм китеп бара хатыннар,
Түшкәйләрен уйнатып.
Бомжларның исе китми
Андый гына байлыкка.
Һәрнәрсәгә кызыгып йөрсәң —
Нәрсә булмас халыкта.
Алар этләр белән бергә
Азык эзли урамда.
Ырлашып та киткәлиләр,
Бүлешер нәрсә булганда.
Хәерчеләр дә үреләә
Алар тапкан ризыкка.
«Ирекле» илдә яшәве
Бик рәхәт тә, кызык та.

*2004*

## СЫНАЛГАН ХАЛЫК

Утта сыналган халык без,
Суда сыналган халык.
Алтын тәхеткә утырып
Мең кат зурланган халык.

Гасырлар кичкән халык без,
Зур яулар кичкән халык.
Кырылсак та, кырга сибелеп,
Гөл булып үскән халык.

Җиңүләр күргән халык без,
Җиңелүләр күргән халык.
Җиңелсәк тә, тезләнмичә
Төз басып йөргән халык.

Телен саклаган халык без,
Динен саклаган халык.
Күңелендә зур тарихның
Өнен саклаган халык.

Ирек яраткан халык без,
Хөрлек яраткан халык.
Гигантлар үскән җирләргә
Орлык тараткан халык.

Үлмәс әле, мәңге үлмәс
Хәтерен җуймаган халык.
Киләчәккә шушы Хәтер
Барачак безне алып.

Маңкортлар түгел бит без,
Бик зур хәтерле халык.

*2004*

## ЯШӘҮ КИРӘК

Ничә гасыр буе халкыбызны
Буа килде тарлык, кысанлык.
Туар әле, бәлки, шундый бер көн
Чиксезлектә ярсып очарлык.
Дәртең дә бар синең, дәрманың да,
Канатларың әле сынмаган.
Утлы еллар синең ныклыгыңны
Кабат-кабат килеп сынаган.
Яшь бөркетләр канат ярып тора,
Оялар буш түгел кыяда.
Һәр халыкның үз биеклеге бар,
Үз тамырлары бар дөньяда.
Һичбер халык «кече» була алмый,
Зур да була алмый үзеннән.
Бара дөнья кабат-кабат басып
Үткән заманнарның эзеннән.
Йолдызлар да хәтта бәрелешә,
Урын җитми күктә аларга.
Яна алуыңа сөенеп юкса
Янарга да инде янарга.
Юк шул, юк шул — бәрелешләр бетми,
Кемдер кемгә кылыч уйната.
Бер йолдызы гына сүнгәндә дә
Дөнья камиллеген югалта.
Зур галәмдә без дә бер йолдыз бит
Атылмаган, ватылмаган да.
Телебезне, динебезне саклап
Барабыз без килер заманга.
Өзелеп калсак әгәр шул чылбырдан,
Камиллеге кимер галәмнең.
Без һәммәбез тигез балалары
Анабыз — Хава, атабыз — Адәмнең.

*2004*

## ХӘЗЕР ИНДЕ ШУНДЫЙ ЯШӘҮ КИРӘК

Менә тагын бер ел гомеребез
Чиксезлеккә кереп югалды.
Һавадагы аккош юлы кебек
Беленер-беленмәс кенә эз калды.
Шәфәкъ нурларында сөю янды,
Яфрак булып көннәр коелды.
Дәртле хисләр, тыйнаклана төшеп,
Йөрәк түренәрәк сыенды.
Танымыйлар күпләр тавышымны,
Тавышымның төсе үзгәрде.
Әле ярый еллар күрми үтте
Очкынланып торган күзләрне.
Калды тагын җанның кайнарлыгы,
Яшеренсә дә бераз тирәнгә.
Соклана һәм сөенә алам әле
Болындагы матур гөлләргә.
Калды әле эшли алу бәхете,

Яшәү тәме калды телемдә.
Өмет булып кояш калкып чыга
Ходайның һәр бирмеш көнендә.
Яңа көнне сөенеп каршы алу
Һәм озатып калу кичләрен —
Яшәвеңә яңа мәгънә өсти,
Күп төсләргә байый хисләрең.
Әйе, тагын бер ел үтеп китте,
Шактый гына көчне суырып.
Хәзер инде шундый яшәү кирәк —
Һәрбер көнең елга торырлык.

*2005*

* * *

Бер сорауга җавап эзлим:
Нәрсәдә соң яшәү яме? —
Җаның биреп эшләүдәме,
Шәп йортларда яшәүдәме,
Дөньяң онытып сөюдәме,
Күп гыйлемнәр белүдәме,
Әллә инде белгәнеңне
Башкаларга бирүдәме?
Нәрсәдә соң яшәү яме? —
Зур урынга үрләүдәме,
Яну, көю, дөрләүдәме?
Җырың белән, моңың белән
Йөрәкләрне биләүдәме?
Нәрсәдә соң яшәү яме? —
Алудамы, сатудамы,
Байлыкларың артудамы,
Әллә инде аңга килеп
Үз-үзеңә кайтудамы?
Нәрсәдә соң яшәү яме? —
Дусларың күп булудамы,
Сөйгән ярдан уңудамы,
Һәрбер аткан таңга сөенеп,
Күзләргә нур тулудамы?
Нәрсәдә соң яшәү яме? —
Гел матурлык эзләүдәме,
Әллә көчтән килгән кадәр
Туган җирне бизәүдәме?
Нәрсәдә соң яшәү яме?

*2005*

## БЕР ӨМЕТ

Көн тудымы, әллә niләр булыр төсле,
Куеныма былбыл килеп сыеныр төсле.
Куендагы шул былбылның моңнарында
Бөтен дөнья рәхәтләнеп коеныр төсле.

Көн тудымы, әллә ниләр булыр төсле,
Учларыма күктән алма коелыр төсле.
Ул алмалар, бәхет агачыннан өзелеп,
Алларымда тау-тау өелеп торыр төсле.

Көн тудымы, әллә ниләр булыр төсле,
Яннарымда дуслар җыелып торыр төсле.
Дусларымның җан җылысын тою белән,
Тәнемдәге авыруларым коелыр төсле.

Көн тудымы, әллә ниләр булыр төсле,
Сугышлардан дөнья кинәт тыелыр төсле.
Корыган агач яфрак ярып җибәрер дә,
Ботаклары җимешләрдән сыгылыр төсле.

Көн тудымы, әллә ниләр булыр төсле,
Явызлыкка чик-киртәләр куелыр төсле.
Күңелләрдә иман, вөҗдан уяныр да
Бөтен инсан бер Аллага сыеныр төсле.

*2005*

## КУНАК

Зур кунак көтә хуҗалар,
Өйдә ыгы-зыгы купкан.
Көмеш кашык, затлы савыт
Шкаф түрләреннән чыккан.
Өстәлдә чиккән ашъяулык,
Күзнең явын алып тора.
Чәчәкләре гүя тере,
Җем-җем итеп янып тора.
Кая карама — чисталык,
Бар тәрәзәләр юылган.
Чиста тәрәзәләр аша
Өйгә кояш нуры тулган.
Бала-чагалар мәш килә,
Өйдә күңелле мәшәкать.
Хатын өчпочмак пешерә
Каз итеннән бик тә тәмләп.
Ә аш инде күптән кайный,
Казан килә гөбер-гөбер.
Ап-ак оннан токмач җәелә, —
Озакламый кунак килер.
Ир һәм хатын икәүләшеп
Әзерлиләр бик бай табын.
Күңелләре күтәренке,
Онытканнар аруларын.
Сый-нигъмәтләр куелып беткәч
Карыйлар читкәрәк китеп:
«Бар нәрсә дә куелганмы,
Тезелгәнме матур итеп?!»
Бик канәгать кала алар,
Табын матур булган бик тә.
Сәгать суга доң-доң итеп,
Кунак килер вакыт җитә.
Хуҗаларның йөрәкләре
Сәгатьтән дә ныграк суга:
«Токмач куерып бетәр инде,
Кунак калып килсә соңга».
Вакыт күбрәк үткән саен,
Сәгатькә күз ешрак төшә.
Өчпочмаклар суына башлый,
Аш куера пешә-пешә.
Ир һәм хатын сүзсез генә
Утыралар урындыкка.
Сәгать суга кичке унны,
Көтүләргә куеп нокта.
Хуҗабикәнең күзләрен

Ирексездән яшь чылата.
Ире аны кочып алып
Яшен сөртә һәм юата:
«Кайгырма син, хатынкаем,
Яшең түкмә юк-бар уйлап.
Үзен аштан өстен куйгач,
Зур булмаган, димәк, кунак.
Йә, әйдәгез, утырышыйк,
Бу дөньяда без дә кунак.
Кайчагында үзеңне дә
Кунак итү кирәк зурлап».
Һәм балалар ябырыла
Өстәлдәге сый-нигъмәткә.
Әкрен-әкрен чума сыйлар
Корсак дигән зур чүлмәккә.
Эт тә туя, мәче дә тук,
Онытыла кунак гаме.
Күздән ачы яшьне сөрткәч,
Күренә башлый дөнья яме.

*2005*

## ӘТӘЧ ЕЛЫНДА

Килә этәч елында бер
Әтәчләнеп аласы:
Мин бар әле, мин исән, дип,
Таңда аваз саласы.

Уятсын минем тавышым
Авылның тавыкларын.
Исләренә төшерсен бер
Дәртле, яшь вакытларын.

Яшь этәчләр көнләшсеннәр:
«Кара син бу картлачны!
Таңнан да иртә кычкырып
Хур итә безнең башны.

Болай булса, безне онытыр
Бөтен тавыкларыбыз.
Тоныкланыр, йотылып калыр
Безнең тавышларыбыз».

Кычкырыйм әле, кычкырыйм,
Күрсәтим көч барлыгын.
Уятыйм әле авылның
Йоклаган бар тавыгын.

Әтәч елында килә бер
Әтәчләнеп аласы.
Әтәчләнеп аласы да
Алтын күкәй саласы.

*2005*

## ТЫНЛЫК ТАВЫШЫ

Төн уртасы.
Йоклый алмый ятам.
Өйдә бары тынлык тавышы.

Караңгылык, куе караңгылык
Буып куйган вакыт агышын.

Тынлык тавышы,
Шомландыргыч тавыш,
Колагыма минем пышылдый:
«Эре дә син минем кочагымда,
Бөтенләйгә миңа кушыл, — ди. —

Януларың, көюләрең бетәр,
Газапларың бетәр, сагышың.
Гармония — тик тынлыкта гына,
Тынлык кына кирәк җан өчен.

Җирне, күкне хәзер тавыш басты,
Кушылып бетте тавыш тавышка.
Кеше белән кеше генә түгел,
Туплар белән туплар ярыша.

Бу тавышка артык түзалмыйча,
Җир йөрәге шартлап ярылыр.
Барсы тынгач, җирдә тик бер тавыш,
Тынлык тавышы калыр барыбер».

Бу сүзләрдә хаклык бар шикелле,
Тик йөрәкне булмый тыңлатып.
Тынлыкны ул читкә куар өчен
Катырак тибә башлый «тук» та «тук».

Һәм чынлап та ераклаша миннән
Җан өшеткеч тынлык тавышы.
Уяна аң, кызулана башлый
Тамырларда канның агышы.

Төн авыша таңга.
Чигәм буйлап
Утлы уйлар үтә яндырып.
Арып-талып мин йокыга китәм,
Йөрәгемне сакта калдырып.

*2005*

* * *

Авырып яттым.
Минем сулышымнан
Офыкларга утлар капты.
Һәм болытлар
Зәңгәр күк юлыннан
Яна-яна акты.
Йөрәк тибүеннән
Җир тетрәде.
Болыт болытка бәрелеп,
Күк күкрәде.
Сулар ташып акты,
Ә дулкыннар
Ак күбеккә батты.
Күкрәгемнән минем
Кайнар вулкан атты.
Яндым, көйдем —
Тәмам өтелеп беттем;

Аңкауларыма ябышып
Телләр кипте.
Сүзләр авызда үлделәр
Бәргәләнеп, әрнеп.
Аера алмады акылым
Кайда шәрык, кайда гареп.
Менә беркөн
Утлы болытларны
Җилләр куды.
Аң яктырды.
Мин исән, дип,
Йөрәк тибеп куйды.
Тәнем буйлап
Дулкын үтте,
Иркен сулыш алдым.
Әй сөендем,
Авыруымны
Дуслар белми калды.
Ә белсәләр,
Һәм белеп тә килмәсәләр,
Авыр булыр иде бигрәк.
Җиңелеп куяр иде, бәлки,
Чирне җиңгән йөрәк.
Йөрәккә, сизгер йөрәккә
Күпме кирәк,
Күпме кирәк!
*2005*

* * *

Карт агачларны кисәләр! —
Таралган шундый хәбәр.
Карт агачларны кискәчтен
Яшәрә, имеш, шәһәр.

Карт агачларны кисәләр,
Җилдә авулары бар.
Яки яшен чаткысыннан
Дөрләп янулары бар.

Карт агачларны кисәләр,
Шәһәрне матурларга:
Киңлек җитми, мәйдан җитми
Яңа йорт һәм юлларга.

Карт агачларны кисәләр,
Карга өере күктә.
Каркылдаша алар: «кар, кар —
Ояларыбыз бетә».

Карт агачларны кисәләр! —
Таралган шундый хәбәр.
Төрле уйлар килеп башка,
Чымырдап куя тәннәр.

Бәлки, бу әйбәт гамәлдер!
Дип юанмакчы булам.
Ләкин һич арына алмыйм
Шөбһәле, шомлы уйдан.
*2005*

## ЭШ ТӘМЕ

Бик ешаеп китте бу бәйрәмнәр,
Тормыш тора гүя гел туйдан.
Атнасына ун көн бәйрәм ясап
Котылмакчы кеше гамь, уйдан.

Бәйрәм хөрмәтенә шәраб алып
Саекса да безнең кесәбез,
Үзебезне корбан итә-итә,
Ил баесын өчен эчәбез.

Ил яшәсен, әйдә, ил бай булсын,
Ил алдында кеше бер бөҗәк.
Атнасына ун көн бәйрәм булса,
Бөҗәкләр дә кырылып бетәчәк.

Бәйрәмнәр күп, әйе, артыгын күп,
Бәйрәмнәргә бәйрәм ялгана.
Эш атыннан чабышкылар ясап,
Сабантуйга чакыра замана.

Болай да бит җирдә эшсезләр күп,
Аларга ник синең бәйрәмең?!
Эшле кешене дә эшсез итеп
Бетермәскә иде эш тәмен,
Киметмәскә иде җир ямен.

*2005*

## ШУНДЫЙ СУГЫШ

Тәрәзәмне ачып җибәрүгә
Керә шәһәр исе.
Урам исе барлык хушбуйлардан
Мең мәртәбә көчле.

Күкрәкләрне тутырып сулыйбыз без
Һәркөн урам исен.
Иртән дымлы аксыл булса да ул
Зәңгәрләнә кичен.

Без каядыр ашыгабыз һаман,
Сизмибез дә исне.
Үзебез аша үткәрәбез барсын,
Шулай тиеш төсле.

Шәһәрләшеп беттек тәмам —
Урбанизация.
Кемдер әйтер, бәлки, бу бит, дуслар,
«Корбанизация».

Һәр заманның үзенең корбаннары,
Шулай бара тормыш.
Гомер буе җирдә дәвам итә
Мылтыкларсыз сугыш.

*2005*

## ШУНДЫЙ КӨН

Бүген минем шундый көнем:
Берни эшлисе килми.
Каләм алып, шигырь язып,
Җанны көчлисе килми.

Бүген минем шундый көнем:
Хәтта уйлыйсы килми.
Кошлар сайрыйлар агачта,
Минем тыңлыйсым килми.

Бүген минем шундый көнем:
Күзгә рәшә эленгән.
Салкын, кара күләгәләр
Ургып чыга күңелдән.

Бүген минем шундый көнем:
Хыял атым арыган.
Җилфердәтми ялкын-ялын,
Башы түбән салынган.

Бүген минем шундый көнем:
Күңел буш җырдан, моңнан.
Шулай тынып кала бары
Дөнья давыл алдыннан.

*2005*

## АНА ҖЫРЫ

Әй балам, балам,
Балам — гөл генәм.
Керфекләреңә
Нурлар эленгән.
Бер битең — Кояш,
Бер битеңдә — Ай.
Талпынасың син
Гүя бер тургай.
Алтыным да син,
Көмешем дә син.
Бәгыремдә үскән
Җимешем дә син.
Йомшак тәпием,
Назлы нәнием.
Ике фәрештәң
Әти-әниең.
Ап-ак мамыктай
Синең тәннәрең.
Үзеңә җыйгансың
Дөнья ямьнәрен.
Әй балам, балам,
Күзем карасы.
Наздан яралган
Сөю алмасы.
Карыйбыз сиңа
Күз тимәсен дип.
Саклыйбыз сине
Җил тимәсен дип.
Йоклаган чакта

Бик еш көләсең.
Бәлки, бик матур
Төшләр күрәсең.
Төшләрең кебек
Булсын өнең дә.
Шатланып яшә
Һәрбер көнеңдә.
Кояш нур җәйсен
Синең юлыңа.
Бәхетле бул син
Гомер буена.

*2005*

* * *

Язмаган шагыйрьләр бар
Һәм язган шагыйрьләр бар.
Язмаганнар — «даһилар»,
Язганнары — «гадиләр».

* * *

Яшьләр белән яшәрәм мин,
Картлар белән картаям.
Картаймагыз әле, картлар,
Яшьлектә калыйм һаман.

* * *

Елмаеп сөйләшсә берәрсе,
Ачылабыз, китәбез чишелеп;
Елмайган иреннәр эчендә
Елан-тел ятуы мөмкин бит.

* * *

Гомере буе бик тырышып
Кояштан тап эзләде.
Кояштан тап табалмады —
Сукырайды күзләре.

*2005*

## ЧАКЫРА БАЛАЧАГЫМ

Кайтып барам балачакка
Хәтерем юлларыннан.
Чаба болын чәчәкләре,
Җитәкләп кулларымнан.

Ашкынуларым күчкәнме
Җәйге уйнак җилләргә —

Йөгерә-йөгерә киләләр дә
Уралалар билләргә.

Хисләр яшен булып уйный,
Җан тургай булып оча.
Ак каеннар, каршы чыгып,
Кайнар кулымны кыса.

Иңнәремә былбыл куна,
Кояш тула күзләргә.
Чык тамчылары тәгәри
Минем баскан эзләргә.

Кайтып барам балачакка,
Күңел шунда тартыла.
Хатирәләрне яңартып,
Күктә яшен атыла.

*2005*

## НАЗ

Ашкынулы ярсу хисләр белән
Көтеп алам һәрбер язларны.
Язлар килгән саен яңаралар
Әти-әниемнең назлары.

Җәйге кояш җылы нуры белән
Битләремә китсә кагылып —
Искә алам, әти, әни, сезнең
Рәхәт назыгызны сагынып.

Бакчаларда алма өлгергәндә,
Шаулаганда иген кырлары —
Күргән кебек булам ипи тоткан,
Әти, әни, сезнең кулларны.

Яңа гына яуган йомшак карда,
Күзләр камашырлык сафлыкта —
Чагыла сезнең якты йөзләрегез
Һәм кушыла шушы аклыкка.

Җәйләр миңа күпме ямен бирде,
Каршыладым күпме язларны.
Ләкин берни алмаштыра алмый,
Әти, әни, сезнең назларны.

Рәхмәтем зур сезгә, әти, әни,
Ул рәхмәтем кайнар канымда.
Кая гына китеп барсам да мин,
Назыгыз йөри минем җанымда.

*2005*

## ПУЛЯНЫҢ КАЛМАДЫ КИРӘГЕ

Нәрсәдер шартлады урамда,

Юлларга пыяла коелды.
Әллә ни арада бер төркем
Кораллы солдатлар җыелды.

Ишекләр каерып ачылды,
Җентекләп каралды һәр фатир.
Кем белә: әбиләр, бабайлар
Шартлаткыч әзерләп ятадыр.

Бик теләп эзләсәң, әлбәттә,
Эзләгән әйберең табыла бит:
Карт солдат өеннән таптылар
Бүреккә салынган пистолет.

Ул аны фронтта вакытта
Алды бер әсирнең кулыннан.
Һәм сугыш беткәнче саклады
Чыгармый бер дә үз куеныннан.

Сугышта хәлләр тиз үзгәрә,
«Капкын»га калуың бар эләгеп.
«Ирекле» булырга мөмкин бит,
Чигәңә бер пуля җибәреп.

Сугыштан кайтты ул тетелеп,
Сызлаулар суырды җелеген.
Ничә кат мендәре астыннан
Капшады ул иске бүреген.

Тик түзде: белсә дә үзенең
Беркемгә кирәкле түгелен.
Бәлки, бер рәтләнер дөнья, дип
Юатты үзенең күңелен.

...Һәм бүген корычтай ике кул
Солдатны кубарды ятактан.
Кургаштай бик авыр тамчылар
Тәгәрәп төштеләр яңактан.

«Террорист, — диделәр солдатка, —
Кем бирде сиңа бу коралны?
Әйт, юкса кабереннән кубарып
Атарбыз атаңны, анаңны».

Солдатның типтеләр эченә,
Пуляның калмады кирәге.
Рәхимсез дөньяга рәнҗүдән,
Тибүдән туктады йөрәге.

*2005*

## ФЕВРАЛЬ БУРАНЫ

Улый февраль бураны,
Җир гүя кар урманы.
Ишетелә бар яктан
Карт бүреләр улавы.

Кояш та юк, Ай да юк,
Бар да карга күмелгән.
Котыра җил — диктатор,
Башлар түбән иелгән.
Бу явыз көч һәммәсен
Екмакчы һәм измәкче —
Ясамакчы дөньяны
Коллар империясе.
Кыюланып күз ачсаң,
Кар тондыра күзеңә.
Әгәр инде төз бассаң,
Китереп «тибә» тезеңә.
Уйларга ирек бирми,
Аңыңны саташтыра.
Йомык күзле колларны
Юлларда адаштыра.
Ышыкланыр урын юк,
Бигрәк яман бураны.
Әйтерсең җил бау ишә
Буар өчен дөньяны.
Тик шул гына җылыта —
Буран түгел мәңгелек.
Җил туктар, кояш чыгар,
Җир өстенә ямь биреп.
Ләкин шушы буранда
Адашмый калу кирәк.
Билебезне турайтып,
Төз басып бару кирәк.

*2005*

## АГЫМСУДА АГЫП БАРА

Ашыгабыз, абынабыз,
Сөртенәбез.
Үткән җилгә йодрык янап
Сүгенәбез.

Баралмыйбыз алга таба,
Чигенәбез.
Килеп җиттек текә ярның
Читенә без.

Тамырларны умырып-умырып
Агым ашый.
Ботакларны җил каерып
Суга ташлый.

Убыла ярлар, егыла таллар,
Ә җил көлә.
Ташлар булып бата Хәтер
Су төбенә.

Табигатькә артык түгел
Юкса без дә.
Ләкин колак салучы юк
Өнебезгә.

Безнең өннәр суга ага
Таллар белән.
Агымсулар кыса безне
Ярлар белән.

Егылабыз, кысылабыз,
Убылабыз.
Агымсуда агып бара
Кыйбылабыз.

*2005*

## НИБАРЫ

Сугышлар юк илдә әлегә,
Бомба чокырламый юлларны;
Һәркөн саен арта бәяләр,
Үзгәреш шул әлегә нибары.

Хатын-кызлар окоп казымый,
Бөкрәймәгән буе-сыннары;
Армиягә китә уллары —
Тик шул гына әлегә нибары.

Кайтып тора тимер табутлар,
Күмелә илнең асыл уллары —
Сугышлар юк, туплар шартламый,
Яшь солдатлар кырыла нибары.

Һәр чат саен өч-дүрт хәерче,
Сибелә җилгә зар һәм моңнары.
Илебез бай безнең, шундый бай,
Тик ярлылар арта нибары.

Кибетләргә керсәң, бар да бар,
«Ал!» — дип тора һәрбер товары.
Алыр идең сумка тотырып,
Акча гына җитми нибары.

Сугышлар юк илдә әлегә,
Коела җиргә Кояш нурлары.
Бөтенесе әйбәт шикелле,
Тынычлык юк җанда нибары.

*2005*

* * *

Агыла кара болытлар,
Агыла безнең якка.
Йөзен сөртеп өлгералмый
Күктә кояш та хәтта.

Кошлар кара болытларны
Телгәләмәкче була.
Тик кылыч-канатларыннан
Канлы каурый коела.

Тарая бара офыклар,
Болыт куерган саен.
Кими бөркет оялары,
Таулар убылган саен.

*2005*

## ШОМ КАЛДЫ

Яз килде, дип сөенеп өлгермәдек,
Өр-яңадан һава бозылды.
Сайрар кошлар кинәт тынып калды,
Күреп күктә очкан козгынны.

Козгын очты урман өсләреннән,
Тугайларны кат-кат айкады.
Күләгәсе су өстенә төшеп,
Дулкыннарга ятып чайкалды.

Балыклар да куркып төпкә чумды,
(Күренмәвең чөнки яхшырак).
Козгыннар бит алар юкка килми,
Алар килә бары җан сорап.

Тирә-юньгә хәвеф-хәтәр өстәп,
Болытлар да куера төштеләр.
Йодрыкларын кесәләргә тыгып,
Эчтән сукрандылар кешеләр.

Ә козгынга тик шул кирәк иде,
Очып йөрде дә ул югалды.
Күңелләрдә яз шатлыгы бетте,
Курку гына калды, шом калды.

*2005*

## САНДУГАЧ ОЯСЫ

Ешкынлык эчендә бер оя,
Мөгаен сандугач оясы.
Яшергән ул аны шундый нык,
Серле шул кошларның дөньясы.
Күрмисең кергәнен, чыкканын,
Чума ул чыгармый бер тавыш.
Яфрак та селкенми куакта,
Әйтерсең бөтенләй оя буш.
Беләсең югыйсә шушында
Куаклар эчендә оя бар.
Сайрыйлар гел шушы тирәдә,
Моң белән күмелә дөньялар.
Күрмәгән нәрсәләр серле шул,
Хыялны төрлечә уйната.
Күңелләр түрендә йоклаган
Иң татлы хисләрне уята.
Бик гүзәл тоела ул оя,
Эчендә йоп-йомшак мамыктыр.
Ул оҗмах түренә охшаштыр,
Анда гел сафлыктыр, пакьлектер.
Тартылам яшерен ояга,
Тик аңа кагылмыйм — сер калсын.
Тикмәгә шулкадәр яшереп
Кормыйдыр бу кошлар оясын.
Кошлар шул безнең күк түгелләр,
Ачмыйлар яшерен җирләрен.

Саклыйлар алар үз оясын,
Кызганмый көннәрен, төннәрен.

*2005*

## БУЛЫР ИДЕ СЫЗЫП ТАШЛАП

Әллә нинди тынгысызлык
Җанымны талкып тора.
Ул елан кебек сихерләп
Үзенә тартып тора.

Аны адаштырыр өчен
Карурманнарга керәм.
Барлык юлларны капларга
Куе томаннар эләм.

Бәргәләнәм, чәбәләнәм,
Утка-суларга төшәм.
Тик аннан булмый арынып,
Ул бәреп чыга эчтән.

Төннәрен йокыларымнан
Сикертеп торгыза ул.
Йә давыл булып килә дә
Бар тәртипне боза ул.

Интектерә, җәфалый гел,
Шул явыз — тынгысызлык.
Шатланып йөргән чакта да
Куя кәефне бозып.

Бик теләсәм, язмышымнан
Буладыр аны сызып.
Тик җанның чите кителер,
Калмаса тынгысызлык.

*2005*

## МЕҢ САВАПКА САНАЛЫР

*Миңлегөл апа Рафиковага*

Күп ятимнәрне сыйдырдың
Үзеңнең йөрәгеңә.
Ак фәрештәң зур саваплар
Язгандыр иңнәреңә.

Ятимнәрнең күз яшьләрен
Сөрткән кулъяулыкларың,
Оҗмах кошына әйләнеп,
Эчерер кәүсәр суларын.

Бер ятимне елмайту да
Мең савапка саналыр.
Изге эштән бу дөньяга
Тик изгелек таралыр.

Кешегә бит гомер буе

Наз кирәк, җылы кирәк:
Баштан сыйпап юатырга
Аналар кулы кирәк.

Шушы назны бирә алдың
Син бик күп ятимнәргә.
Күчә барыр бу олы наз
Күңелдән күңелләргә.

*2005*

## НИЛЕКТӘН

Кешеләр бер-берсен яратмый,
Нилектән икән бу, нилектән?
Замана тудырган чирме бу,
Әллә соң калганмы электән?!

Бу яман гадәтнең тамыры
Дым ала нииндирәк инештән?
Һәм күккә язылды шундый сүз:
«Җаннарга яшеренгән иблистән».

*2005*

## ТҮГЕЛ ИКӘН

Бүген мин җыр саттым
Һәм төштем зур шиккә:
Әгәр дә бу эшем
Әйләнсә кәсепкә?!
Көндез дә, төнлә дә
Шушы уй борчыды.
Эт итеп сүктем мин
Җыр алган җырчыны.
Күсәкнең иң зуры
Үземә эләкте.
Ниндидер авыр шом
Талкыды йөрәкне.
Шул вакыт ерактан
Ишетелде бер тавыш:
«Дөнья ул — зур базар,
Юк монда яман эш.
Шигырь дә товар бит,
Сатыла, алына.
Борчылып, уйланып,
Шик салма җаныңа.
Синең җыр кушылыр
Кошларның тавышына.
Бер якты төс бирер
Күпләрнең тавышына.
Моңсызлар моңланыр,
Уйсызлар уйланыр.
Оеган күңелләр
Йокыдан уяныр.
Дөнья ул — зур базар,
Җыр, шигырь — бер товар.
Товарың сатылса,

Тик шатлан син аңар».
Бу сүзләр мине һич
Юата алмады.
Хисләрнең давылы
Җанымны айкады.
Әйтерсең күкләрнең
Түбәсе тишелде.
Өстемә йолдызлар
Күмере ишелде.
Гөлләрем боекты,
Моң сарды бакчамны.
Мин утка ыргыттым
Җыр саткан акчамны.
Тик шуннан соң гына
Яктырды күңелем.
Аңладым шигырьнең
Бер товар түгелен.

*2005*

## ЙӨРӘК

Йөрәк аша уза язлар, көзләр,
Йөрәктә дә юллар упкынлы:
Йә көтмәстән вулкан бәреп чыга,
Йә кузгала сөю дулкыны.

Җәйләр җиле диңгез артларына
Илтеп ташлый билдән күтәреп.
Кышның зәһәр буранын да йөрәк
Үзе аша тора үткәреп.

Хисләр өермәсе кузгалганда,
Тамырлардан кайнар кан ага.
Барып бәрелә аның кайнарлыгы
Сөю дәрте сүнгән җаннарга.

Урманнарга алып кереп китә,
Сайрар кошлар җырын тыңларга.
Йөрәк үзе барын сыйдыра ала,
Үзе сыймый урман, кырларга.

Аңа кирәк күкләр биеклеге,
Аңа кирәк чиксез чиксезлек.
Бәлки әле, җанның соңгы кылы
Чиксезлектә калыр өзелеп.

*2005*

## ҺӘР КӨН ИРТӘН

Мин йокымнан уянамын иртән,
Кәгазь-каләмемне сагынып.
Йөгерешә башлый хәрефләрем,
Бер-берсенә бәрелеп, абынып.

Әйтерсең лә кәгазь ярсу диңгез,
Уй-дулкыннар агыла тоташтан.
Ак диңгезгә кайнар тамчы тама

Җиһан йөрәгеннән — Кояштан.

Шигырь моңнарына акчарлаклар
Үз тавышын кушып җибәрә.
Хәтер сукмаклары алып чыга
Яшьлек яшьнәп үткән җирләргә.

Яшьлегемнең яшел күләгәсен
Сакламаган яшел аланнар.
Ул үләннәр инде ничә кабат
Кояш нурларында янганнар.

Күләгәләр — яшьлек күләгәсе,
Алар инде хәзер ник кирәк?
Фаҗигале яшьлек күләгәсен
Ничә еллар йөрим өстерәп?

Йөгерә каләм кәгазь өсләреннән,
Уй-фикерләр кала уелып.
Яшәр икән алар киләчәктә
Кемнәр йөрәгенә сыенып?!

*2005*

## БЕР КЫЗ ҖЫРЛЫЙ

Бер кыз җырлый.
Үзенә соклanudan
Йөзләренә чыккан көләч балкыш.
Ишетелә залга өзек-өзек
Аертылган сөттәй сыек тавыш.

Колакларны яра музыкасы,
Егылып кала сүзләр ярты юлда.
Билеты юк тамашачы кебек,
Һич урын юк монда тирән моңга.

Ә зал тыңлый. Кул да чабып куя,
Күммәсә дә кызны алкышларга.
Тамашачы инде күнегеп беткән
Судан сыек, төссез тавышларга.

Каймак кебек күңелләрдә эреп
Сихәт бирә торган моңнарыбыз
Кычкыралар күңел түрләреннән:
«Читлекләрдән безне чыгарыгыз.

Канатлар нык әле, сулышлар киң,
Офыкларны мең кат иңләрлек.
Кайсыбызны безнең алсагыз да,
Иң шәп симфониягә тиңләрлек».

*2005*

## МОНДЫЙ БӘХЕТ ТӘ КИРӘК

Яңа фатир алдык әле,
Шатлыктан сикерә йөрәк.
Ыргыттык бөтен әйберне,

Иске-москы ник кирәк?!
Бер бүлмәдә алты кеше,
Кандала һәм таракан.
Ходай ярлыга иш итеп
Аларны да яраткан.
Калдырдык та бөтенесен,
Бер кат өс-баштан күчтек.
Сөенечтән хатын белән
Бер ярты әйрән эчтек.
Күктән төштеме бу бәхет,
Үзгәрдеме дөньясы? —
Фатир фатир гына түгел,
Фәрештәләр оясы.
Үзе иркен, үзе матур,
Әй мондагы хозурлык!
Шушы хозурлыкка карап
Ашамыйча торырлык.
Хәер, ашыйсың килсә дә,
Кесә ягы бик такыр:
Хезмәт хакын алдык быел
Алты айга бер тапкыр.
Ә шулай да күңелләр көр,
Өебез тора көлеп.
Кайсы яктан карасаң да,
Патша сарае кебек.
Ә шулай да иске фатир
Искә төшеп куйгалый.
Искә төшеп, сагындырып,
Җанны кисеп куйгалый.
Савыт-сабалар да әле
Ярыйсы сыман иде.
Бары чүмечебез тишек
Һәм сабы сынган иде.
Булмаса да кастрюльнең
Капкачы һәм тоткасы,
Ярый иде пешерергә
Суда тары боткасы.
Уйланабыз аяз кичтә,
Уйлар белми чаманы:
Ярым ай искә төшерә
Безнең ярык табаны.
Утырып уйлар уйлый-уйлый,
Философ булдык тәмам.
Хатын әйтте: «Чыгу юлы
Бар икән бит бу хәлдән».
«Ничек?» — дип аңа карадым,
Хатын хәйләкәр көлде.
«Яңа өй котлау мәҗлесе
Үткәрәбез беркөнне.
Кайгырма берни дә юк дип,
Килсеннәр дә күрсеннәр.
Килеп күргәч ни кирәген,
Кайтып алып килсеннәр.
Якташлар бар, туганнар бар,
Дус-ишләр дә җитәрлек.
Безнең бу патша сараен
Бүләк белән күмәрлек».
Нәкъ хатын әйткәнчә булды:
Дуслар килде җыелып.
Күчтәнәчләре бар иде

Ике мәҗлес җыярлык.
Әйбәт бит бездә кешеләр,
Юмарт бит безнең халык.
Бүләк ташый башладылар
Әллә кайлардан табып.
Кем урындык, кемдер өстәл,
Кем — кәнәфи, кем — диван.
Телевизор, савыт-саба,
Карават, мендәр, юрган.
Карыйбыз — өйдә бар да бар,
Бөтенесе өр-яңа.
Хәтта залда өй балкытып
Бәллүр люстра яна.
Кухняда ике суыткыч,
Идәндә затлы келәм.
Иң саран дип йөргән дустым
Шәп шкаф алып килгән.
Ул чикләвек агачыннан,
Ялт та йолт балкып тора.
Карарга теләмәсәң дә,
Карашны тартып тора.
Фатир иркен — биш бүлмәле,
Ни куйсаң да сыярлык.
«Холл» дип аталган бүлмәдә
Хәтта футбол уйнарлык.
Кемдер әйтер: шыттыра бу,
Мондый хәл булмас һич тә.
Була икән ул, дусларым,
Өндә булмаса — төштә.
Өзелмәсен өчен өмет,
Туңмасын өчен йөрәк.
Мондый бәхетне һич югы
Төштә күрү дә кирәк.

*2005*

## ХИКМӘТЛЕ ДАРУ

Иртән торсам, гаҗәеп хәл,
Бер җирем дә авыртмый.
Әллә яшьлек кайтканмы дип
Уйланып яттым шактый.
Йөрәгем дә әйбәт тибә,
Туктар-туктамас түгел.
Үпкәмне тутырып сулыйм,
Сулыш алулар җиңел.
Битемдә җыерчык беткән,
Беләкләргә көч кергән.
Гүя әкияти тылсымчы
Тылсым укып өшкергән.
Кичтән тешем сызлый иде,
Ул да сызламый хәтта.
Бу нинди могҗиза, диеп
Калдым тәмам гаҗәпкә.
Хикмәт нәрсәдә икән дип,
Озак кына баш ваттым
Һәм исемә төшердем дә,
Үз-үземә шаккаттым.
Телевизордан бер реклама

Караган идем кичтән.
Имеш, бөтен чирең бетә,
Фәлән даруны эчсәң.
Мин шунда ук кичекмәстән
Шул даруга йөгердем.
Ярый әле иң соңгысын
Эләктереп өлгердем.
Рекламага ышанмыйлар,
Күпләр, ул ялган, диләр.
Аларны карау үзе үк
Агудан яман, диләр.
Ә мин менә ышандым да
Эчтем әйткән даруны.
Сыпырып төшердем шулай
Үземнең бар авыруны.
Беләм, ышанмыйсыз миңа...
Дөресеме?
Дөресе —
Шигырьдә язылганнарның
Була инде киресе.
*2005*

## ӘРНҮ

Иртән торып әгәр күз ташласам
Казанымның берәр чүплегенә:
«Без җиңдекме, әллә җиңелдекме?» —
Дигән сорау килә күңелемә.
Ашыгалар бөкре карт-корылар,
Шыгыр-шыгыр кул арбасын сөйрәп.
Чүплекләрдә «табыш», «байлык» ята,
Ә табышка тизрәк бару кирәк.
Кемдер шешә, кемдер ризык эзли,
Ялан кулы белән чүп актара.
Муены өзелмәгән шешә тапса,
Алтын тапкан кебек ул шатлана.
Кемнәргәдер ямаулыклар кирәк,
Ямаулыксыз булмый һич тә торып.
Дөньялары ертык, тишек булгач,
Яшисең гел ялгап, ямаштырып.
Ә бераздан базарларга чыга
Чүплекләрдән җыйган шушы «товар».
Карашларын түбән таба текәп,
Алу-сату итә сансыз картлар.
Кайберсенең пинжәк өсләрендә
Калган әле орден эзләре дә;
Оялудан кызарганнар картлар,
Илгә рәнҗү юеш күзләрендә.
«Без җиңдекме, әллә җиңелдекме?» —
Шушы сорау мине интектерә.
Кеше кадере беткән илнең үзен
Киләчәктә ниләр көтеп тора?!
Җаным әрнеп тәрәзәгә карыйм,
Шуннан башлыйм һәрбер иртәне.
Чүплекләрдән кешеләр таралуын
Көтеп тора урам этләре.
*2005*

* * *

Бернәрсә дә үзгәрмәде кебек,
Уйлар әле йөгерек.
Хыял сарайларын гына никтер
Җилләр киткән җимереп.

Сизми калдым вакыт үтүләрен,
Эшем минем — дөнья.
Хәтер аты гына кайчакларда
Адашкалап куя.

Вакыйгалар, кар көртләре кебек,
Юлны күмеп киткән.
Үткән сукмакларым күңелемдә
Чуалышып беткән.

Ләкин һаман тукталган юк әле,
Барам алга таба.
Эзләремдә ләкин гөлләр үсми,
Утлар янып кала.

Бернәрсә дә үзгәрмәде кебек,
Каләм кулда, шөкер.
Вакыт атын иярләргә генә
Өлгермимен никтер.

*2005*

## АҖАГАН

Аҗаган — тавышсыз яшен,
Ул — фәрештәләр туе.
Арыш серкә очырганда,
Туй бара төннәр буе.

Тавышсыз гына җырлыйлар,
Тавыш монда — яктылык.
Тып-тын гына биюләрдән
Күренеп тора затлылык.

Бии, җырлый алыр иде
Ду кубарып алар да —
Күккә, җиргә хөрмәт бик зур
Бу илаһи җаннарда.

Бер офыктан бер офыкка
Төсләр җыры җәелә.
Уза туйлар, сибелә нурлар
Авылның тын җәендә.

*2005*

## ОНЫТАБЫЗ

Киткәннәрне тиз онытабыз,
Онытмаска кирәк тә —
Әмма урын бигрәк тар шул

Безнең мескен йөрәктә.

Ә үзебез мәңгелеккә
Йөрибез дәгъва кылып.
Тырыша хәтта кәрләләр дә
Күренергә гигант булып.

Йөрәгең башкалар өчен
Булса һәрвакыт ябык.
Үз хисләрең өчен дә ул
Булачак бары табут.

*2005*

* * *

Гәүдәм минем йодрык кадәр генә,
Ачуың килсә — алдың, ыргыттың.
Аппетиты әйбәт булганнарга
Баш-аягым белән — бер йотым.

Шушы нәрсә алдый бик еш кына
«Мин!», «Мин!» диеп йөргән ирләрне.
Юлдан алып атмак булалар да
Сындыралар алар билләрен.

Белмиләр шул: минем тамырларым
Миллион күңелләргә тоташкан.
Кеп-кечкенә генә күкрәгемә
Олы дөнья кереп урнашкан.

Анда — Кояш, анда — Ай-йолдызлар,
Мәхәббәт һәм нәфрәт — бар да бар.
Анда таулар, анда кайнар диңгез,
Анда буй җитмәслек ярлар бар.

Карурманнар тамыр җәйгән анда,
Җаным шуның барсын сыйдырган.
Үз көченә артык нык ышанып,
Әзме батыр билен сындырган!
Тырышмагыз җанны кубарырга
Халык күңелендәге урыныннан.

*2005*

## ТӨСЛӘР

Кочак-кочак төсләр җыеп кайттым
Көзнең гаҗәп матур көнендә.
Алмадым тик кара төсне генә —
Калды анысы аю өнендә.

Кара төсләр миңа кирәк түгел,
Якты төсләр якын нигәдер.
Яфрак булып алтын ява җиргә,
Мондый байлык бары көздәдер.

Бу төсләрнең әле бик күбесе
Шигырь юлларыма күчәчәк.
Төсләр белән төсләр кушылачак
Һәм шулардан гөлләр үсәчәк.

Кышкы бураннарга күмелгәчтен
Урам, кырлар, басу, болыннар,
Җир хәтерен бер яңартыр өчен
Шушы гөлләр кирәк булырлар.

Булсын әйдә, булсын яз төсе дә,
Булсын әйдә, булсын көз төсе.
Хәтеребезгә күбрәк төсләр сеңсен,
Хәтер бит ул — тормыш көзгесе.

Үткәннәрне шул көзгедән карап
Искә төшерә бит һәммәбез.
Төсләр җанга кереп торган чакта
Киереп ачыйк җанны, әйдәгез.
*2005*

* * *

Үргә менә башласаң,
Ике төркем күзәтә:
Кемнәрнеңдер карашы
Сине югары этә,
Кемдер ташка абынып
Тәгәрәвеңне көтә.

* * *

Һәр көн йөрим уйлар урманында,
Куера бара уйлар урманы.
Кергән чакта сукмак табылса да,
Чыгар өчен булмый юллары.

*2005*

## БЕРНӘРСӘ ДӘ БУЛМЫЙ МӘҢГЕЛЕК

Яшь чагында дуслар бик күп иде,
Уртак иде бөтен уебыз.
Кочаклашып урам ураганда,
Күккә үрли иде җырыбыз.

Тыңлый иде кызлар тәрәз ачып:
Кайсыбызның тавышы көчлерәк?!
Без беләбез алар тыңлаганны,
Безнең өчен бары шул кирәк.

Кайчагында матур кызлар өчен
Бераз бәргәләшеп алсак та —
Дуслашабыз бик тиз арада без,
Ачу озак бармый яшь чакта.

Чөнки әле җаннар керләнмәгән,
Бөтенебез әле бертөсле.
Киемнәр дә затлы түгел, ләкин
Яшь чагында барсы килешле.

Күңелебездә һичбер хөсетлек юк,
Бер-беребездән нигә көнләшик?!
Маллар да юк безнең, даннар да юк,
Бөтен байлыгыбыз шул яшьлек!

Бер учакка бәрәңгеләр күмдек,
Бер учакка җыелып җылындык.
Җил-давыллар бәрсә йөзебезгә,
Бер-беребезгә ныграк сыендык.

Еллар үтте, без дә үзгәрештек,
Тигезсезлек керде арага.
Кем баеды, кемдер фәкыйрьләнде,
Кемдер түрә булды калада.

Еллар белән җырлар үзгәрделәр,
Һәрберебезнең хәзер үз җыры.
Әкрен-әкрен сиздермичә генә
Өзелә барды дуслык чылбыры.

Бергәләшеп учак ягар өчен
Вакыт та юк хәзер, теләк тә.
Бөгәрләнеп яткан елан кебек,
Бер салкынлык ята йөрәктә.

Бернәрсә дә мәңге түгел икән,
Тормыш тора безне үзгәртеп:
Арба тарткан ярлы дустын байлар
Машинадан кала күзәтеп.

*2005*

* * *

Мин беләмен дошманнарым барын,
Каһәрләмим ләкин аларны.
Һәрбер кеше сөенеп күзәтми бит
Түш киереп чапкан атларны.

Егылуын, абынуын тели
Күңеле тарлар — яхшы атларның.
Ул егылса, алга чыгуы бар
Көч-хәл белән барган чаптарның.

Беләм, тормыш сабантуе түгел,
Ярышмыйбыз чыгып мәйданга.
Тик ниндидер бер көнчелек яши
Сиздермәскә тырышып күп җанда.

Ул йокларга мөмкин озак-озак,
Уянмаска мөмкин һичкайчан.
Камчы булып үрелми ул сиңа,
Томырылып алга чапмасаң.

Кайнар канны тыеп буламыни,
Камчы канатса да йөзеңне —
Узасың син күкләр юлы аша,
Айга салып тояк эзеңне.

Ә дошманнар була икән — булсын,

Аларның да булуы кирәкле.
Алар бетсә, кем ярсытып торыр,
Кем камчылап торыр йөрәкне!

*2005*

* * *

Көз үзенең кулъяулыгын
Каен ботагына элеп киткән.
Җилфер-җилфер итә бу кулъяулык,
Онытмагыз көзне, дия микән?

* * *

Уйлар буранында адаштым,
Юл табалмый озак маташтым.
Ул юл булган икән янымда —
Яшәү уты йөрткән җанымда.

* * *

Бик еш атыла йолдызлар,
Әллә күктә дә сугыш? —
Яшен шары шартласа да
Кысылып куя сулыш.

* * *

Әллә көлү, әллә елау,
Ишетелә нинди өннәр?
Әллә туалмый ятамы
Киләчәк матур көннәр?

* * *

Елаганың бармы, диләр,
Елап кемне куркытыйм?
Аны да елап үткәрсәң —
Гомер бит ул бер йотым.

* * *

Кошларга канат биргән,
Кешегә акыл биргән:
Теләсәң, акылың белән
Күкләргә атыл, дигән.

* * *

— Нигә очынасың болай,
Нәрсә булды, күңелем?
— Шатлыгым шул: буш үтмәде
Минем бүгенге көнем.

* * *

Канатлылар оча, дибез,
Оча ерак җирләргә;
Канатсызлар да «очалар»,
Сүз әйтсәң түрәләргә.

* * *

Биегрәк менә барган саен
Кичерәя бара кешеләр.
Алар бары тормыш китабының
Бер ноктасы гына төслеләр.

* * *

Ташкыннар булып агыла,
Дөньяны баса буш сүз.
Буш сүзне алучылар күп —
Чөнки бәясе очсыз.

*2005*

* * *

Ак чәчәкләр җибәргәнсең,
Синең күңелең актыр.
Яман эшләр, яман хисләр
Сиңа бөтенләй яттыр.

Каршымдагы ак чәчәкләр
Раслап тора сүземне.
Бер кочып үбәрмен әле,
Әгәр күрсәм үзеңне.

*2005*

* * *

Бик биектән кошлар очып бара,
Ишетелми канат тавышлары.
Язылып кала бары офыкларга
Җаннарында йөрткән язмышлары.

Укый гына белү кирәк безгә,
Ни язылган анда — күк йөзенә.
Күкләр серле — анда ниләр барын
Күрә алмый маңгай күзе генә.

*2005*

* * *

Шәһәр һавасы төтенле,
Шәһәрнең кары кара.
Ак карлы авылны ташлап,
Яшьләр шәһәргә бара.

* * *

Кемдер алыштыра исемен,
Оҗмахка керер өчен.
Тик куып чыгара алмый
Күңелендәге иблисен.

* * *

Шешә имеп үскән балалар
Үскәчтен дә шешә имәчәк.
Бәлки, шушы шешә эченә
Салынгандыр безнең киләчәк.

* * *

Чумдым тирән уйларга,
Баскычлар юк чыгарга;
Гомеремнең очын эзлим
Кулларыма урарга.

*2005*

## ИКЕ ЮЛ

Зур чатта ике юл,
Берсе киң һәм шома.
Киң юлны тутырып
Агыла машина.
Машина эчендә
Бик кәттә егетләр.
Сөяркә-җанашлар
Хур кызы кебекләр!
Ашыга һәммәсе
Тиз-тиз — тизерәк!
Иң яхшы урыннар
Барсына да кирәк.
Узышып баралар
Бу атсыз арбалар.
Күбесе, бәрелеп,
Канауга авалар.
Сүгенә ауганнар
Һәм артта калганнар.
Сөенә һәммәсен
Тик уза алганнар.
Икенче юл башка —
Үләнле тар сукмак.
Монда гел карт-коры
Ял итә еш туктап.
Хәлсезләр, көчсезләр
Җилдән дә авалар.
Андыйны юлдашлар
Күтәреп алалар.
Зур юл да, сукмак та
Баралар бер якка.
Максатлар бер генә:
Эләгү оҗмахка.

*2005*

## ЕЛАГЫЗ, ДИЛӘР

Елыйм дисәң, елар өчен
Сәбәпләр күп, билгеле:
Гаделсезлек хәнҗәрләре
Теләкүпме күңелне.

Әзме бер кәгазь өчен дә
Миллион кабат йөрүләр —
Шул кәгазен алалмыйча
Бусагада үлүләр;

Җаныңны таптау, хурлаудан
Әзмени кимсенүләр,
Тездән түбән түрәләргә
Иелеп ришвәт бирүләр;

Аяклылар — раслар өчен
Аяклары юклыгын —
Гомерләре буе таптый
Хастаханәләр юлын.

Тереләргә кадер җитми,
Үлгәннәргә — каберләр.
Үлгәннәр дә еласынмы
Каты диеп бәгырьләр.

Кимсетүнең ысулларын
Беләләр бездә яхшы —
Юләрләр йортлары бар,
Күбрәк уйласа башың.

Дустың дус булудан туктый,
Күтәрелсә югары.
Элекке дус кул бирми дип,
Гел елап торыргамы?!

Без еласак, аларның бит
Күңеленә май булыр.
Тәкәбберләнеп китәргә
Тагын да бер җай булыр.

Елаучылар арткан саен,
Көлүчеләр артачак.
Ә гаделлек онытылып,
Гел тапталып ятачак.

Еласаң безнең тормышта
Елап кына торырлык.
Еламыйк әле, уянсын
Элеккеге горурлык.

Без бөек, горур халыкның
Уллары — варислары.
Төшмәсен безнең башларга
Аларның каргышлары.

*2005*

* * *

Тамагым тук,
Өстем бөтен,
Торырга бар өем.
Ләкин көйләп
Тору кирәк
Өебезнең көен.

Өйнең көе
Китмәс өчен
Тырышабыз.
Бер алмашсыз
Сакчы кебек
Тормышта без.

Җитмәгәнне
Мин җиткереп,
Ялгап торам.
Хатын минем
Яраларны
Ямап тора.

*2005*

* * *

Кайчакта күңелдә
Нәрсәдер уала.
Әйтерсең кыйммәтле
Әйберең югала.

Тик аны белмисең —
Нәрсә соң югалган?
Мәхәббәт былбылы
Качканмы оядан?!

Актарып карыйсың
Хәтерең сандыгын.
Барлыйсың күңелдән
Бар булган байлыгың.

Эзлисең, эзлисең,
Табылмый — юк кына.
Хәтердә җемелдәп
Куйгалый ут кына.

Һәм арып эзләүдән
Тотынасың эшеңә.
Шул чакта җавабын
Күңелең төшенә.

*2005*

* * *

Дөнья матур —
Гел матурлап торсаң.
Дөнья ямьсез —
Гел-гел хурлап торсаң.

Без зур халык —
Үзебезне зурлый алсак.
Без кечкенә —
Һәр шәүләгә бүрек салсак.

Без акыллы —
Акылыбызны эшкә җиксәк.
Без гайрәтле —
Көчләләрне акыл белән җиңсәк.

*2005*

## ЯШИ БАШЛАРГА ВАКЫТ

Без яшәр өчен туганбыз,
Көрәшер өчен түгел.
Тормыштан геройлар эзләү —
Ул инде үткән шөгыль.

Ә без һаман көрәшәбез,
Туктый алмыйбыз һич тә.
Бар тормышыбыз корылган
Гел көрәшкә, гел көчкә.

Бу көрәштә кагыйдә юк:
Хәрәмләш, аяк та чал.
Әллә нинди хәйләләр кор —
Батыр булып кына кал.

Кычкыра белсәң әгәр дә
Ертылганчы бугазың.
Һич кенә дә икеләнмә —
Син җиңүче буласың.

Ничек кенә яуласаң да
«Батыр» дигән исемне,
Ялтыравык медаль бизәр
Шушы көннән түшеңне.

Бәлки, гадиләштерәмдер,
Көрәш бит ул зур нәрсә.
Көрәшнең дә кызыгы бетә,
Һәркем көн дә көрәшсә.

Яшисе иде югыйсә
Гел акылга таянып.
Китәр иде тормышыбыз
Бераз гына җайланып.

Кулдан алда акыл йөрсә,
Уйларга илче булып.
Йөрер идек һәрвакытта
Файдалы эшләр кылып.

Гаделлек тә чыгар иде
Уянып, өскә калкып.
Инде көрәшүдән туктап
Яши башларга вакыт бит,
Яши башларга вакыт.

*2005*

* * *

Бар киемен чишенеп ташлаган да
Рәхәтләнеп ята кызынып.
Очар кошлар күк пәрдәсе аша
Карап китә аңа кызыгып.

Аның матур ап-ак шома тәнен
Җилләр сыйпап китә кайвакыт.
Зәңгәр күктән, күзен кыса төшеп,
Кояш карап тора яратып.

Ә ул ята җәйнең җылысыннан
Рәхәтлекләр җыеп үзенә.
Керфеген дә кагып куймый хәтта
Нурлар тулганда да йөзенә.

Бер гаме юк аның бу дөньяда,
Исе китми хәтта кояшка.
Тик бөркетләр генә кунып ала
Тау башында яткан бу ташка.

*2005*

## ИКЕ КЫЗ

Юл читендә ике кыз,
Тәннәре ярым ачык.
Җилләр китә кытыклап,
Ябык җирләрен ачып.

Сөйләшәләр бу кызлар,
Дөньяда юк гамьнәре.
Һәр сүз саен көләләр,
Шәптер, ахры, хәлләре.

Берсе әйтә: — Минем, — ди, —
Баш эшләми башлады...
Дус кызының бу сүздән
Сикереп куя кашлары.

Һәм әйтә ул дустына,
Гүя бик зур сер ача:
— Ике як та бертигез
Эшли алмый лабаса.

Кызларга була кызык,
Көләләр шырык-шырык.
Кендектәге алкалар
Сикерә дырык-дырык.

*2005*

* * *

Яратырга сәбәп кирәк түгел,
Сәбәпсез дә булабыз гашыйк.

Ташлашырга гына сәбәп кирәк,
Бер сәбәпсез булмый ташлашып.

* * *

Милләт, дибез, татар, дибез,
Кайда безнең татарлык?
Калды көч: тик бер шешәне
Өч кешегә «ватарлык».

*2005*

## БИЛГЕСЕЗ СОЛДАТ КАБЕРЕ

Менә кабер. Кем күмелгән анда?
Әтиемме, берәр якташмы?
Кем утырткан аның каберенә
Хөрмәт белән шушы ак ташны?
Исемен дә язып куймаганнар,
Кабер ташы дәшми, тын тора.
Җилләр генә, кураларга өреп,
«Матәм маршы» көен сызгыра.
Кем син, солдат?
Әти кешеме син?
Кабер ташы, нигә дәшмисең?
Әти булсаң, син бит үз балаңның
Йөрәгендә һаман яшисең.
Бер тол хатын егерме ел буе
Күңелендә сине саклыйдыр.
Яки синең кабереңне эзләп
Сугыш узган юлдан атлыйдыр.
Кабер йоткан синең гәүдәңне дә,
Исемең дә җирдә калмаган.
Ә бит менә сине көтә-көтә
Җиргә бик аз яшьләр таммаган.
Исемнәрен еллар сызсалар да,
Китми алар безнең күңелдән.
Чөнки алар җиргә генә түгел,
Барлык йөрәкләргә күмелгән.
Сугыш бетте күптән, ләкин һаман
Үткәннәрне күңел актара.
Кеше каны монда күпме аккан?!
Ә кан тамган җирдә тап кала.
Күңел хисләренә ирек бирәм,
Тотып булмый чөнки тыеп та.
Киемдәге тапны юып була —
Йөрәкләрне булмый юып та.

*1963–2006*

## ӘЙТ СИН, ДОКТОР

Доктор,
Күзләремә минем карыйсың да
Телисең син нидер әйтергә.
Тик кыймыйча башың чайкыйсың син,
Төшерә алмагандай хәтергә.

Әйт турысын, авыр булса булсын,
Тик ялганны сөйләп юатма.
Ялган сүзләр белән йөрәгемдә
Эшкә ашмас хыял уятма.

Мин гомеремне томан аша түгел,
Ачык итеп килә күрәсем.
Барыр юлым әгәр күренмәсә,
Яшәү миңа
Нинди генә шатлык бирә соң?

Мин алдыма олы максат куйдым,
Максатыма кирәк җитәргә.
Гомерем минем әгәр кыска икән,
Ашыгырга кирәк үтәргә.

Эшләнмәгән эшләр күп калса да,
Башланган эш җитсен азакка.
Әйтче, доктор, тынгы белмәс йөрәк
Чыдар микән тагын озакка.

Мин гомеремә үзем пычак салмам,
Тик шулай да килә беләсем.
Һәм гомеремнең соңгы минутын да
Халкым өчен килә бирәсем.

*1963–2006*

## ЕГЕТ ҺӘМ КЫЗ

— Саласыңмы? — диде егет,
Кыз әйтте: — Салам, салам.
Тик егет кеше буларак
Син үрнәк күрсәт алдан.

Егет кыстатып тормады,
Ялт кына салып куйды.
Кыз да аннан калышмады
Һәм бер җиңеллек тойды.

Бөтенесе тиз эшләнде,
Икесе дә салдылар —
Адәм белән Хава кебек
Яп-ялангач калдылар.

Аннары нишләгәннәрдер,
Бәлки, сөенгәннәрдер.
Аннары инде, әлбәттә,
Кире киенгәннәрдер.

*2005*

* * *

Якын миңа, никтер бик тә якын
Халкыбызның озын җырлары.
Шигырь язып яткан чакларда да
Сузып-сузып куям шуларны.

«Әллүки»не, «Зиләйлүк»не җырлап

«Карурман»га барып керәмен.
Моңнар дөньясына кереп чумсам,
Әллә күктә, әллә җирдә мин.

Җырчылыгым шуның кадәр генә,
Җитеп җитми күпчак сулыш та.
Андый чакта күңел төпләреннән
Бәреп чыккан чишмә булыша.

Белмим, никтер хәтер ярларына
«Уел»лары калган уелып.
Ялгыз чакта җанга терәк табам,
Халкым җырларына сыенып.

Шигырьләргә ургып-ургып керә
Шул җырлардан килгән моң-тавыш.
Халкыбызның бер җырына сыйган
Шигырьләргә сыймас мең язмыш.

Шигырь язам, күңел төпкелендә
Дулкын-дулкын җырлар тирбәлә.
Шигырьләрем халык җырларыннан
Озак яшәү серен өйрәнә.

*2006*

## КИТАПЛАР КИТАБЫ

*«Мәгариф» нәшриятына 15 ел тулу уңаеннан*

«Әлифба» — китаплар китабы,
«Әлифба» — тәүге юл белемгә.
Укыган һәр китап, һәр әсәр
Зур байлык калдыра күңелдә.

Китап ул — кешелек хәтере,
Хәтере юк икән — халык юк.
Ә безнең халкыбыз гомергә
Яшәгән китапка табынып.

Юлчыга юлдаш та булган ул,
Һәр чорга чордаш та булган ул.
Караңгы күңелләр төпкелен
Яктырткан кояш та булган ул.

Буынны буынга ялгарга
Тергезгән хәтерләр учагын.
Алтыннан һәйкәлләр куярлык
Олылап татарның китабын.

Китапта — халыкның язмышы,
Китапта — чорларның сулышы.
Милләт тә сакланган бары тик
Китаплы булганга тормышы.

Китаплар китабы — «Әлифба»,
Алтыннан кыйммәтле һәр хәреф.
Яшәсен китаплар китабын
Тергезгән, зур иткән «Мәгариф».

*2006*

## ҖАН ОЧЫШЫ

Кемнәрдер яулый йөрәкне
Кайнар мәхәббәт белән.
Ә кемнәрдер яулый аны
Шәфкать, мәрхәмәт белән.

Ә бит тормыш шундый кырыс,
Һәр җан саен җәрәхәт.
Җәрәхәтләрне бәйләргә
Кирәк безгә мәрхәмәт.

Алтын түгел, көмеш түгел,
Җылылык кына бары.
Шул җылылыктан көч алып
Очына кеше җаны.

Очына, иңли күкләрне,
Чыга ул чиксезлеккә.
Вакыт куйган киртәләрне
Сикереп кенә үтә.

Айларда тирбәлеп ала,
Тота яшен ташларын.
Ял итә мамык болытка
Куеп кайнар башларын.

Җанга һәркөн очыш кирәк,
Очышта аңа рәхәт.
Җан очышына сокланып
Карап тора мәрхәмәт.

*2006*

## ТӘРБИЯ

Әнисе уңга тартты,
Әтисе сулга тартты.
Малай китте үз юлыннан
Һәм пычракка батты.

*2006*

* * *

Һәр көн саен ак кәгазьгә
Тезелә бара сүзләр.
Каләм артыннан йөгереп
Талчыгалар күзләр.

Күңелемне савам шулай,
Тулышканда уйлар.
Кайнар хисләр агышыннан
Кысылып куя тыннар.

Ак кәгазьнең өсләрендә
Куба көчле давыл.
Давылларны күкрәгеңдә

Тыеп тору авыр.

Каләм очына уралган
Тормышның бар кылы.
Шул кылларда үз җырымны
Уйныйм гомер буе.

*2006*

## ШУНДЫЙ-ШУНДЫЙ УЙЛАР

Килә кайчак бу дөньяны ташлап
Ерак-еракларга китәсе.
Йә булмаса кояш кызуында
Нурлар булып эреп бетәсе.

Кем булса да уйлар иде микән
Кая китте диеп бу бәндә.
Болыннан да, хәер, ямь кимерме,
Бер чәчәген аның өзгәнгә?!

Һәркөн күпме йолдыз атылып тора,
Кайсы йолдыздан соң эз калган —
Яна-яна җиргә төшкән дә ул
Хәтер диңгезендә югалган.

Шундый уйлар, менә шундый уйлар
Акыл йомгагына урала.
Акыл йомгагына урала да
Яшәү мәгънәләре югала.

Гомре буе гел югалта кеше:
Балачагын, аннан яшьлеген.
Матурлыгын, көчен һәм хәтерен —
Коелып бетә кыйммәт бар йөгең.

Кадере бетә, онытыла кеше,
Эзләр җирдә тәмам югала.
Гомер — мизгел, шушы бер мизгелдә
Кеше яши, эшли, сынала.

*2006*

* * *

Чорлар белән сыналдык,
Еллар белән сыналдык.
Чорларның пәрәвезенә
Чебен булып чорналдык.

Җырлар белән сыналдык,
Моңнар белән сыналдык.
Бар нәрсәне югалтканда
Җырлар җырлап юандык.

Утлар белән сыналдык,
Сулар белән сыналдык.
Агымсулар ярга атса,
Утырып уйлар уйландык.

Без һаман сыналабыз,
Кимибез, югалабыз.
Җир күчәренә эләккән
Үләндәй уралабыз.

*2006*

* * *

Өйрәтелгән өй эте без,
Тешләмибез, өрмибез.
Тышка чыксак, авызлык һәм
Муенчактан йөрибез.

Хуҗаның дус-ишләренә
Койрык болгап торабыз.
Ул өстерсә, гайрәтләнеп
Ырлап куйган булабыз.

Ирекле урам этләре
Керә бары төшләргә.
Тели күңел әрнеп-әрнеп
Ирек исен иснәргә.

Муенчакны салып булмый,
Күпме генә омтылма —
Ыргылабыз, тартылабыз,
Кысыла бары тын гына.

*2006*

## ҮЗЕБЕЗ

Күтәрәбез кайбер бәндәләрне,
Тартып алып пычрак чүплектән.
Ул бәндәбез чабатасын салып
Йөри башлый әйбәт итектән.

Борын китә югарыга менеп,
Ыргытыла иске кәләпүш.
Бил тураеп китә кинәт кенә,
Киерелә башлый күкрәк-түш.

Бәдрәфкә дә җәяү йөрми башлый
Чүплегеннән чыккан түрәбез.
Чиратларга языла-языла гына,
Бүлмәсенә аның керәбез.

Эндәшәбез аңа «сез» дип кенә,
«Син» дияргә бармый телебез.
Аның ахмак сүзләреннән дә без
Тирән-тирән мәгънә эзлибез.

Үзебезгә шулай пот ясыйбыз
Һәм шул потка табынып йөрибез.
Ә бит юкса юктан бар итүче
Аллага да без бит «син» дибез.

*2006*

* * *

Яшьлек күзләрендә
Якты нур һәм балкыш:
Күккә сибелер очкыннары,
Кагылсаң да ялгыш.

Картлык күзләрендә
Мөлдерәмә сагыш.
Бәргәләнеп ята анда
Язылып беткән язмыш.

*2006*

## ЧЕБЕН

Пәрәвез җебенә
Эләккән бер чебен:
Тартыла, ыргыла,
Өзә алмый җебен.

Канатлы югыйсә,
Аяклы югыйсә.
Өзелер кебек җеп,
Шартлатып бер типсә.

Юк, тибә алмый шул,
Аяклар уралган.
Җеп очы еракта,
Җеп очы чуалган.

Әкренләп бу җепкә
Канатлар эләгә.
Чебеннең гәүдәсе
Җилләрдә тибрәлә.

Үрмәкүч бик сабыр
Күзәтә корбанын.
Көтә ул тозакта
Хәрәкәт тынганын.

...Агачтан агачка
Үрмәкүч җеп тарта.
Пәрәвез җебендә
Корбаннар гел арта.

*2006*

## ҖЫР СУЗА АВЗАЛОВА

Сандугачлар килгән урманга,
Шаулый урман, ду куба.
Сандугач түгел икән бит,
Җыр суза Авзалова.

Чишмә ага чылтыр-чылтыр,
Сулар үргә ыргыла.
Суларны үргә агызып,
Җыр суза Авзалова.

Шаулый урман тып-тын көндә,
Җил чыга, давыл куба.
Тын урманнарны шаулатып,
Җыр суза Авзалова.

Канатларын суга бәреп
Йөзә дисәм аккошлар —
Әлфия Авзаловага
Ява икән алкышлар.

Былбыллар картаймый, диләр,
Мин дә ышанам моңа.
Җыры белән гел яшьлектә
Әлфия Авзалова.

*2006*

* * *

Гел камчылап торам сине,
Чыгармыйм бер дә ялга.
Башлап куйган эшләр дәшә:
Туктама, алга, алга!

Кайчак шәфәкъ нурларыннан
Учларыма кан тама.
Ә мин һаман ашыктырам:
Туктама, алга, алга!

Чиксезлекнең чиге бетә,
Вакыт-ат артта кала.
Чакыра билгесез юллар:
Туктама, алга, алга!

Яңа хис, яңа көч, дәрт,
Җирдә һәрбер көн яңа.
Куалыймын үз-үземне:
Туктама, алга, алга!

Алмашынып тора чорлар,
Чор яңа, җырлар яңа.
Чорларны чорнап үзеңә,
Җырларым, алга, алга!

*2006*

* * *

Тормыш арбасының күчәренә
Чүп-чар һаман күбрәк урала.
Авырлыктан күзләр томалана,
Ориентирлар хәтта югала.

Инде туктыйм, туктыйм дигән чакта
Ярдәм итеп куя «җеннәр»ем.
Йөрәгемдә яшь тай кешни башлый,
Һәм яктырып китә көннәрем.

Елларымны җилдә җилфердәтеп
Ашкынамын тагын юлларга.
Баш очымда кошлар оча башлый
Теләп иңнәремә кунарга.

Әллә нинди бер юләрлек белән
Сикереп чыгам офык чикләрен.
Яшен оясына җырлар салам
Һәм рәхмәтен тоям күкләрнең.

Шушы хисләр яшен оясыннан
Очып чыгарлар да бервакыт —
Утсыз йөрәкләргә ут кабызып,
Урап йөрер дөнья буйлатып.

*2006*

* * *

Елгалар, диңгезләр кичтем мин,
Күкләрне, җирләрне айкадым.
Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә? —
Шуңарга мин җавап тапмадым.

Яшәүнең мәгънәсе нидә, дип
Дәштем мин бер төркем яшьләргә.
Уйлап тормыйча әйттеләр:
Сөеп һәм сөелеп яшәүдә.

Бирдем мин шушы ук сорауны
Өй салып ятучы бер иргә.
— Менә бит, — диде ул, ым кагып,
Салына башлаган зур өйгә.

Бирдем мин тагын шул сорауны
Баласын имезүче анага.
Ул миңа җавап та бирмәде,
Тик балкып карады балага.

Үләргә ятучы бер бабай
Миңа ни кирәген белүгә
Әйтте һич уйланып тормыйча:
— Кадерең барында үлүдә.

*2006*

**ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК**

# Җыр — күңелнең канаты

*Шатлансаң да, җыр кирәк,*
*Кайгырсаң да, җыр кирәк.*
*Җанга ятышлы җырларның*
*Барсын сыйдыра йөрәк.*

## БЕЗ КАВЫШЫРБЫЗ

Мин туганда, әни, мәңгелеккә
Өзелгән бит синең гомерең.
Үлем белән яшәү — гел янәшә,
Язмышларның белгән кем серен?

Син киткәнсең йолдыз юлларыннан,
Күкләр сине алган үзенә.
Очкансың син гүзәл аккош булып,
Нурың салып сабыең йөзенә.

Тик син исән, мәңге исән, әни,
Миңа күчкән синең сулышың.
Минем җырым хәтерләтсен иде
Һавадагы аккош очышын.

Син гомереңне миңа биреп киттең,
Мин яшимен синең өчен дә.
Без кавышырбыз, әни, синең белән
Җидегән йолдызларның берсендә.

*2004*

## МИҢА ӨЙСЕЗ КҮҢЕЛСЕЗ

Чакыралар гөлләр иленә,
Барам, күрәм — күңелсез.
Кайтасым килә өемә,
Мин яши алмыйм өйсез.

Тыныч почмак, җылы кочак,
Әнә шул сагындыра.
Гармун тавышы, чишмә агышы
Җаннарны ашкындыра.

Матур җирләр, матур илләр —
Бик күп инде, бик күп сез.
Кичерегез, зинһар, мине,
Миңа өйсез күңелсез.

Җылы почмак, җылы учак,
Өй — мәхәббәт оясы.
Килә минем үз оямда
Назларга коенасы.

Китмимен оҗмах иленә,
Кирәкми оҗмах иле.
Үз илемдә тамыр җәйде
Безнең мәхәббәт гөле.

Җылы почмак, җылы кочак,

Боларга тиң ни бар соң?
Өзмәгез гөлләр тамырын,
Гөлләр урынында калсын.

*2004*

## ИРЕКЛЕ КОШ

Мин ирекле сайрар кош идем,
Оча идем биек-биектә.
Яңгырый иде минем тавышым
Еракларга зәңгәр саф күктә.

Җырладым гел сөю турында,
Тугайларда, иген кырында.
Сагыш, моңга урын юк иде
Тавышымда, минем җырымда.

Җырлап йөргән чакта иректә,
Эләктем мин алтын читлеккә.
Әйдә җырла, җырла, диделәр,
Алларыма гөлләр өйделәр.

Теләсәм дә җырлый алмадым,
Җырсыз атты хәтта таңнарым.
Тик иреккә, бары иреккә
Омтылды шул минем җаннарым.

Аңламады мине кешеләр,
Минем җырым туды иректә.
Ә иректә җырлап үскән кош
Җырлый аламыни читлектә.

*2004*

## ӨЛЕШЕМӘ ТИГӘН КӨМЕШЕМ

Кайда йөри икән адашып
Өлешемә тигән көмешем.
Бүләр идек тигез иттереп
Мәхәббәтнең татлы җимешен.

Кушымта:
Кемнәр әйтер гөлем дип,
Кемнәр әйтер алым дип.
Кемнәр әйтер гомерлеккә
Булчы минем ярым дип.

Ак каеннан алдым буй-сынны,
Чишмәләрдән җырлар өйрәндем.
Гүзәллеген салдым җырыма
Болындагы барлык гөлләрнең.

Кушымта.

Һәрбер кошка җылы яз кирәк,
Һәрбер жанга йомшак наз кирәк.
Тормыш җырын бергә җырларга
Чыдам кыллы моңлы саз кирәк.

Кушымта.

*2004*

## СИН КАЙДА

Әтием, күзләрең ни төсле,
Мин инде аларны онытмыым.
Гомерем буена, җан әрнеп,
Әтиле кызларга кызыктым.

Кушымта:

Кимсенеп яшьләрем тамганда
Җилләрдән сорадым: син кайда?
Күзләрең, сүзләрең онытылды,
Ә үзең яшәдең гел җанда.

Әтием диясе килгән чак
Күп булды, күп булды, күп булды.
Кайчакта рәнҗүдән, үпкәдән
Күкрәктә тыннарым буылды.

Кушымта.

Мин инде буй җиткән кыз бала,
Күп кенә егетләр күз сала.
Әнием язмышын күрәм дә
Сөюгә ышаныч югала.

Кушымта.

Әтием, синең дә мине бер
Күрәсең киләдер, ышанам.
«Кызым» дип каршыма килсәң дә,
«Әти» дип мин сине кочалмам.

Кушымта.

*2004*

## ТУГАН КӨН

Бүген синең туган көн бәйрәмең,
Туу үзе бәхет ул җиргә.
Гомер буе шушы бәйрәмнәрне
Каршыласак иде без бергә.
Йөрәкләрне йөрәкләргә бәйләп,
Күзебезне алмый күзләрдән,
Һәрвакытта олы максатларга
Барсак иде бер үк эзләрдән.

Кушымта:

Син тугансың якты бу дөньяга,
Җирдә ул көн йолдыз кабынгандыр.
Шул йолдызның серле нурларыннан
Син барачак юллар салынгандыр.

Әнкәң дә бит сиңа бәхет теләп,
Бишегеңдә назлап тибрәткән.
Җан җылысын җырларына салып,

Яшәү серләренә өйрәткән.
Дөнья гамен онытдырып торсын
Туган көнең — олы бәйрәмең.
Гел кояшлы, якты гына булсын
Язың, көзең, кышың, җәйләрең.

Кушымта.

*2004*

## АШКЫНУ

Офыклардан кошлар очып бара,
Серле язмышлары каршына.
Кошлар белән очып китәрмен күк,
Әй ашкына йөрәк, ашкына.

Кушымта:
Йөзләргә ут капкан,
Йөрәккә ут капкан.
Дөрлимен, янамын —
Яратам, яратам, яратам.

Сөю алмалары учка төшәр,
Бәхет капкаларын ач кына.
Чиксезлеккә, серле чиксезлеккә
Әй ашкына йөрәк, ашкына.

Кушымта.

Шатлыгымны уртаклашыр өчен
Йөгерәләр гөлләр каршыма.
Язларыма, назларыма таба
Әй ашкына йөрәк, ашкына.

Кушымта.

*2004*

## ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР ЯНАР ЧАК

Чаба-чаба язлар килә
Кыңгыраулы пар атта.
Ничек инде ашкынма син,
Ничек инде яратма.

Кушымта:
Тыпы-тыпы, тыпы-тыпы
Биешәләр тамчылар.
Тамчыларга кушылып бии
Йөрәктәге ярсулар.

Ашкыну, дәртләр өстәлә
Язгы ерганакларга.
Җанга сыймаган хыяллар
Китәләр еракларга.

Кушымта.

Яз белән яшьлек — игезәк,
Күңелләре җилбәзәк.
Ага бозлар, кала кызлар,
Ташуларга кул изәп.

Кушымта.

Язлар килә, язлар килә,
Сулар үргә агар чак.
Хисләргә утлар кабынып,
Яшь йөрәкләр янар чак.

Кушымта:

Тыпы-тыпы, тыпы-тыпы
Биешәләр тамчылар.
Тамчыларның биюенә
Кушыла безнең ярсулар.

*2005*

## БӘРГӘЛӘНӘ ЙӨРӘК

Күзләрең һәм сүзләрең
Сөйлиләр төрле-төрле.
Кит, әйдә, китә алсаң,
Тыйма үз күңелеңне.
Дөрес әйткән көнчеләр:
«Ахыры булмас хәерле.
Мондый көчле мәхәббәт
Булмас озын гомерле».
Инде алар булыр шат,
Сүзләре бит булды хак.
Тик минем җаным гына
Бәргәләнә, сызлана.

Кушымта:

Утларга салдың,
Аңламый да калдым.
Син идең бердәнбер
Сөйгән ярым.
Барыбер сине
Оныта алмам һич тә.
Күктәге Ай шаһит,
Ул төшерер искә.

Син оныттың барсын,
Шундый җиңел генә.
Башка ярлар якын
Хәзер күңелеңә.
Безнең сукмакларда
Үсә башка гөлләр.
Кошлар белән очты
Бергә булган көннәр.
Ә шулай да бәгырь
Өзгәләнә, яна.
Синнән башка ярлар
Кирәк түгел аңа.

Кушымта.

## ЯЗМЫШЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРИК

Ялгыз калган көнем
Искә төште бүген,
Сагындырып.
Хисләремне тыеп,

Йөрдем эчкә җыеп,
Ялындырып.

Кушымта:

Күңелнең гөлләрен,
Гомернең көннәрен
Учакларга якмыйк, якмыйк.
Көннәр күп дип алда,
Калмыйк ялгыз ярда,
Өмет булсын җанда
Һәрвакыт.

Хисләр инде янган,
Кабатламыйк һаман
Ялгышларны.
Яшик көнләштереп,
Яшик берләштереп
Язмышларны.

Кушымта.

*2005*

## ТАПТЫМ МИН ҮЗЕМНЕ

Мин үземне озак-озак эзләдем,
Кайда гына калмадылар эзләрем.
Кичеп чыктым шаулы диңгез суларын,
Ярсу дулкын ул миндер дип уйладым.

Кушымта:

Җил белән як-якка
Таралды дулкыннар.
Калды тик күңелдә
Сагышлы уй-моңнар.

Йолдызлардан эзләп йөрдем үземне,
Ай-көзгедән карап тордым йөземне.
Ләкин никтер тонык иде Ай-көзге,
Ачык итеп күрсәтмәде ул йөзне.

Кушымта:

Ай йөзен сөртергә
Тапмадым ак болыт.
Кайттым үз җиремә
Йолдыздай атылып.

Мин үземне карурманнан эзләдем,
Очраттым тик төрле җәнлек эзләрен.
Күңелем тулды. Утырып уйлар уйладым.
Кошлар булып күккә очты уйларым.

Кушымта:

Шул чакта күрдем дә
Кояштай йөзеңне,
Синең саф күзләрдә
Таптым мин үземне.

*2005*

## СИНЕҢ ЙӨРӘК АҢЛАРМЫ?

Мин гомремне багышладым сөюгә,
Янам, көям исемең телгә килүгә.
Синең җаның минем җанны аңлармы,
Синең җан да минекедәй янармы?

Сиңа атап җырлар җырлыйм, моңланам,
Айлы кичтә Айга карап уйланам.
Минем җырым сиңа барып җитәрме,
Йөрәгеңне мәңге әсир итәрме?

Мин гомремне багышладым сөюгә,
Рәхәт табам сөюдә һәм көюдә.
Синең йөрәк мәхәббәткә әзерме,
«Мин дә сөям», — дип, йөрәгең әйтерме?

Минем җаным тик сөюдән көч ала,
Туктамый ул: иртә яна, кич яна.
Канатланам, керфек сирпеп карасаң,
Нишлим инде, яратам бит, яратам.

*2005*

## ЯРАТЫП ЯРАТТЫРАМ

Минем башка тылсымым юк,
Яратып яраттырам.
Кирәк икән, тургай булып
Күкләрдә сайрап торам.
Сайрый-сайрый, сайрый-сайрый
Барыбер яраттырам.
Кояш нуры булып тулам
Моңсуланган күзләргә.
Гөлләр булып үсеп чыгам
Ул йөрегән эзләргә.
Матур гөлне ул күрсен дә
Үрелсен дип өзәргә.
Диңгезләр булып ярсыймын,
Дулкыннар булып чабам.
Йолдызлар юлы буенча
Якты моң булып агам.
Якты моң булып агам да
Күңел кылларын кагам.
Хисләрем янар тау минем,
Туктаусыз кайнап торам.
Ялынып түгел, табынып түгел,
Яратып яраттырам.
Мәхәббәтнең серен белдем,
Яратып яраттырам.

*2005*

## БЕЗ ЯНАР ӨЧЕН ТУГАН

Зур мәхәббәт тик бер генә килә,
Мәхәббәт ул — яшьлек бүләге.
Бу бүләкне алыштыра алмый

Иң зур байлыклар да җирдәге.

Кушымта:

Без сөяр өчен туганбыз,
Без янар өчен туган.
Без барабыз бәхетебезгә
Мәхәббәт сызган юлдан.

Шушы сөю, шушы мәхәббәтнең
Утын йөртсәк кенә йөрәктә —
Яшьлек һаман безнең белән калыр,
Без кайларда гына йөрсәк тә.

Кушымта.

Бернәрсә дә ике тапкыр килми,
Үтә бар да аккан су кебек.
Яшик әле гел бәхетле булып,
Яшик әле сөеп, сөелеп.

Кушымта.

*2005*

## ГӨЛҖИМЕШ

Чәчәкләрең аллы-гөлле,
Сабакларың энәле.
Өсләреңдә һәрвакытта
Матур бәйрәм күлмәге.

Гөлҗимеш, гөлҗимеш,
Куагыңда мең җимеш.
Шул мең җимеш арасыннан
Бирче миңа бер җимеш.

Матурлыгың сокландыра,
Иркәли гел күземне.
Чәнечкеле җимешеңне
Ирнем белән өзимме?

Гөлҗимеш, гөлҗимеш,
Куагыңда мең җимеш.
Шул мең җимеш арасында
Юкмыни минем өлеш?!

Кердем, өздем бер җимешен,
Озак уйлап йөрмәдем.
Тырналып бетте битләрем,
Канады иреннәрем.

Чәнечкеле булса да, ул
Иң татлы җимеш булды.
Минем өлешемә тигән
Иң затлы көмеш булды.

*2006*

## ЯШЕЛ АЛМА

Яшьлек бит ул — яшел алма,
Тизрәк пешәсем килә.

Чык суларында коенып,
Нурлар эчәсем килә.

Кушымта:

Их килә, килә, килә,
Чибәр буласым килә.
Җилләрдә тирбәлеп үскән
Гөлләр буласым килә.

Машиналар туктап калсын,
Мин урамда йөргәндә.
Бер елмаеп алсын әле
Кысылган иреннәр дә.

Кушымта:

Их килә, килә, килә,
Килә матур буласым.
Мине күргәч, һәрбер йөздә
Якты нурлар уйнасын.

Мин карасам, яшь егетләр
Тигез җирдә абынсын.
Уты сүнгән йөрәкләрдә
Сөю уты кабынсын.

Кушымта:

Их килә, килә, килә,
Йолдыз буласым килә.
Яндырырлык, көйдерерлек
Ут кыз буласым килә.

*2006*

## БЕЗНЕҢ ЙОЛДЫЗ

Сүнәр өчен диеп кабынмады
Безнең йолдыз кара төннәрдә.
Яна-яна җиргә төшә калса,
Әйләнер ул гүзәл гөлләргә.
Ул гөлләрне өзәр гашыйк парлар,
Тик ялгызлар өзмәс аларны.
Өзгән гөлен бирер кеше тапмый
Телгәләнер ялгыз җаннары.

Кушымта:

Күктә ялгыз Ай,
Йөзе сагышлы.
Җиңел түгелдер
Аның язмышы.
Үз парын эзләп
Төннәр гизәдер.
Салкын ялгызлык
Бәгърен өзәдер.

Айга карап чумам хыялларга,
Ай тәгәрәп төшә алдыма.
Ике ялгыз бер пар булмаса да,
Рәхәт булып китә җаныма.
Өмет уты кабына йөрәгемдә,
Безнең йолдыз әле яначак.

Әгәр аның нуры кими төшсә,
Мәхәббәттән якты алачак.

Кушымта:

Айга иптәшкә
Килде Зөһрә кыз.
Ул хәзер парлы,
Түгел ул ялгыз.
Айның йөзеннән
Юылды сагыш.
Беркөн миңа да
Елмаер язмыш.

*2006*

## СОҢ БУЛЫР

Син бит мине үлеп яратасың,
Ник йөрисең аны яшереп?
Бетмәсме соң кайнар хисләрең дә
Йолдыз нурларыдай чәчелеп?

Кушымта:

Син булмасаң
Яннарымда,
Учак сүнәр
Җаннарымда.
Ярдәм итмәс
Үкенүләр,
Ярдәм итмәс
Үтенүләр.

Бер-бер артлы көннәр очып тора,
Һәр яңа көн кертә үзгәреш.
Мәхәббәтне җанда ялгыз йөртмик,
Зур сөюне син дә күтәреш.

Кушымта.

Алда әле бар да, алда димик,
Көннәр озын — гомер бик кыска.
Сөюнең бит бөтен матурлыгы
Күренә бары бергә очышта.

Кушымта.

*2006*

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

# Балачак

*Әй балачак, балачак,*
*Хәтерләрдә мәңге сүнмәс*
*Учак булып калачак.*

## ӨЙДӘ КАЛАМ

— Әти, эшкә барасыңмы?
Иярт әле, мин дә барам.
— Юк, юк, эшкә түгел әле,
Башка җиргә барам, балам.

— Ә, клубка, киногамы?
Мин дә барам, әти, яме?
— Юк, юк, балам, клубка дип
Җыенуым түгел әле.

— Кая барсаң да ияргм...
— Мин мәктәпкә барам, балам.
— Ә алайса, әти җаным,
Мин бүгенгә өйдә калам.

*1961*

## КҮПМЕГӘ ЗЫЯН

Бер куян, бакчага кереп,
Кимергән ун алмагач.
Һәр ел саен ун сум табыш
Биргән булган бу агач.

Бу куянны хуҗа атып
Саткан ун сум акчага.
Үз хакыңнан шушы куян
Ничә тапкыр артык зыян
Китергән бу бакчага?

*1961*

## ҮПКӘ

Мин песнәк ашатам
Һәр көнне кич-иртә.
Ачыкса, песнәгем
Тәрәзәгә чиертә —
Килгәнен белгертә.

Кулга да өйрәнде,
Курыкмый һич кенә.
Шунсы бик начар шул —
Үсми ул һич кенә —
Һаман да кечкенә.

*1961*

## ТУЙДЫМ ИНДЕ БУ КҮЛМӘКТӘН

Туйдым инде бу күлмәктән,
Тузмый да тузмый һич тә.
Әни аны алган иде
Яшем тулганда бишкә.

Хәзер миңа алты инде,
Ә күлмәк тишелми дә.
Күлмәк алам дигән сүзләр
Әле ишетелми дә.

Яза белсәм, язар идем
Газетага теләкне:
Фабрик апа бик нык итеп
Текмәсен дип күлмәкне.

*1962*

## ӘЛЛӘ КЕЧЕ, ӘЛЛӘ ЗУР

— Мин бит инде бик зур, —
Ди кайвакыт Зиннур.
— Кинога барыйм мин дә,
Каласым килми өйдә.

Берәр эш кушсаң аңа,
Бик тиз хәйләсен таба:
— Мин бит әле кечкенә,
Яшем бары биш кенә.
Эшләрмен, — ди, — үскәчтен,
Сезнең яшькә җиткәчтен.

Аптыраашта әткәсе,
Гаҗәпләнә әнкәсе:
Белмибез, диләр, Зиннур
Әллә кече, әллә зур!

*1962*

## БҮРЕККӘ ХУҖА ТАБЫЛДЫ

Нинди генә җәфа чикми
Габделхак кигән бүрек.
Йә ертыла, йә сүтелә,
Туптай тибелеп йөреп.

Беркөн Габделхак шакката
Шундый могҗиза күреп:
Песиләре балалаган —
Оя булган бит бүрек.

Менә сиңа кирәк булса,
Тапканнар җылы урын.
Җитмәсә, сукыр песиләр
Имәләр бүрек йонын.

Файдасызга аунатканчы
Төрле җирдә типкәләп.
Мәче балалар үстерә,
Бу бүректә иркәләп.

*1962*

## ЭТЮД

Башкортстанның таллары
Башларын игән Ыкка,
Күрешергә теләгәндәй,
Кул сузып безнең якка.

Башкортстан талларының
Сузылган кулын күреп,
Чәчләрен җилдән тарата
Безнең яктагы зирек.

Ык та ул җирдә тарайган,
Җитсен дип талның буе.
Белмим инде кайчан булыр
Бу гашыйкларның туе.

*1962*

## АҢЛАМЫЙМ МИН АБЫЙНЫ

Минем абый спортсмен,
Беләге шундый юан:
Аның күлмәк җиңенә дә
Мин башым белән сыям.

Ике потлы герләрне ул
Бер бармак белән чөя.
Җилкәләре шундый чыдам,
Хет бер йөк утын төя.

Тик кайвакыт ни өчендер
Аңламыйм мин абыйны:
Күрше Гөлсем апа керсә,
Хәтерләтә сабыйны.

Җилкәләрен салындырып,
Ул тәмам тирләп төшә.
Әйтерсең класс алдында
Авыр мәсьәлә чишә.

*1962*

## КАЯН БЕЛГӘН?

Барыйлар бүген дәрестә
Үттеләр «алмаш токны».
Тик Барый дәрес буена
Сөйләп утырды юкны.

Кайткач, Барый токны сыный,
Патронга бармак тыгып.
Ә ток куәтле батырдай
Ега Барыйны сугып.

Бераз айный төшкәч, Барый
Уйлана башын иеп:
«Минем дәрес тыңламауны
Ток каян белгән?» — диеп.

*1962*

## БИЯЛӘЙ

Бияләйдә бармаклар бит
Җылыналар кысышып.
Шуңа күрә салкында да
Алар йөрмиләр өшеп.

Тормышта да бергәләшеп
Яшәсәң генә җылы.
Катып, туңып калмыйм дисәң,
Онытма, дускай, шуны.

*1962*

## САБЫР САБИР

Сабыр Сабир дип йөртәбез
Сабирны без үзара.
Бик сабыр ул, беркемне дә
Теләми һич узарга.
Контроль эшләрне башлый,
Башкалар бетергәндә:
Сабырлык та кирәк икән,
Кешедән күчергәндә.
Такта янына чыкса да
Көтә ашыкмый гына.
Берәрсенең пышылдавы
Кергәнче колагына.
Утырып калды класста
Сабыр дустыбыз Сабир:
«Әй, ашыгып ни эш бар соң,
Итәм әле, — ди, — сабыр».

*1962*

## КАЙЧЫ ҺӘМ ЭНӘ

Бер нәзек энәгә кайчы
Дәшә ди болай көлеп:
— Син шулкадәрле кечкенә,
Үсә алмыйсың һич кенә
Зур булып минем кебек.

— Син, кайчы дус, дәү булсаң да,
Турап кисәсең генә.
Ә мин әйберләрне тегәм,
Зурайтам, матурлыйм, чигәм, —
Дип җавап биргән энә.

*1962*

## МАКТАНУ БӘЛАСЕ

Уйната песи тычканны,
Бер җибәрә, бер тота.
Кача башласа корбаны,
Мыраулый да куркыта.

Күзләрен йомган була ул,
Тәпиен сузган була.
Койрыгын идәнгә бәреп,
Яныннан узган була.

Ярык янына китерә
Этеп-төртеп тычканын.
Һәм... үзе дә сизми кала
Табышының качканын.

Бер уңыш белән мавыгып
Эшләмәсәң башка эш,
Ярыкка качкан тычкандай,
Тиз юкка чыга уңыш.

*1962*

## СОРЫ БОРЫНЛЫ КОШЧЫК

Агач башында ояда
Сары борынлы кошчык
Әй талпына, әй талпына,
Китәргә тели очып.

— Канатларың ныгый төшсен,
Үрелмә, кошчык, күккә.
Җиргә бер дә төшми генә
Менеп булмый ул күккә.

*1962*

## ВАРИС

Бер үсә, бер кечерәя —
Шул сыйфат хас Вариска:
Ун төрлегә әйләнә ул
Бер сәгатьлек дәрестә.
Укытучы караганда,
Партадан чак күренә.

Ә читкә борылса, үсә —
Өч партага үрелә.
Тагын шул вакыт зурая —
Дәресен яхшы белсә.
Кеше җилкәсенә поса,
Әгәр укымый килсә.
Менә шундый кеше инде
Безнең дустыбыз Варис:
Бер була ул ике метр,
Бер була ике карыш.

*1962*

## АШЫК-ПОШЫК ГАЛӘВИ

Һәрбер эшне Галәви
Ашык-пошык әвәли.
Бетермисең эш кушып,
Китә Галәви очып.

Баргач, эшен оныта,
Кире өйгә юл тота.
Кабат эшләп һәр эшен,
Түгә ул юкка көчен.

*1962*

## КҮЧӘР ҺӘМ ТӘГӘРМӘЧ

Берчак күчәр тәгәрмәчкә болай дәшә:
— Йөкнең бөтен авырлыгы миңа төшә.
Мин токтасы бөтен җирнең һәрбер җирдә,
Ләкин никтер мактамыйлар мине бер дә.
Күчәрдән соң сүз алалар тәгәрмәчләр:
— Юк, күчәр дус!
Без булмасак туктый эшләр,
Бөтен йөкне тәгәрмәчләр сөйрәп бара;
Бездән башка берәр йөкне тартып кара.
Бәхәс кыза, шул вакытны күчәр сына.
Тәгәрмәч тә ватылып җавап бирә моңа —
Күчәр белән тәгәрмәчне алыштырып,
Кеше китә йөкне шул аттан тарттырып.

*1962*

## ГАДЕЛША КОМАНДАСЫ

### I

Күкрәген бераз киереп,
Күлмәк изүен ачып,
Сөйли башлады Гаделша,
Агач төбенә басып:
— Малайлар, мине беләсез,
Сүзем бар, солдатларым! —
Һәм бар да тынып калдылар,
Торгызып колакларын.
— Бүгеннән әзерләнегез

Бик кызыклы походка,
Иртәгә шушында сбор
Күрсәтелгән вакытка.
Сәгыйть, син алып килерсең
Өегездән бер чиләк.
Сәгыйть әйтте командирга,
Үрә катып: — Бик теләп!
— Ә син, Хәлим, әзерләп куй
Бик яхшы имән таяк.
— Есть, — дип кычкырды Хәлим,
Бәреп аякка аяк.
— Син, Фираз, бик төз атасың,
Бер рогатка әзерлә!
— Әзер булыр!
— Ярый, дуслар,
Сүзем бетте хәзергә.

**II**

Тау артыннан күзен ачып
Караса кояш иртән —
Малайлар шул ук урынга
Җыелып килеп җиткән.
Утлы күмердәй ялтырый
Малайларның күзләре,
Бик кызыклы булса кирәк
Гаделшаның сүзләре.
— Йомран ауларга барабыз,
Сезне шуңа чакырдым.
Авыл артындагы басу
Ике генә чакырым.

**III**

Малайлар да бик канәгать,
Барсы да дәртле, көчле;
Йомран түгел, аюны да
Тота алырлар төсле.
Эшлиләр алар шаулашып,
Дәшми Гаделша гына.
Сүзгә катнашып куя ул,
Эшкә кагылса гына.
Хәлимнең имән таягын
Чиләк сабына кертеп,
Сәгыйть, Хәлим су ташыйлар,
Маңгай тирләрен сөртеп.
Тирән чокырга су коя,
Чиләкне җайлап тотып,
Ә оя төпсез коедай
Тора бар суны йотып.
Фираз оста снайпердай,
Үз рогаткасы белән
Атып, чәкеп кенә тора
Йомранны берәм-берәм.
Аткан йомранын тотарга
Барса Фираз йөгереп —
Ай, ни хурлык! Карагызчы,
Йомраны китә кереп.
...Гаделшага карадылар
Малайлар, ярдәм сорап.
Гаделша да уйга калды,

Чабуын кулга урап.
Икеләнеп командирга
Карап торды да бераз:
— Дуслар, миндә бер тәкъдим бар, —
Дип сүз башлады Фираз.
— Минем сүзем тик шул гына,
Чыбык кирәк тозакка.
— Нинди тозак, нинди чыбык?
Сөйлә, сузма озакка.
— Нинди диеп... Тимер чыбык.
Шуннан тозак корасың.
Тозак булса, йомраннарны
Чүпләп кенә торасың.
Җан өргәндәй тәэсир итте
Яңа фикер төркемгә.
Унбишәр тозак ясарга
Приказ булды һәркемгә.
Шунда гына тойды алар
Бик каты аруларын.
Учак ягып җибәрделәр,
Җыеп кыр кураларын.
Ашадылар бәрәңгене,
Эчләрен төя-төя:
— Моннан да тәмле азыкны
Күргән юк! — дия-дия.

**IV**

Тозак әйбәт. Зур табыш бар
Алар кулында бүген.
Биш малайга утыз йомран, —
Ул бит уен эш түгел.
Сөйләшеп кайттылар алар,
Берсен-берсе бүлешеп,
Гел юк кына нәрсәдән дә
Чын күңелдән көлешеп.
Авылда да бар сүзләре
Булды йомран турында.
Сөйләделәр уңышларын
Һәр җай чыккан урында.
Ай буена йөрде алар
Һәр көн саен сунарга.
Өйрәнделәр тотарга да,
Тиресен дә тунарга.

**V**

Идарәгә чакырттылар
Команданы бервакыт.
Малайларның бөтенесе
Калды кинәт шаккатып.
Зариф әйтте: — Ул йомраннар
Колхозныкы булгандыр.
Хәзер безне председатель
Судка бирә торгандыр.
...Аяк очка басып кына
Үтте малайлар түргә,
Утырдылар кысылышып:
— Ни күрсәк, күрик бергә.

Сүз башлады председатель
Мыегын бөтерде дә,
Урындыгын малайларга
Якынрак китерде дә:
— Бу эшне кем оештырды?
Кем сезгә киңәш бирде?
Йә, әйтегез, тартынмагыз,
Кайсыгыз башлап йөрде?
Диванга сеңде малайлар,
Башларын түбән иеп.
Ә Гаделша торып басты,
Ни булса булыр диеп.
Председатель шкафыннан
Тартып алды бер төргәк.
Малайларның күзләрендә
Очкыннар китте дөрләп.
— Кырдыгыз сез игеннәрнең
Иң әшәке дошманын,
Шуның өчен бүләклибез
Бүген сезне, дусларым...
Председатель малайларга
Бирде фотоаппарат,
Малайлар бар да ах итте,
Әйбәт бүләккә карап.

*1962*

## МАЭМАЙ-ХУДОЖНИК

Йомшак җепшек кар өстендә
Маэмай ята сузылып,
Кояш нурлары астында
Ялкау гына кызынып.

Тәпиенә башын салган,
Колакларын шиңдергән,
Койрыгын да селкетми,
Әйтерсең тәмам үлгән.

Менә кинәт торып басты —
Ахры, түше өшегән.
Ап-ак кар өстенә маэмай
Үз рәсемен төшергән.

*1963*

## ОНЫГЫ ҺӘМ ӘБИСЕ

Әй шатлык Шәрифкә —
Иртәгә сентябрь.
Хәзер гел барыр ул
Мәктәпкә көн дә бер.

Күңеле очына,
Куана, шатлана.
Йөрәктә ашкыну,
Йөрәктә тантана.

Тик менә әбисе
Берүзе кала бит.
Куркыныч булмасмы
Шәрифсез аңа бик.

— Әбекәй! — ди Шәриф, —
Иртәгә сентябрь.
Бергәләп йөрербез,
Укырга син дә кер.

*1963*

## ОКТЯБРЬ

Кар төшә җиргә иренеп,
Теләр-теләмәс кенә.
Җил йөри кураен өреп,
Көйләр-көйләмәс кенә.

Болытлар иске толыптай,
Асылынган-салынган.
Күк бүген алама тунын
Катлый-катлый ябынган.

Бер карала, бер агара,
Юллар тора алмашып.
Кыш килә туң җир өстеннән,
Курыкмый дөп-дөп басып.

*1963*

## КӨЙСЕЗ БАЛА

Кемгә генә килеп кермә,
Була бер көйсез бала.
Һәркем шуңарга карый да
Шакката, телсез кала.
Дустыңа бер сүз әйтим дим
Тибрәтсәң син телеңне —
Шул бала килеп кысылып
Чуалта зиһенеңне.
Хуҗа оныта дөньясын,
Аш куйса — ашы ташый,
Ваннасына су җибәрсә,
Өен су баса башлый.
Ә бала — заман баласы,
Юк аның белмәгәне:
Көләсең дә, елыйсың да
Тыңлап ул сөйләгәнне.
Әгәр аның көе китсә,
Эшләр начар тагын да:
Әллә кемнәрне такмаксыз
Биетә ул янында.
Көйсез бала — телевизор,
Һәркемнең күз уңында.
Ничек яшәдек икән без
Телевизор югында?!
*1963*

## ТАКЫРБАШ

Такырбаш та Такырбаш дип
Атап йөрттеләр аны.
Чәчен кырдырып йөргәнгә,
Шулай таралды даны.

Вакыт узды, озакламый
Чәч үсте Такырбашка.
Кушаматы да үзгәрде,
Әйләнде Бакырбашка.

Тагын көннәр үтә торды,
Тагын үзгәрде исем.
Бу юлы исем алды ул
Яхшы укыган өчен.

Такырбаш та онытылды
Һәм бетте Бакырбаш та.
Хәзер инде кушаматы
Әйләнде Тапкырбашка.
*1963*

## БЕРГӘ-БЕРГӘ

Синдә җыр бар,
Миндә җыр бар —
Матур җырлар бик күп җирдә.
Синең җырың миңа күчсен,
Минем җырым сиңа күчсен —
Җырлыйк әле бергә-бергә.

Синдә кул бар,
Миндә кул бар —
Тотынышыйк син дә, мин дә.
Синең шатлык миңа күчсен,
Минем шатлык сиңа күчсен —
Уйныйк әле бергә-бергә.

Синдә уй бар,
Миндә уй бар —
Уйлар бар ул һәр күңелдә.
Синең уйлар миңа күчсен,
Минем уйлар сиңа күчсен —
Уйлыйк әле бергә-бергә.
*1963*

## ЭЗЛӘДЕМ, ДИ, АПАСЫН

Кайтып керсәм, мөлдер-мөлдер
Утыра елап энем.
— Тагын нәрсә булды инде,
Нигә елыйсың? — дидем.

Өстәлемә күз төшерсәм,
Өстәлдә эшләр харап.
Телевизорны сүткән бу —
Ай энем, Марат, Марат.

Эчтән лампаларын алып

Өеп куйган барчасын.
Нишләдең син, дигән идем,
Эзләдем, ди, апасын.

*1963*

## НИНДИ САВЫТ ТӘМЛЕРӘК

Нинди савыттан ашасаң
Тәмлерәк була аш-су?
Шул сорауны чишә алмый
Уйлана нәни Алсу.
Моңа кадәр ашады ул
Көмеш савыттан гына;
Хәзер инде сөйми аны —
Сәбәбе юктан гына.
Бервакытны әниләре
Киткән иде кунакка.
Алсу үзе аш пешерде
Беркем югында чакта.
Алюмин савытка салып
Ашады аны Алсу.
Ашы шундый тәмле иде,
Ник бер тамчысы калсын.
Шуннан бирле бертуктаусыз
Уйлана безнең Алсу:
«Нинди савыттан ашасаң
Тәмлерәк була аш-су?»

*1963*

## ХИКМӘТЛЕ СҮЗ

Бер сүзне күп сөйләсәм,
Аны тәмам «иләсәм»,
Тирги мине һәммәсе:
Туйдырамын, янәсе.

Ә мин шундый сүз беләм,
Ул сүздән туймый һичкем.
Тиргәмиләр, сүкмиләр,
Сөйләп торсаң да өч көн.

Кыен түгел әйтергә,
Бик ансат, рәхәт үзе.
Сезгә дә өйрәтәм аны:
Ул була «рәхмәт» сүзе.

*1964*

## МАЛАЙ ТАКМАГЫ

Күкне болыт каплап алган,
Кар ява бүрек-бүрек.
Рамат карый тәрәзәдән,
Сулышын өреп-өреп.

Юллар ап-ак, өйләр ап-ак,
Түбәләр тау булганнар.
Агачлар муеннарыннан
Көрткә кереп чумганнар.

Тәрәзәгә карый-карый
Такмаклый Рамат шунда:
— Әй, болытлар, болытлар,
Карны ишмәгез монда.

Көш, көш, көшегез,
Бүтән җиргә күчегез.
Әнкәй юллар чистарта,
Ераккарак төшегез.

*1964*

## ИҢ МАТУР ҖИР

Апаларына кунакка
Шәһәргә килә Дилбәр.
Апасы аңа шәһәрдә
Күрсәтә әллә ниләр.

Алып бара зоопаркка,
Йөртә аны музейда.
Кайтасы килми Дилбәрнең,
Шәһәр ошый кызыйга.

Йөри торгач арый Дилбәр,
Һәм сусый эсселектән.
Апасы газлы су алып
Бирә аңа кибеттән.

Апасы сорый Дилбәрдән:
— Шәһәр матурмы? — диеп.
Дилбәр әйтә: — Иң матур җир
Газлы су эчкән кибет.
*1964*

## КЕЧКЕНӘ ПАТША

Егермедән артык вәзир
Бер кечкенә патшага.
Җитмәсә, сакчы куелган
Як-яктагы капкага.

Бу патшаны вәзирләре
Гел типкәләп йөртәләр.
Баш белән һәм аяк белән
Этәләр дә төртәләр.

Вәзирләр куалар аны
Менә шулай куркытып.
Капкага килсә керергә,
Сакчысы ала тотып.

Вәзирләре — уйнаучылар,

Патша дигәнем — туп ул;
Әйтмәсәм дә белгәнсездер,
Бу уен була футбол.
*1964*

## КӨЧ БИРӘСЕҢ МИҢА СИН, МУСА

Әллә сине артык яратканга,
Әллә язмыш бераз уртакка, —
Авырлыклар килсә, таянамын
Сиңа, Муса, синең китапка.

Кыен чакта, өметләрем киселеп,
Тормышымнан күңелем суынса,
Көрәш, дускай, көрәш, туктама, дип
Эндәшәсең кебек син, Муса.

Моабитның юеш стенасын
Кимергәндә ачлык өрәге, —
Син тудырдың утлы җырларыңны,
Белдең алар безгә кирәген.

Әйе, белдең безнең буыннарга
Җырларыңның кирәк буласын.
Авыруга дәва булачагын,
Егылганда терәк буласын.

Авыр язмыш палач балтасыдай
Янап тора миңа көн туса.
Авырлыкны ничек җиңү юлын
Өйрәтәсең миңа син, Муса.
*1964*

## СӘГАТЬ

Кичке сәгать болай суга:
Доң, доң,
Доң, доң!
Кече телем җитте унга
Бик соң,
Бик соң!
Җәй урының
Доң, доң!
Бик тын гына йөри төнлә
Тын, тын,
Тын, тын!
Йокламасаң да ят ди ул
Шым-шым,
Шым-шым.
Иртәләрен болай суга:
Тик-так,
Тик-так.
Уянырга вакыт җитте,
Калма йоклап,
йок-лап.
Уян нык-лап,
нык-лап!
*1964*

## АНА ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Түшәктә ята
Авыру ана.
Бик авыр аңа,
Бик авыр аңа.
Күзләре хәлсез,
Йөзләре сулган,
Гомер савыты
Мөлдерәп тулган.
Ялгыш кагылсаң,
Түгелер төсле,
Җиргә чык булып
Сибелер төсле.
Сәгатькә карый,
Минутлар саный.
Ә үлем якын,
Ә үлем яный.
Шул вакыт үлем
Әйтә анага:
«Сиңа ун елны
Өстим яңадан.
Ләкин шартым бар:
Бүләк гомернең
Тик үзең өчен
Яшә һәр көнен».
Авыру ана
Уйлый да улын,
Әйтә пышылдап:
— Юк, китмә, үлем.
Минем сулышны
Хәзер үк кис тә
Ун ел гомерне
Балама өстә.
*1964*

## ҮЛЕМСЕЗ ҖЫР

*(Баллада)*

Таш капчык-төрмә
Тыннарны кыса,
Кысан төрмәдә
Богаулы Муса.
Ишектә — йозак,
Кулларда — богау.
Дар агачында
Элмәкләнгән бау.
Тирбәлә бу бау,
Җил исеп куйса,
Чылтырый богау,
Кузгалса Муса.
Карар укылган —
Ул үлем көтә.
Ләкин йөрәкне
Бер җыр җилкетә.
Якын, бик якын
Күңелгә бу җыр.
Язып куярга —

Кулларда чылбыр.
Муса күңелендә
Яңа җыр кайный.
Тышта өздереп
Бер кошчык сайрый.
Ни гаҗәп: кинәт
Тәрәз ачыла,
Кош очып керә
Муса янына.
Мусаның җырын
Отып ала да
Очып китә ул
Иркен далага.
Кошчык бу җырны
Көйли гөлләргә,
Һәм күчә бу җыр
Телдән телләргә.
Бу үлемсез җыр
Гизә дөньяны.
Бу җырда яши
Шагыйрьнең җаны.

*1964*

## БАЛ КОРТЫ

Бал кортлары армый-талмый никтар ташый,
Гөлдән гөлгә куна-куна таңнан таңга.
Алар башта матур итеп кәрәз ясый,
Аннан инде җыйнаулашып оча балга.
Кешеләрнең күзләренә күренмичә,
Чәчәкләрдә генә булган тәмне җыеп,
Эшли алар янып-көеп сүрелмичә,
Эшләреннән ләззәт табып, тәмен тоеп.
Шагыйрьләр дә менә шундый бал кортлары,
Кешеләрнең күңелләрен тиңлим гөлгә.
Алар да бит чәчәкләрдән ширбәт җыя,
Бал иттереп кайтаралар һәр күңелгә.

*1964*

* * *

— Мин югары, син түбән,
Болытка тия түбәм, —
Дип әйтә икән кибән
Кечкенә чүмәләгә.
— Әйе, кибән, син биек,
Ләкин сине ясыйлар бит
Чүмәләләрне өеп, —
Дигән чүмәлә аңар,
Моны кем читкә кагар.

*1964*

## КҮКТӘ

Карап ятам төнлә йолдызларга —
Күк йөзенең чәчәк юрганын.
Йолдызларга карап ята торгач,

Искә төшә борчак куырганым.
Кызган борчак шулай кайвакытны
Очып чыга читкә табадан.
Йолдызлар да, кызган борчак кебек,
Түбән таба оча һавадан.
Йоклап китәм, карап ята торгач,
Йокыдан бит булмый тыелып.
Күкнең, ахры, кесәләре тишек,
Борчаклары тора коелып.

*1964*

## КҮКЕЛЕ СӘГАТЬ

Стенада, баш очымда
Күкеле сәгать тора,
Күкесе чыгып вакытны
Кычкырып санап тора.
Күке җидене кычкыртса,
Йокымнан торып басам.
Нәкъ вакытында уята,
Шәп сәгать бу, ичмасам.
Ә бервакыт кабаланып
Сикереп тордым кинәт.
Күке унбер күкелдәде,
Соңга калганмын, димәк.
Карасам сәгать өч кенә
Ялгышты икән ник бу?
Шулчак кинәт тал башында
Күке кычкырды: «Күк-күк!»

*1964*

## КОЯШ ҺӘМ КАЗ БӘБКӘЛӘРЕ

Җәйге эссе көн,
Исми бит җил дә.
Кояш та энә
Коена күлдә.
Шунда ук йөзә
Каз бәбкәләре.
Ә яннарында
Шат әнкәләре.
Бәбкәләр суга
Уйнап чумалар.
Күлдән кояшны
Тотмак булалар.
Кояш тоттырмый,
Китә читкәрәк.
Чукыйм дигәндә
Чума төпкәрәк.
Бәбкәләр арып
Чыгалар ярга.
Ә кояш күктән
Көлә аларга:
Тоттырмадым, ди,
Сезгә барыбер.
Төшәрмен әле

Күлгә тагын бер.
Әгәр төшмәсәм
Мин күлгә кабат,
Үзегез менәрсез
Үскәчтен канат.

*1964*

## ГАЙНИ

Киткәннәрме соң майлап?
Урамнар бүген тайгак.
Булмаса да этүче,
Егыла һәрбер үтүче.

Мәктәптән кайта Гайни,
Аның аягы таймый.
Итекләре дагалы —
Аның шул шәп чак әле.

Күрә Гайни: бер чатта
Бер карт егылып ята.
Йөгереп бара, торгыза,
Тагын шактый юл уза.

Барган саен отыры
Күбрәк очрый карт–коры.
Гайни күк ныклы терәк
Бик күп кешегә кирәк.

Кычкыра шулчак Гайни:
— Минем аягым таймый,
Ябышыгыз кулларга,
Егылмассыз юлларда!

Арыганнар, талганнар,
Егылганнар, ауганнар —
Бар да аңа тотына,
Зур бәладән котыла.

Командирдай иң алдан
Әй басып килә Гайни!
Уң ягында ун бабай,
Сул ягында ун әби.

*1965*

## АП-АК ИТКӘН

Чисталыкны бик ярата
Гөлгенә,
Битен-кулын юып тора
Гел генә.

Өс-башына һич тә керләр
Тидерми.
Курчакка да каткан күлмәк
Кидерми.

Артыграк тырышты шул
Ул бүген:

Юып куйды әнисенең
Бүреген.

Кара киез итеген дә
Юды ул.
Бар нәрсәне «ап-ак» итеп
Куйды ул.

Бөтен нәрсә әнә шулай
Ялт итте,
Кайтып кергәч әнкәләре
Аһ итте.

*1965*

## КОМПОЗИТОР ЧЫПЧЫКЛАР

Скрипка кылларыдай
Тартылганнар чыбыклар,
Шул кылларда көй уйныйлар
Композитор чыпчыклар.

Берсе арып туктадисә,
Икенчесе тотына.
Өченчесе шул көйләрне
Салып тора нотага.

Урамнарны яңгырата
Шушы чыпчыклар җыры.
Песи астан койрык болгый,
Ул — хорның дирижеры.

*1965*

## САБАНТУЙ

Бүген бездә сабантуй,
Эшләреңнең барын куй.
Тизрәк йөгер мәйданга:
Бәйрәм башлана анда.
Кемдә нинди һөнәр бар?
Йөгерергә кемнәр бар?
Кызганмый табаннарны
Урагыз мәйданнарны.
Ә көрәшә кайсыгыз?
Көч сынашып кайтыгыз.
Курыкмагыз егылудан,
Йөгереп артта калудан.
Ансыз булмый сабантуй,
Колагыңа киртләп куй.
Булмаса һөнәрегез,
Читтән карап йөрегез
Картлар чүлмәк ватканын,
Атлар чабышып кайтканын,
Көрәшчеләр бер-берсен
Җилкә аша атканын.
Карасагыз — бәйрәм бар,
Сусасагыз — әйрән бар.
Ял итәрсез арсагыз,
Үкенмәссез барсагыз.

*1965*

## КАЯ КИТКӘН ТАМЧЫЛАР?

Тәрәзәдән кулын сузып,
Бер сабый тамчы тота;
Саный: берәү, икәү, өчәү!
Ә дүрт санын оныта.
Кабат санап карарга дип
Учын ачып караса:
Искиткеч хәл, учта тамчы
Берәү дә юк лабаса.

*1965*

## БУШЛАЙ БИЛЕТ «САТАЛАР»

Клубка ашыга Галләм,
Клубта бүген кино.
Кинонын да иң яхшысы,
Иң шәбе — «Буратино».

Барып керсә, гаҗәп бер хәл,
Бер кеше юк кассада.
Бушка гына керә бүген
Малайларның барсы да.

Галләм аптырап торганда,
Эндәшә аңа Шәкүр:
— Бүген бит уңыш бәйрәме,
Кино бушка, әйдә кер.

Кайткан чакта Галләмнәргә
Очрый өлкән апалар.
Галләм әйтә: «Ашыгыгыз,
Бушлай билет «саталар».

*1965*

## ӘЛЛӘ КАЙЧАК...

Бер атнада җиде көн бар,
Мин моны күптән беләм.
Календарь битен санадык
Беркөн әнием белән.

Ә бервакыт бер атнага
Әни китте кунакка.
Ну озын да булды инде
Әнисез үткән атна.

Әйтсәм әйтим инде сезгә
Ул чак хәтта еладым.
Әллә кайбер атналарда
Көннәр күбрәк буламы?

*1965*

## АК БОЛЫТЛАР

Ак болытлар — самолетлар,
Җил аларның пилотлары.
Күктә йөзә, илләр гизә
Җирнең кысыр болытлары.
Разведкага йөри алар,
Кайда коры — шуны күреп.
Аннан яңгыр болытына
Шул турыда рапорт биреп.
Ак болытлар, вак болытлар,
Күк абзаның оныклары.
Җәен-кышын, язын-көзен
Ак аларның толыплары.
Кайчак тора зәңгәр күктә
Тезелешеп ак болытлар.
Әйтерсең лә аэродромга
Җыелышкан самолетлар.

*1965*

## ЯЗГЫ ПАРЧАЛАР

Боз китә елгада, боз китә,
Бозларга утырып кыш китә.
Елгалар ярсыган ат кебек
Тибешеп ярларны селкетә.

Зыңгылдап ярыла язгы боз,
Әйтерсең кыңгырау кагалар.
Салкыннар, бураннар җырлашып,
Ашыгып еракка агалар.

Кояш та җиңнәрен сызганган,
Эшли ул ашыга-ашыга.
Ә кырлар кайнаган казандай —
Ургылып-ургылып пар чыга.

*1965*

## МӨНИПНЕҢ ДӘФТӘРЕ

Укытучы дәфтәр карый,
Кемнеке чиста, ди ул.
Пөхтә итеп язарга
Кайсыгыз оста, ди ул.

Вәли кара тамызган,
Нали поляга сызган.
Гөлнар ике урында
Бармагы белән бозган.

Ә монсы Наза икән,
Бик чиста яза икән.
Һәр хәрефе килешле,
Назага тиеш бишле.

Шул вакыт шаян Мөнип

Кычкыра болай диеп:
«Иң чиста дәфтәр кемдә?
Назада түгел — миндә!»

Карасалар дәфтәрен,
Чынлап та дәфтәр чиста.
Чөнки Мөнип аңарга
Язмаган бер хәреф тә.

*1965*

## ЙОЛДЫЗЛЫ КИЧ

Бик матур бүген кич,
Күк йөзе сипкелле.
Ә түрдә — тулган ай,
Анысы миң шикелле.

Күк бүген болыттан
Пәрәнҗә япмаган.
Күз тияр диеп тә
Бер дә шаккатмаган.

Нур чәчә зур миңе,
Җемелди сипкелләр.
Матур да, күркәм дә
Йолдызлы бу кичләр.

*1965*

## ЯРЫК КОЙРЫК

— Кичәге карлыгач килгән,
Күрче, күрче, әтием.
Әнә ничек борыны белән
Чукып тора тәпиен.

— Бәлки, башка карлыгачтыр,
Каян беләсең, кызым?
— Әнә ич койрыгы ярык,
Шуннан таныдым үзен.

*1965*

## ОХШАШЛЫК

— Бабакай, сиңа охшаган
Кеше күрдем урамда.
Кәкре таякка таянып
Тора иде ул анда.

— Миңа охшаган иде соң
Ул бабайның кай ягы?
— Гел синеке төсле иде
Кулындагы таягы...

*1965*

## ФУТБОЛ

Малайларны җыйныйм мин,
Һәркөн футбол уйныйм мин.
Ләкин безнең капка юк,
Ә ясарга такта юк.
Шулай да уен кызык,
Табаннар бетә кызып —
Чабып тирләп-пешәбез,
Манма суга төшәбез.
Ашарга да кайтмыйбыз,
Ишегалдын таптыйбыз.
Купса куба табан да,
Туп тибәбез һаман да.
Шунысы кыен: кайткачтын
Әти әрләштергәли.
Чөнки туп, капка булмагач,
Тәрәзәдән кергәли.

*1965*

## БӘБИ КЕМГӘ ОХШАГАН?

Безнең әни алып кайтты
Шундый елак бер бәби.
Еласа да, әни үзен
Һич кенә дә тиргәми.

Мине хәзер оныттылар,
Юк өчен дә тиргиләр:
Өйгә бәби алып кайттык,
Син бит хәзер зур, диләр.

Әти карый да бәбигә:
— Нәкъ әнисе бу, — дия.
Ә әни сөйгән вакытта
— Нәкъ әтисе, — дип сөя.

Ә мин әйтәм, алай түгел,
Алар белеп сөйләшми:
Бәби бабайга охшаган,
Аның башы пеләш бит.

*1965*

## ТӨШЕРМӘДЕМ

Курыкканда уч төбенә
Төшә диләр йөрәкне.
Беркөн шулай юкка гына
Әти биргәч «кирәкне» —
Йөрәгем тибә дөп-дөп,
Учыңа төшәмен дип.

Кулым белән кысып тоттым
Йөрәкне бар көчемә,
Никадәр тыпырчынса да,
Төшермәдем учыма.
Бездә көч ул җитәрлек —
Куркуны юк итәрлек.

*1965*

## ҖӘЙ КӨНЕ ДӘ ШУАРМЫН

Иптәшләрем арасында
Минем генә юк чанам.
Әни, нигә син миңа да
Чана алмыйсың һаман?

Хәзер, кызым, җәй җитә ич,
Чана алмыйм шуңар мин.
— Син ал гына, чанам булса,
Җәй көне дә шуармын.

*1965*

## ӘНИЕМҺӨНӘРЕ

Минем әнием тегүче,
Үз эшен бик нык сөя;
Ул теккән җылы киемне
Бик күп кешеләр кия.

Үземнең дә хыялларым
Тегүче булу гына;
Минем хезмәтем дә бирсен
Һәркемгә җылы гына.

*1965*

## МОҢЛЫ МИНЕМ КУРАЕМ

Уйнар идем гармуным юк,
Җырлар идем — тавышым.
Кисеп алып курай иттем
Елгабызның камышын.

Камыш курай эчләрендә
Күпме моң булган икән.
Ул камышка җәйләр буе
Күпме кош кунган икән.

Һәрбер коштан моңнар алган
Елгабызның камышы.
Өргән саен саркып чыга
Шул кошларның тавышы.

Әйтәләр миңа кешеләр,
Моңлы, диләр, уйнавың.
Минем монда катнашым юк,
Үзе моңлы кураем.

*1965*

## ЧУАР ТАВЫК

Канат кагып, түш киереп

Масая чуар тавык:
— Мин чуар да, мин чибәр дә,
Кара миндәйне табып.
Арагызда мин бер генә
Алтын кебек каурыйлы.
Ә сез гади ак тавыклар,
Мин мактаулы, абруйлы.
Ак тавыклар әйтә аңа:
Син чуар, дип, сүзең хак.
Әмма синең йомыркаң да
Безнекедәй гади, ак.
Чуар тавык тынып кала,
Сөйләми ул сүз алып.
Масаер иде, булмый шул
Чуар йомырка салып.

*1965*

## БУШЛЫК

Өйнең эче яп-ялангач,
Белмимен, әллә нигә.
Кайтып керәсе дә килми
Бүген бөтенләй өйгә.

Бөтен нәрсә үз урынында,
Тик җитешми әллә ни...
Әй, онытып торам икән:
Өйдә юк бүген әни!

*1965*

## ТАПКАН ТӘМЛЕ НӘРСӘНЕ

Аптырыймын мин бәбигә,
Елап тора юкка да.
Кызыкмый ул аллы-гөлле
Сикереп торган тупка да.

Конфет тоттырсаң капмый да,
Ыргыта гел идәнгә.
Бер елмаеп та карамый,
Син бит тәти, дигәнгә.

Конфеттан да тәмле итеп
Бармагын имә генә.
Бар әйберен алсаң ал, тик
Бармакка тимә генә.

Шоколад биреп карадым,
Шуны да бит алмады.
Аннан да тәмле микәнни
Үзенең баш бармагы?

*1965*

## МАРТ КОЯШЫ

Кояш язга хәзерләнә,
Репетиция ясый.

Аяк асларын эретеп,
Юлларны бозып ташлый.

Йә, болыт белән төренеп,
Ялкау баладай йоклый.
Юрганын җил ачмый торып,
Болыт астыннан чыкмый.

Карларны да йомшата ул,
Мамык кебек иттерә.
Түбәләрне юешли дә
Аннан шуны киптерә.

Җылы яктагы кошларга
Телеграмма җибәрә:
«Кайтыгыз! — дип, — яз ясарга
Туган-үскән җирләргә».

*1965*

## АПРЕЛЬ

Апрель ае табигатькә
Зур үзгәрешләр ясый:
Кыш абзаңны буйсындырып,
Еракка илтеп ташлый.

Аннан инде гөрләвекләр
Җир-ананы уята.
Апрель-батыр, җиң сызганып,
Елгада бозлар вата.

Ул әле шәп дворник та:
Себереп ташлый юлларны,
Чокырларга илтеп түгә
Урамдагы суларны.

Апрель-батыр эшли көн-төн
Шулай ару-талусыз.
Май айлары шуңар да бит
Килә соңга калусыз.

*1965*

## МАЙ

Майның җылы сулышыннан
Игеннәр үсеп китә,
Чәчәк исләре аңкытып,
Рәхәт җил исеп китә.

Үләннәр борын төртәләр,
Бөреләр тунын сала.
Алмагачлар ак чәчәкле
Күлмәген киеп ала.

Кошлар бала чыгаралар,
Каз-үрдәкләр — бәбкәсен.
Бөтен табигать яңара —
Май айлары шәп тә соң!

*1965*

## ИЮНЬ-ИЮЛЬ

Июнь ае, июль ае —
Чәчәкле дә җиләкле.
Кояшы да бигрәк кайнар —
Салдыра ул күлмәкне.

Елгаларда йөзә-йөзә
Балык булып бетәбез.
Ярышларда чуртаннарны
Выжлап узып китәбез.

Июнь ае, июль ае
Көч бирә торган айлар.
Безне колаклардан тартып
Үстерә торган айлар.

*1965*

## АВГУСТ

Август ае баладай,
Гел яшь була күзләре.
Алсу алма күрсә генә
Балкып китә йөзләре.

*1965*

## СЕНТЯБРЬ

Ә сентябрь, сентябрь —
Бу айда эш йөз дә бер:
Бәрәңге дә аласы,
Мәктәпкә дә барасы,
Алмасын да җыясы,
Җыйгач, сайлап куясы.

Чүп-чарлар яндырасы,
Җир казып калдырасы...
Әй күп инде, эшләр күп,
Ник аны санап торам?!
Әни ничек өлгерә,
Кызганып карап торам.

*1965*

## ЙОРТ ҺӘМ ОЕК

Оек бәйли әнкәй, ә урамда
Зур бер йортка нигез казыйлар.
Машиналар белән җир актара
Егет-кызлар, олы абзыйлар.

Урамдагы йортка карый-карый,
Үз эченнән нидер сөйләнеп,
Оек бәйли әнкәй, тик нигәдер
Энәләре җитми көйләнеп.

Әллә нигә эше үрчеми күк,
Шуңа бәйли ашыга-ашыга.
Каян шулай төзелеш ачтылар соң
Нәкъ китереп безнең каршыга?

Атна үтте бер дә сизелмичә,
Тәмамлады әнкәй оегын.
Ә бу вакыт инде теге йортның
Кадаклыйлар иде кыегын.

*1965*

## МЕНӘ ШУЛАЙ ҮСӘ АЛАР

Олысына өч яшь тула,
Сигез ай — кечесенә.
Энесен карый башлаган,
Үскән шул инде менә.

Тирбәтә ул энекәшен
Утырып та, ятып та.
Бигрәк ярата аны
Еламаган вакытта.

Көйсезләнгән чакта гына
Сөйми бер дә энесен.
Үзе утырып елый башлый
Уздырып бөтенесен.

Менә шулай үсә алар
Абыйсы һәм энесе.
Әниләре чыгып китсә
«Концерт» куеп икесе.

*1965*

## АЙ

Түгәрәк күмәчтәй
Ай тулы, ай бөтен.
Каерып, телемләп
Кис тә ал бер читен.

Йә аны тураклап
Өеп куй табынга.
Табының ямьләнер,
Бизәлер тагын да.

Юк, болай ярамый
Кисәргә, турарга.
Ул бит күп тырышкан
Туп кебек туларга.

Ул инде болай да
Калыр бер сызыкка.
Йә тулы килеш тә
Капланыр болытка.

Ай тора үзгәреп:

Бер — ярты, бер — бөтен.
Тик менә ай кебек
Булмасын бәхетем.

*1965*

## МИН БИТ СИНЕҢ ИЛДАРЫҢ

Әткәй, киттең, ятим иттең,
Син оныттың мин барын.
Ташласаң да, кайтмасаң да,
Мин бит синең Илдарың.

Син киткәнгә, мин көткәнгә
Була хәзер ел ярым.
Син китсәң дә, ел үтсә дә
Сагына сине Илдарың.

Белми идем, хәзер белдем
Бу дөньяда моң барын.
Моңланучы, уйланучы
Булыр синең Илдарың.

Бардыр, бәлки, синең, әти,
Йөрәгеңә тиң парың.
Пар да булыр, яр да булыр,
Тик булмас бит Илдарың.

Син онытма, юл суытма,
Әйләнсәң дә Җир шарын.
Кайларда гына йөрсәң дә,
Сагындырыр Илдарың.

*1965*

## БАБАҢ КЕБЕК БУЛ, ДИЛӘР

Минем бабам бик яраткан
Зур кибәннәр куярга.
Кибән Ярул дип йөрткәннәр
Бабабызны шуңарга.

Очламый торып кибәнен
Җиргә һич төшмәгән ул.
Кулларында ут уйнатып,
Рухланып эшләгән ул.

Ашарына да биргәннәр
Сәнәккә элеп кенә.
Эшләгән бабай дәртләнеп,
Эш тәмен белеп кенә.

Үлгәндә дә үлгән ди ул
Башын куеп печәнгә.
Соңгы чыбыкны кадагач,
Әйткән: «Ярый үлсәм дә».

Картлар әле дә сөйлиләр,
Шәп иде Ярул, диләр.

Миңа да киңәш йөзеннән,
Бабаң кебек бул, диләр.

*1965*

## ЭНӘ

Үзем мин гади энә,
Буем бик тә кечкенә.
Хезмәтем тегү, ялгау,
Бик җиңел моны аңлау.
Хуҗам тегүче минем,
Мине гел йөртә түштә.
Тегешәм һәрчак кием —
Мин кирәк аңа эштә.
Хуҗамның бар бер кызы,
Бик нәни әле үзе —
Тик тормый үзе һич тә,
Кайчан карама эштә.
Курчакка күлмәк тегә,
Сырлап түшләрен чигә,
Аның белән мин бик дус,
Ул бит әйбәт, эшчән кыз.
Тагын бар бер уллары,
Һич тик тормый куллары.
Йә ертып кайта тезен,
Йә умыра изүен.
Ә беркөнне ул кайтты
Өздереп күлмәк җиңен.
Һәм мине эзләп тапты.
Уйлый: җиң тагу җиңел.
Әй маташты җеп саплап,
Мине бетте азаплап.
Әгәр килсә кулымнан,
Алыр идем яңаклап.
Кулына кадап алды,
Бармагыннан кан тамды.
Сындыра язды мине,
Бигрәк тә инде тиле.
Кара күлмәкнең җиңен
Ап-ак җеп белән текте.
Артык та, ким дә түгел,
Ул өч сәгать интекте.
Беләсезме нишләдем
Малай җиңен такканда?
Бармакларын тешләдем
Мине ялгыш тотканда.
Азапланды, тир түкте,
Шулай да үзе текте.
Бу булды аңа сабак,
Күлмәк ертмады кабат.
Үзем нәни булсам да
Һәркөн озын юл үтәм.
Бик арысам — хуҗамның
Түшенә кунып ял итәм.

*1965*

## ИКЕ КЫЗ ҺӘМ БЕР КӨЧЕК

Урманга китте беркөн
Ике кыз һәм бер көчек,
Алып кайтмакчы булып
Җиләк-җимешне ишеп.
Урман әйбәт, тын иде,
Яфракларда моң иде.
Җиләкләр һәр сабакта
Берәү түгел, ун иде.
Юллар бик уңган иде,
Күңелләр булган иде.
Куллардагы тубаллар
Мөлдерәп тулган иде.
Ләкин шулчак кинәттән
Нидер булды урманга.
Агачлар гөж иттеләр
Гел тик кенә торганда.
Каргалар карылдады,
Чәүкәләр чәрелдәде,
Яфраклар дерелдәде.
Көн бозылды, җил купты
Һәм кызларны куркытты.
Берсенең эшләпәсен
Алып җиргә ыргытты.
Җиңел салам эшләпә
Очып йөрде һавада,
Аргач кунды ботакка —
Ял кирәк бит аңа да.
Эшләпәле ботакка
Кунды шулчак бер карга.
Эшләпә күмәч булып
Тоелдымы аңарга, —
Читен килеп чукыды,
Ләкин тәмен тапмады.
Аннары ачу белән
Аны җиргә ташлады.
Тик эшләпә төшмәде
Бу кызларның каршына, —
Качып барган куянның
Капланды ул башына.
Чапты куян куркудан
Белми түрне-ишекне.
Эшләпәле баш белән
Сөзеп екты көчекне.
Көчек китте тәгәрәп,
Шыңшый да алмый калды.
Эшләпәне калдырып
Куян күздән югалды.
Эшләпә төшкәч җиргә
Шулай михнәтләр кичеп,
Кайтыр юлга чыктылар
Ике кыз һәм бер көчек.
Савытлар җиләк кенә,
Атлыйлар ипләп кенә.
Баштан үткән хәлләрне
Көчеккә сөйләп кенә.
Көчек кенә ачулы,
Эшләпәгә өрә ул.
Маңгаеның сызлавын

Шуннан гына күрә ул.

*1965*

## БӘП-БӘЛӘКӘЙ АПУШТАН

Ятимлек сине кемнәргә
Әнием дидермәгән.
Кемнәрнең утлы сүзләре
Җаныңны көйдермәгән дә
Шатлыгың сүндермәгән.

Еласаң да елагансың
Кешедән качып кына.
Яраларыңа сипкәнсең
Май түгел, балчык кына шул,
Ят күздән качып кына.

Бөек Тукай булганчы син
Бәп-бәләкәй Апуштан —
Кагылгансың, сугылгансың,
Өтелгәнсең сагыштан шул,
Тибелгәнсең язмыштан.

Үсә-үсә әкияттәге
Батырдай олы булдың.
Җаннан җанга күчә-күчә
Халыкның моңы булдың син,
Халыкның улы булдың.

*1966*

## ТОТЫЛДЫ

Әнкәсе авырып китте
Мансурның берчак.
Дарулар китерде Мансур
Аңарга учлап.

— Шушыларны эч тә, әнкәй,
Тиз генә тазар.
Тагын дарулар бирермен
Җитмәсә алар.

— Каян алдың син боларны?
— Теге вакытта
Мин аларны эчми генә
Җыйдым савытка...

*1966*

## ЧАҢГЫ ШУГАНДА

Чаңгыда шуганда
Колаклар кызара.
Ә тотып карасаң,
Әйтерсең боз алар.

Борыннар кызара,
Керфекләр бәсләнә.
Салкыннан, рәхәттән
Күзләрең яшьләнә.

Чаңгыда очасың,
Очасың — шумыйсың.
Тауларга менәсең,
Юлларга сыймыйсың.

Бөтен җир ак мамык,
Шыгырдый басканда.
Бер ятып ауныйсың,
Хисләрең ташканда.

Тәннәрең языла,
Иркенлек — ягында.
Дәва син, салкын кыш,
Арыган чагында.

Синдә бар пакьлек тә,
Синдә бар аклык та.
Синдәге гүзәллек
Бар безнең халыкта.

*1996*

## ЧӘЧӘКЛӘР ЯРАТУЧЫ

Гөлләр утырта Зәйтүнә,
Яз килеп җитте исә.
Гөлләр бөреләрен ача,
Зәйтүнә кулы тисә.
Розасы бар, канәфере,
Георгины — барчасы.
Салават күпере төсле
Аның чәчәк бакчасы.
Әле ул бик яшь булса да,
Даны таралган ерак.
Гөл үстерүнең серләрен
Язалар аннан сорап.
Ә Зәйтүнә хатлар белән
Орлыклар да җибәрә.
— Чәчәккә күмелсен, — ди ул, —
Бездә бөтен җирләр дә.

*1966*

## «ҖЕНЛЕ» МЕНДӘР

Ялгызы гына
Калгачтын өйдә,
Бер кызык хәлгә
Очрый Халидә.
Уйламый-нитми
Утырган чакта,

Мендәр җанлана
Кинәт почмакта.
Кузгалып куя,
Пыш-пыш иттерә.
Әйтерсең кемдер
Аңа җан өрә.
Халидә тәмам
Куркуга төшә.
Ә мендәр һаман
Зурая, үсә.
Күзләрен йомып,
Бар көчен җыйнап,
Ташлый Халидә
Мендәрне кыйнап.
Караса барып
Халидә-батыр,
Мендәр астында
Бер күәс камыр.

*1966*

## СУЫК ТӨСЕ

Мин беләмен, кышның төсе
Мамык кебек ак була.
Минем иң яраткан чаклар
Кышкы салкын чак була.

Суык кызыл төстә икән,
Анысын яңа төшендем.
Салкынга чыккач битләре
Кызара бар кешенең.

Салкын үзе күренми дә,
Үзе бик нык чеметә.
Шул чеметкән чакта, ахры,
Кызылын сөртеп китә.

*1966*

## ЯШИ АЛМЫЙМ ШУНСЫЗ

Озак йөрсәм ялыктыра башлый
Болыннар да, матур урман да.
Сандугачлар хәтта туйдыра бит
Бертуктаусыз сайрап торганда.

Йолдызларның нуры кими кебек,
Озак йөрсәм якты төннәрдә.
Һәрвакытта янда торса әгәр
Ямьсезләнә кебек гөлләр дә.

Тиз туйсам да кайбер нәрсәләрдән,
Бер нәрсәгә артык комсыз мин —
Кешеләрдән һич тә туя алмыйм,
Яши алмыйм менә шунсыз мин.

*1966*

## БУРАН БЕЛӘН ДУСЛАШТЫК

Буран белән дуслаштык без,
Дуслык башланды күптән:
Аның белән икәүләшеп
Тау ясыйбыз без көрттән.

Ул юллардан кар китерә,
Мин шуып таптап торам.
Әллә белеп, әллә белми
Миңа эшләшә буран.

Тавым инде бик зур хәзер,
Рәхмәт инде җилләргә.
Исәп бар әле шул таудан
Йолдызларга менәргә.

*1966*

## БЕРАЗ КӨТӘРГӘ МИКӘН?

Күктә йолдызлар нигәдер
Атыла сирәк кенә.
Төшерсәң иде аларны
Кар кебек көрәп кенә.
Йолдызлар бик күп булгачтын
Санарга бик җайсызлар.
Кайчан мин санарлык кына
Калыр икән йолдызлар?
Күктә йолдыз әзәйгәнен
Озак көтәргә микән?
Әллә кулга көрәк алып
Менеп китәргә микән?

*1966*

## БЕЗНЕҢ БАБАЙ

Кышкы салкын бер көндә,
Әйтми–нитми беркемгә,
Авылдан, бик ерактан,
Бабай килде кунакка.
Керфекләре бәс кенә,
Күзләре гел яшь кенә.
Боз сакаллы, кар башлы —
Кыш бабайга охшашлы.
Узып тормый түргә дә,
Тотынды ул тиргәргә:
— Җәһәннәмдә торасыз,
Килеп җитәр хәл юк, — ди. —
Авылда ни җитмәгән,
Монда бит бер ямь юк, — ди. —
Фатирыгыз зур–зурын,
Ул ягы, — ди, — бик яхшы.
Сөякләрне язарга
Ләкин юк, — ди, — мич башы.
Шундый безнең бабабыз,
Бераз сәер холыклы.

Картая барган саен
Ныграк сөйми суыкны.
Әтине дә тирги ул:
— Мич яса, — ди, — почмакка.
Минем сүзне тотмасаң,
Килмәм дә, — ди, — кунакка.
Шулай диеп китсә дә,
Үзе килә ел саен.
Былтыр әйткән сүзләрен
Онытадыр, мөгаен.

*1967*

## УЙЛАП ТАБУЧЫ

Газеталарга язмыйлар
Әле аның турында,
Рәсемнәрен дә күрмәссең
Иң почетлы урында.
Тик килер шундый вакыт,
Үзен танытыр Вахит.
Хәзердән үк балта–чүкеч
Бии аның кулында.
«Кылны кырыкка ярыр бу», —
Диләр аның турында.
Ярыр, ярыр, ышанам,
Булдырырга охшаган.
Йомычканы кораб итәр,
Калай тапса — самолет.
Ул ясаган әйберләргә
Кызыкмаган малай юк.
Сүтә, җыя, төзәтә,
Бар нәрсәне үзгәртә.
Самавыр торбасыннан да
Паровоз ясап куяр.
Ни тотса — шуны булдырыр,
Нишләсә — шуны управ.
Эзләнә ул, уйлана,
Кулларына эш таба.
Газеталарга язмыйлар
Әле аның турында,
Рәсемнәрен дә элмиләр
Иң почетлы урынга.
Килер бер көн, бар кешеләр
Рәхмәт әйтерләр аңа.
Дөньяда һәр ачыш бит
Эзләнүдән башлана.

*1967*

## АЮ ТУН

Абыем Себердә яши,
Бик шәп аның һөнәре.
Тайгаларда аю аулап
Үтә икән көннәре.

Үзе тоткан бер аюның
Тиресеннән тун тегеп
Миңа да җибәргән әле —

Йөрмә, дигән, интегеп.

Туным шундый җылы минем,
Һич өшетеп карамый.
Өшетеп карамаса да,
Кияргә шул ярамый.

Аны киеп чыктым исә,
Бөтен этләр өрәләр.
Әллә инде мине чынлап
Аю диеп беләләр?!

*1967*

## МӨНИП

Күршеләрнең алмасына
Кызыгып йөри Мөнип:
— Йолдызлар элгән диярсең,
Һәммәсе тора көлеп.
Ник аларның алмалары
Бар да кызыл, ал икән?!
Берсен менеп алсаң инде,
Эче тулы бал микән?
Үрмәли Мөнип агачка,
Чалбарын да жәлләми.
Ертылса ертылыр инде,
Бер алмасы әллә ни!

Иң биектә, иң зурысы
Бигрәк матур күренә.
Башкасын карамый Мөнип,
Шунысына үрелә.
Шул вакытны алмагачы
Кинәт китә чайкалып,
Һавадагы болытлар да
Йөри башлый айкалып.
Кулдагы алмасы белән
Оча Мөнип түбәнгә.
Ярый ботак эләктерә,
Инде беттем дигәндә.
— Күрче, нинди зур алма! — дип
Чыкса хуҗа, шул чакта
Алмадай кызарган Мөнип
Эленеп тора ботакта.
*1967*

## НУРЛЫБАЯН

Күрше малай — Нурлыбаян
Бер эт тапкан әллә каян.
Сөйләшәләр көн дә, төн дә
Икесе генә белгән телдә.
— Күтәр минем сумкамны, — дип
Әйтә икән малай уйнап.
Тешләп эте зур сумканы

Алып китә урам буйлап.
Онытылып калса тышта
Берәр төрле кием-салым,
Эте хәзер алып керә,
Исен генә сизсен аның.
Мактанып та җибәргәли
Нурлыбаян кайчакларда:
— Үсү белән китәм, — ди ул, —
Этне алып ил сакларга.

*1967*

## ГЕОГРАФИЯ ДӘРЕСЕНДӘ

Карта янына баскан да
Аптыраган Ләмига.
Кырымны таба алмый ул,
Батканмы әллә суга?!

Өйдә дәрес карамасаң,
Килә икән кыенга:
Кырым диеп Ләмигабыз
Барып чыга Курилга.

Укытучы әйтә аңа:
— Кырым бит, — ди, — көньякта.
Арттан кычкыра бер малай:
— Җир әйләнә бит, апа!

*1967*

## РӘХӘТ ТӘ СОҢ!

Болыннарга чыгасың,
Елгаларга чумасың,
Тирбәләсең талларда,
Йөзәсең шәп салларда,
Походларга барасың,
Яңа чишмә табасың,
Шаярасың, уйныйсың,
Бетмәслек көч җыйныйсың —
Рәхәт тә соң җәй көне!

Ләкин китсә артыкка,
Ял итү дә арыта.
Сагындыра апалар,
Сагындыра парталар.
Сагындыра китаплар —
Укып йөрегән чаклар.

Килеп җитә сентябрь,
Мәктәпләрдә шау да гөр.
Һәрбер укучы өйдән
Сораулар төяп килгән:
— Болытлар ник биектә?
— Җир әйләнә нилектән?
— Кояш янып бетмәсме?
— Диңгез–күлләр кипмәсме?
— Җилнең оясы кайда?
Аңардан бармы файда?

— Чебен–черки, бакалар
Ник бетмиләр, арталар?
Һәммәсен аңлаталар
Укытучы апалар.
Шундый кызык, шундый шәп,
Ярый әле бар мәктәп!
Укып арыгач–талгач,
Бик күп белемнәр алгач,
Яз килеп җитә җырлап,
Бар дөньяны матурлап.
Елгаларда су арта,
Агач бөре яңарта.
Кайталар киткән кошлар,
Яшәү кызык та, дуслар!

*1967*

## ДАМИР

Дамир әйбәт көрәшче,
Беләкләре бик юан,
Әйтерсең туганда ук
Көрәшче булып туган.

Һәркемне дә ега ул,
Гел-гел өскә чыга ул.
Спортны бик сөя ул —
Герне дә шәп чөя ул.

Яратса да спортны,
Укуны бик яратмый.
Тактага дәшсә апа,
«Беттем, эшләр харап», — ди.

Жәлләп тә куям үзен,
Мондый хәлдә күргәндә.
Мәсьәлә авыр шул ул
Ике потлы гердән дә.

*1967*

## СӨЕНЧЕ

Мәктәбемә йөгерим дә
Алыйм әле сөенче:
Авылыбызга яз килүен
Мин күрдем иң беренче.

Бер тамчы биек түбәдән
Минем башка сикерде.
Сикерде дә миңа гына
Яз хәбәрен китерде.

*1967*

## БЕЗНЕҢ АВЫЛ

Безнең авыл шундый җирдә —
Кышын буран оясы.
Йөрер өчен туры сукмак
Җилләргә Ык елгасы.
Тирә–юньдә урманы юк,
Үсә әрәмә генә.
Су буйлары кайнар комлык,
Ят та тәгәрә генә.
Очраган бер таш астыннан
Бәреп чыкмый чишмәләр.
Бездә суны коелардан
Бик тирәннән эчәләр.
Ә шулай да җитми инде
Үзебезнең авылга.
Күкрәк киереп йөримен мин
Авылыбызда чагында.
Матуррак өрә бездә
Алабайлар да хәтта.
Ышанмасагыз, үзегез
Килегез безнең якка.

*1967*

## АВЫЛДА ПЕЧӘН ӨСТЕ

Авылда печән өсте,
Авыл иртә уянган.
Гөлләр алсу иренен
Таң нурына буяган.

Көтүче таңны куа
Чыбыркысын шартлатып.
Елмаеп кояш туа
Кешеләргә шаккатып.

Авылда печән өсте,
Ашкыну һәр йөрәктә.
Кушылып чалгы чыңына
Кошлар сайрый куакта.

*1967*

## КЕМ БУЛДЫ ИКӘН ЯНЫМДА

Тып-тын гына тавыш-тынсыз,
Аяк очына басып —
Төнге җилме керде янга
Белә алмадым ачык.

Йомшак итеп, рәхәт итеп
Чәчләремә кагылды.
Нидер әйтте дә шикелле,
Тавышы иде ягымлы.

Мин күзем ачып карауга,
Беркем юк иде инде.
Кем булды икән янымда,
Әниме, төнге җилме?

*1967*

## ЫНДЫР

Ындырда бодай көшеле,
Ындырда күмәч тавы,
Ындырда яшьләр авазы
Һәм машиналар шавы.
Басудан юллар сузылган
Ындырга, көшелләргә.
Ындырдан юллар сузылган
Йортларга, кешеләргә.
Бер кеше дә читләп үтми
Шушы күмәч ындырын;
Ындыр — басулар йөрәге,
Юллар кушылган урын.

*1967*

## МИЧЧЕ КАРТ

Бар безнең авылда мичче карт,
Яшен ул үзе дә оныткан.
Аның зур, сөялле куллары
Никадәрле өйләрне җылыткан.
Киштәгә китаплар тезгәндәй
Матурлап тезә ул кирпечен.
Һәйкәлгә караган шикелле
Сокланып карыйсың һәр мичен.
Тузмыйлар бу мичләр, тузмыйлар,
Торалар гел җылы өләшеп.
Карт мичче останың эшенә
Кем генә карамас көнләшеп?

*1967*

## СУЫКБОРЫН ҺӘМ СУЫККОЛАК

### I

Кышның салкын көнендә,
Карурманның түрендә
Ике куян күрешкән
Һәм һәркайсы суыктан,
Рәхәт, җылы өй юктан
Зарланырга керешкән.
Берсе әйткән: У-у-уу!
Нинди зәһәр кыш соң бу.
Туңып бетте колаклар,
Күрәсеңме, ап-аклар.
Карлар белән усаң да,
Яфрак каплап куйсаң да,
Җылынмый бит колагым,
Нишләргә соң, туганым?
Тегесе: У-у-уу,
Бигрәк зәһәр суык бу.
Минем туңды борыным,

Инде ничек торырмын?
Ис тә рәтләп сизмимен,
Юлны озак эзлимен.
Бу дөньяның, туганым,
Һич җылысы юк аның...
Ике куян-бичара
Зарланышкач үзара,
Киләләр бер карарга:
— Йә бер буш аю өнен,
Йә җылы учак көлен
Кирәк, — диләр, — табарга.
Эзли торгач табалар,
Бик шәп учак ягалар.
Тик учакны җил өреп
Китә беркөн сүндереп.
Учак тәмам сүнгәчтен,
Көлен буран күмгәчтен,
Гаҗәп салкын беркөнне
Таба алар бер өнне.
Тик берсе дә кермиләр,
Нигә дисәң, шүрлиләр,
Берсе уа колагын,
Һич күзәтми як-ягын.
Берсе тоткан борынын,
Хет койрыгын бор моның,
Калмас куркып, аптырап —
Үлүең дә яхшырак.

**II**

Бара торгач куяннар
Аучыга тап булганнар.
Аучы килә дөп-дөп, ди.
Иңсәсендә мылтык, ди.
Аркасында биштәр, ди.
Атар микән, нишләр бу?
Йөгереп чыга куяннар,
Алар шундый туңганнар.
Гел яшь кенә күзләре,
Көчкә чыга сүзләре.
— Аучы, аучы, — ди алар, —
Безне алчы, — ди алар. —
Түзәр әмәл калмады,
Бик суынды дөньялар.
Ни кушсаң да үтәрбез,
Эшләп гомер итәрбез...
Салып куя бу аучы
Куяннарны биштәргә.
Суярга бик кызганыч,
Болар белән нишләргә?
Туендыргач, җылыткач
Җибәрсенме иреккә?
Илтә аучы аларны
Шәһәрдәге циркка.
Куяннар бик шат икән,
Эшләре бик шәп икән.
Тамаклары сыйлы, ди,
Дөньялары көйле, ди.
Башларында кәләпүш,
Өсләрендә чапан, ди.

Әйтәсе юк, куяннар
Эшнең шәбен тапкан, ди.
Тик шулай да аларның
Тыныч түгел, ди, җаны:
Сагыналар, ди, куяннар
Әле һаман урманны.

*1967*

## КАЛМАГЫЗ СОҢГА

Бәлки, мине әнием эзлидер,
Бәлки, мине әтием эзлидер.
Әтием! — Мин монда,
Әнием! — Мин монда —
Каты тимер караватымда.
Ишек бикле булса — ачыгыз,
Тәрәз бикле булса — шакыгыз.
Кертмәсәләр качып керегез,
Ләкин мине барыбер күрегез.
Тәрәз каршысында өянке,
Өянкедә бер кош оясы.
Көне буе сайраша алар,
Бигрәк матур кошлар дөньясы.
Әнкә кошлар анда җим ташый,
Бала кошлар тәмләп җим ашый.
Оялары йомшак, мамыклы,
Тавышлары шундый шатлыклы.
Ишетәсезме, әтием, мин монда,
Ишетәсезме, әнием, мин монда.
Мин көтәмен, әле көтәмен,
Тик килегез, калмагыз соңга.
Килмәсәгез китеп барырмын
Кошлар белән ерак илләргә,
Җылы эзләп очып йөрермен,
Керә-керә өйдән өйләргә.

*1968*

## УКЫТУЧЫ БУЛДЫМ

Укытучы булдым мин,
Укытам энемне.
Укытучы булуы
Шундый да күңелле.

Мәктәптә чагында
Ни белсәм ападан.
Кайткачтын шуларны
Сөйлимен яңадан.

Тик энем кайвакыт
Аңламый йөдәтә.
Җап-җайлы нәрсәне
Ике-өч кат сөйләтә.

«А» ны «А» дию
Әйтерсең кыен эш.
Шуны бит әйталмый,
Утыра мыш та мыш.

Җитсә ул безнең күк
«С» ларга, «У» ларга.
Нишләр соң шулвакыт,
Тотынырмы еларга?

*1968*

## ШАЯН МАЛАЙ

Тапкыр сүзне
Бик ярата
Искәндәр.
Мәкаль–әйтем
Хәзер анда
Биш дәфтәр.
Ишетсә дә
Табышмагын,
Җор сүзен,
Шатлыгыннан
Чылт–чылт йомып
Бер күзен,
Хәзер аны
Дәфтәренә
«Төртер» ул.
Кесә саен
Бер блокнот
Йөртер ул.
Тотып алыр,
Йотып алыр
Һәр сүзне.
Шуңар да ул
Шаян телле,
Шат йөзле.
Көлдерсә дә
Кызык-кызык
Сүз белән,
Һичбер вакыт
Үзе көлмәс
Кешедән.

*1968*

## ИЛДУС

Велосипед алып бирде
Әткәләре Илдуска.
— Өйрән, — диде, — катнашырсың
Сабантуйда ярышка.
Илдус урамга ашыкты,
Атланып тимер атка.
Шунда аны көтмәгәндә
Сукты да екты капка.
Очып барып төште дә ул,
Очып менеп атланды.
Егылу билгесе булып,
Маңгаенда эз калды.
Урамнарга чыкса Илдус,
Урамнар бик тар икән.
Адым саен йә бер капка,
Йә багана бар икән.

Коймаларның катылыгын
Сынагач шактый гына,
Чирәмлеккә юл тотты ул,
Йөгерә–атлый гына.
Монда урын шундый иркен,
Теләсә күпме егыл.
Мамыктай йомшак чирәмдә
Маңгай күбәчәк түгел.
Тагын менеп атланды ул
Тәгәрмәчле бәлагә.
Күп китмәде, «абынды» шул
Бер тышаулы кәҗәгә.
Кәҗә, тышаулы булса да,
Бик хәтәр хайван икән,
Мөгезен кашырга диеп,
Җай көткән, хәйлә көткән.
Күзләрен уттай итеп,
Мөгезен уктай итеп,
Куып китте Илдусны,
Сөзеп екты Илдусны.
Кап–караңгы булып китте
Илдусның күз аллары;
Велосипед дип, кәҗәгә
Атланды ул аннары.
Велосипедтан да ныграк
Дулап китте кәҗәкәй.
Инде хәзер исән калу
Чамалары бәләкәй.
Бара торгач, кәҗәкәйнең
Өзелде тышаулары.
Гомергә онытмас Илдус
Бу басу урауларны.
Мөгезләрне руль иттереп,
Илдус бик нык тотынды.
Дулый торгач, кәҗә мескен
Үзе арып егылды.
Әгәр сызлаудан туктаса
Маңгае һәм терсәге,
Сабантуйда ярышларда
Катнашырга исәбе.

*1968*

## МӘКТӘПТӘН КАЙТЫП КИЛӘМ

Мәктәптән кайтып киләм,
Сумкам тулы бишлеләр.
Мине алга сөйриләр
Бишлеләр бик көчлеләр.
«Саумысыз» дим һәркемгә.
Их, дөньялар иркен дә!
Әллә кая ашкынам,
Урамнар кояш кына.
Сумкам арытмый кулны,
Мәче дә кисми юлны.
Этләр дә чыкмый өреп,
Минем кайтканны күреп.
Кайтып барам ялгызым,

Ерык минем авызым.
Чыдап булмый, чын менә,
Бишлеләрем көлдерә.

*1968*

## ГАДӘТ

Бер эшкә тотынсам,
Җиде кат тирлим мин,
Белмичә, үземә
Тынгылык бирмим мин.

Маңгайдан шыбырдап
Әйдә, дим, тир аксын,
Тик эшем эш булсын,
Кешеләр яратсын.

Соңыннан кемнәрдер
Тиргәрлек булмасын;
Кызарып, оялып
Тирләрлек булмасын.

*1968*

## МИНЕМ ӘНИ

Минем әни авылда бер,
Ә авыл хәтәр олы.
Шофер Хәҗәрне белсәгез,
Мин нәкъ шул Хәҗәр улы.

Әни көрәшче Галләмнең
Унынчы кызы булыр.
Түшендә урак-чүкечле
Алтын йолдызы булыр.

Күпләр мактыйлар әнине,
Күпләр аны ярата.
Тик кызганган булып сөйли
Күршебез Гөлми апа.

— Әниең гел авыр эштә,
Бик арыйдыр, мескен, — ди. —
Шуның аркасында син дә
Иркә күрми үстең, — ди.

Гөлми апаның сүзенә
Бик исем китеп тормый.
Үзе эш белмәгәнгә ул
Безнең әнине хурлый.

Яратмый дип уйламагыз,
Мине әни ярата.
Кайчан гына сорасам да
Руль тоттырып карата.

Бергә юлга да чыгабыз, —
Шоферның хәтәр юлы. —

Юллар серен өйрәнәмен,
Мин — шофер Хәҗәр улы!

*1968*

## АВЫЛЫБЫЗДА ТУЙ БҮГЕН

Берәү дә өйләнмәсә дә,
Авылыбызда туй бүген.
Кемгә кермә — коймак пешкән,
Кемгә кермә — сый бүген.

Без дә алай буш йөрмибез,
Уйламагыз юләр дип.
Кесә тулы конфет безнең,
Чабу тулы прәннек.

Узышабыз, чабышабыз,
Булмаса да атыбыз.
Атлар безгә нигә кирәк,
Безнең колын чагыбыз.

Таякларны ат иттереп
Шәп тә соң урам урау!
Авызыбыз гармун безнең,
Йөрәгебез — кыңгырау.

*1968*

## ИЛШАТ ҺӘМ ҖИЛ

Илшат һәр көн арганчы
Чана белән кар ташый.
Япа-ялан урында,
Янәсе, шәп тау ясый.

Ул йоклаган чагында
Карын урлыйлар җилләр.
Саклап та торыр иде,
Озын шул кышкы төннәр.

Әйтә аңа әткәсе:
— Аптырама, улым, — ди. —
Койма белән бүләрбез
Явыз җилнең юлын, — ди.

Бик тиз койма ясыйлар,
Чыбыгын да ташыйлар.
Җилнең юлын биклиләр,
Тынычланып йоклыйлар.

Икенче көн чыксалар,
Җил күпме эш майтарган:
Ун көн ташыган карын
Уны белән кайтарган.

*1968*

## ТУГАН ЯК ТАБИГАТЕ

Кайтып киләм урман сукмагыннан,
Шундый рәхәт, җиңел атларга.
Белмим, нинди сихри магнит шулай
Тарта икән туган якларга.

Битләремнән, чәчләремнән сыпырып,
Дәү юкәләр мине иркәли.
Бөтенесен шулай оныттырып,
Баштан сыйпый иде тик әни.

Әнкәй кочагыдай рәхәт икән
Туган якның бөтен җире дә.
Балачагым кабатлана кебек
Һәр яфракта, һәрбер бөредә.

*1968*

## ГОРУР КАЕНБИКӘ

Аланда япа-ялгызы
Үскән бер Каенбикә.
Ботагы — аккош муены,
Яфрагы — яшел көлтә.

Ялгыз гына үскәнгәме,
Ул иркә, назлы булган.
Аланның бөтен кошлары
Тик аңа гына кунган.

Кояш аны һәр иртәдә
Нур белән коендырган.
Җир-ана үз күкрәгеннән
Су биргән, туендырган.

Җилләр чәчен тарап торган,
Яңгырлар битен юган.
Җем-җем иткән чык сулары
Аңарга алка булган.

Каенбикә горурланып
Әйтә икән җилләргә:
«Миннән гүзәл һичкем юк, дип,
Таратыгыз илләргә.

Берүземә бер кояш бит,
Берүземә бер алан.
Табигатьтән матурлыкны
Теләгән кадәр алам».

...Язын агач утыртканнар
Бу аланга кешеләр.
Агачларның бөтенесе
Каенбикә төслеләр.

Бар да гүзәл, бар да сылу,
Аерма юк аларда.
Яфракларда чыклар уйный,
Кояш чыккан чакларда.

Барсына бер кояш җиткән,

Һәммәсенә — бер алан.
Горур Каенбикә шунда
Тәмам югалып калган.

Мактанырга теләсә дә,
Юк бертөрле чара, ди.
Каенбикә бу гадәтен
Инде онытып бара, ди.

*1968*

## ТУКАЙ АША

Юктыр диеп йөри идем
Латвиядә танышларым;
Урамына керү белән,
Ак каеннар каршылады.

Юкәләре, чыршылары,
Наратлары бар да таныш.
Теләсәң, һәр агач белән
Рәхәтләнеп фикер алыш.

Кибетләргә килеп керсәң,
Карап тора Җәлил, Тукай.
Китап сөйгән һәрбер кеше
Алар каршысында туктый.

Монда дуслар булмас диеп
Ялгышканмын, ялгышканмын.
Белдем хәзер халкыбызның
Тукай аша танышканын.

*1968*

## КЫЯМ ҺӘМ КУЯН

Куян ашата Кыям,
Кәбестә төеп тора.
Үткен балта улакта
Туктаусыз биеп тора.

Куян шундый ачыккан,
Башын алмый савыттан.
Кусаң да китми һич тә
Тәмле икән кәбестә.

Бик тиз арада куян
Ялт иттерә улагын.
Ләкин ашаган чакта
Югалта бер колагын.

Аптырашта Кыям да,
Аптырашта куян да.
Әй карыйлар улакны
Тик тапмыйлар колакны.

Эшкә мавыккан Кыям

Кисеп төшергән аны.
Артык ачыккан куян
Ашап бетергән аны.

*1968*

## АВЫЛДАН КИЛӘМ

Авылдан киләм —
Изүләр ачык;
Күкрәктә шаулый
Игеннәр шашып.

Таң яктысы бар
Минем күземдә.
Көмеш чык суы
Уйный эземдә.

Дала җилләре
Исә кесәмдә.
Язмышым бара
Ике иңсәмдә.

Кешегә әйтер
Сүзләрем артты.
Шул газиз сүзләр
Юлларга тартты.

Юлда һәркемгә
Елмаям, көләм;
Каршы алыгыз —
Авылдан киләм.

*1968*

## БАУЛЫ ЯГЫМ

Туган ягым — Баулы ягым,
Баулы ягым — таулы ягым.
Бер тавыңда кояш булса,
Бер тавыңда айлы ягым.

Туган ягым — Баулы ягым,
Елгалы һәм күлле ягым.
Урманнарың җиләкле һәм
Болыннарың гөлле ягым.

Туган ягым — Баулы ягым,
Шәфәкъле һәм таңлы ягым.
Ташларың да шундый йомшак,
Һаваларың баллы ягым.

Туган ягым — Баулы ягым,
Шанлы ягым, данлы ягым.
Тауларыңнан биеккәрәк
Күтәрелде синең даның.

Туган ягым — Баулы ягым,

Җырлы ягым, моңлы ягым.
Күзләрең дә, кышларың да
Җаннарыма җылы ягым.

*1968*

## ИСКӘНДӘРНЕҢ КИҢӘШЕ

Яңа пальто сатып алды
Искәндәрнең бабасы.
Эчләре атлас кына,
Каракүлдән якасы.

Бабай әйтә:
— Бу пальтоны
Бик яратып алдым, — ди. —
Тегелеше дә килешле,
Мамыгы да калын, — ди. —

Тик шунысы ошап җитми,
Бераз зуррак икән, — ди. —
Сатыр идем, мондый шәбен
Табып булмас бүтән, — ди.

Искәндәр тыңлап тора да,
Әйтә үзенең киңәшен:
— Сатма, бабай, ник сатасың,
Үскәчерәк киярсең.

*1969*

## ХАЛИКЪ, БАЛЫК ҺӘМ ПЕСИ

Кармакка барып Халикъ
Алып кайтты бер балык.
Салды сулы табакка,
Су килеште чабакка —
Кинәт кенә терелде,
Уйнады, бөтерелде.
Халикъ пычак кайрады,
Зур табаны майлады.
Учакларын кабызды —
Бөтенесен җайлады.
Аннан тазартыр өчен
Тотып алды чабакны,
Усал чабак көтмәстән
Ут иттерде яңакны.
Тыпырчынды, дулады,
Чабак һич тик тормады.
Яшь чыкса да күзеннән,
Кысып тотып тез белән,
Тазартты аны Халикъ.
Табага керде балык.
Анда да тик ятмады —
Табаны ошатмады,
Төште–китте сикереп.
Мәче килде йөгереп,
Үрелде ул чабакка,
Ул да алды яңакка.

Үз хәлен үзе аңлап,
Качты мәче мыраулап.
Горур мәче чын–чынлап
Үпкәләде бу эшкә,
Почмагыннан чыкмады
Хәтта балык пешкәч тә.

*1969*

## ЦИРК КИЛГӘЧ

Шәһәрдән, бик ерактан,
Цирк килгән клубка.
Рәсеменә караганда,
Охшаган бик кызыкка.
Йөгереп килә Мөнип тә,
Акча суза билетка.
— Урыннар бетте, — диеп,
Кассир карый бер читкә.
Аптырап калмый Мөнип,
Астан куя да көлеп,
Йөгерә өйләренә —
Якын ич, менә генә.
Күтәрә дә урындык
Тагын китә клубка.
— Апа, мин утырам, — ди, —
Үземнең урындыкка.

*1969*

## БАЛЛЫ СУ

Кабартма салдым да
Чәчәкле чиләккә,
Бик эссе бер көнне
Киттем мин җиләккә.

Көн буе йөредем,
Күп болын таптадым.
Никадәр йөрсәм дә,
Җиләкләр тапмадым.

Алҗыдым, сусадым,
Калмады бер көч тә.
Ярый ла шул вакыт
Очрады бер чишмә.

Юындым, су эчтем,
Тутырдым чиләккә.
Суы гел бал гына,
Кирәкми җиләк тә.

Бу баллы суны мин
Өйгә дә апкайттым.
Кайткачтын әбекәй
Аннан чәй кайнатты.

— Чынлап та бу суда
Бар җиләк тәме, — дим,

Яратып эчтеләр
Әбиләр чәйне бик.

*1970*

## КҮПЕР

Бар икән, дуслар,
Шундый бер күпер:
Кылдан да нечкә,
Кылычтан үткер.

Гөнаһың булса,
Кермә үзенә —
Кылы чыдамый,
Шартлап өзелә.

Хәйлә белән дә,
Юк, булмый үтеп.
Аста упкыннар
Торалар көтеп.

Бу серле күпер —
Ана йөрәге.
Тик сафлык кына
Аның терәге.

Керле җан белән
Керсәң аңарга —
Ул күпер бик тиз
Мөмкин аварга.

*1971*

## КЕМ ГАЕПЛЕ

Ачуланып, пыр тузынып
Кайтты Булат өенә.
Күңелендә дулады аның
Җил–давыллы өермә.

Сумкасын атып бәрде ул,
Чишенде өзеп–йолкып,
Аяк астындагы мәче
Качты аңардан куркып.

Әнкәсенә кычкырды ул,
Өйгә керә–керешкә:
— Синең аркаңда бүген мин
Берле алдым дәрестә.

— Ничек алай? — дип сорады
Әнкәсе бик аптырап.
— Моннан соң минем өй эшен
Эшләп куй син яхшырак.

*1971*

## ӘТИСЕНӘ ОХШАП

Илшатның әтисе
Колхозда хисапчы.
Процент санарга
Күнеккән шулчаклы.

Ни генә әйтсә дә
Проценттан башлана:
— Фәләнчә ягулык...
— Фәләнчә ашлама...

Илшат та өйрәнә
Әтисе һөнәрен.
Процентка сала гел
Эшләгән эшләрен:

— Йөз процент ашадым,
Йөз процент йокладым.
Ун процент укыдым,
Чырай да сытмадым.

Йөз илле процентка
Шаярдым, уйнадым.
Ә үзем бер процент
Ару да тоймадым...

Мәктәптә алса ул
Беркөнне ике биш,
Ике йөз процент, ди,
Бүгенге өлгереш.

*1971*

## МОЛОДЕЦ МИНЕМ ӘБИ

Бөтен эш кулыннан килә,
Әй уңган минем әби!
Мин дигәндә — ул идәндә,
Көчен һич тә жәлләми.

Алъяпкычларым үтүкли,
Көн дә чәчләрем үрә.
Якаларым гел ак минем
Әби юганга күрә.

Китап–дәфтәрләремне дә
Гел карап кына тора,
Ертылган битләре булса
Тота да ябыштыра.

Күңелләре күтәрелә
Бер ертыкны ямаса.
Минем өчен укырга да
Барыр иде... яраса.

*1972*

## РӘХМӘТ СИҢА, ЗАМАНА

Малай чагым — шук чагым,
Сикереп торган туп чагым:
Әле читкә тибелдем,
Әле өскә чөелдем,
Әле кундым читәнгә,
Әле төштем түтәлгә,
Әле йөздем дулкында,
Әле чумдым упкынга.
Шуңа хәзер куанам:
Син сабый дип башларымнан
Сыйпамады заманам.

Егет чагым — төп чагым,
Имән кебек нык чагым:
Яшен булды йөрәктә,
Гайрәт булды беләктә.
Иген иксәм, уңдырдым,
Печән чапсам, булдырдым,
Бар дисәләр, йөгердем,
Һәммәсенә өлгердем.
Шуңар хәзер куанам:
Син яшь, диеп, жәлләмичә,
Эш өйрәтте заманам.

*1972*

## НИГӘ КЫЗЫК ИЛҺАМГА?

Әй кызык та Илһамга,
Көлә гел чырык-чырык:
Иртән дә авыз ерык,
Кичтән дә авыз ерык.

Ярыктан да көлә ул,
Сарыктан да көлә ул.
Маэмай да кызык аңа,
Бахбай да кызык аңа.

Әйтә ул эткәсенә,
Әйтә ул әнкәсенә:
— Сез дә кызык күрәсез,
Ничек көлми түзәсез?

Көлмәс иде Илһам да,
Бар җирдә кызык күрә;
Тулып ташкан бәхете
Көлмәс җирдән көлдерә.

*1972*

## ӨЙ АРТЫНДА ШОМЫРТЫМ

Өй артында шомыртым,
Чыгып ашыйм шыпыртын.
Тәлгәшләре кара чук,
Өзеп алмый чара юк.
Үткәндә дә кабамын,

Сүткәндә дә кабамын:
Тагын берне өз диеп
Сорап тора тамагым.
Телләр ике катлана,
Тешләр була кап–кара.
Тик ашыймын барыбер:
Тагын бер дә, тагын бер.
Теш каралса — агарыр,
Тамак бетсә — яңарыр:
Аларыннан курыкмыйм,
Бигрәк тәмле шомыртым.
Эреп тора авызда,
Кирәк түгел карбыз да.
Шундый балланып пешкән,
Гел минем өчен үскән.
Өй артында шымыртым,
Чыгып ашыйм шыпыртын.
Ашый торгач, бер бакча
Шомыртны мин сыпырттым.

*1973*

## МУЛЬТФИЛЬМНАР КАРЫЙБЫЗ

Кызык бездә кичләрен,
Ташлыйбыз да эшләрне
Җыелышып барыбыз
Телевизор карыйбыз.
Тотып әби бәйләмен
Җайлап килеп утыра.
Бабай эзли күзлеген,
Дөньяны пыр туздыра.
Сеңлем әйтә: фультфильм,
Мин әйтәмен: шук фильм.
Энем әле сөйләшми,
Шартлата гына телен.
Әти газетын ташлый,
Әнинең сөте ташый.
Әбекәйнең йомгагын
Мәче чуалта башлый.
Бернәрсә дә күрмибез,
Бетә дөнья кайгысы:
Бүре куа Куянны,
Җитезрәк кайсысы?
Адым саен маҗара.
Кызык хәйран-тамаша.
Куяны да, Бүресе дә
Армый икән армаса.
Армас идек без дә һич,
Бигрәк кыска мультфильм.
Өлгермисең карарга
Бетә куя шук фильм.

*1973*

## КҮЗ ТИДЕРӘМ КИРЕГӘ

Бәби карыйм, уйнатам,

Елады исә — юатам.
Җилкәмә дә мендерәм,
Шырык-шырык көлдерәм.
Син бит матур, тәти, дим,
Бер йөрерсең тәпи, дим.
Авыз-борының ап-ак, дим.
Тешкәйләрең вак-вак, дим.
Беркөн бәби чирләде:
Бер кызды, бер тирләде.
Чакырганга килмәде,
Шырык-шырык көлмәде.
Әни әйтте: «Күз тигән!
Бигрәк матур бала бит.
Гел сокланып карарга
Ярамый шул аңа бик».
Ярамагач ярамый —
Хәзер алай карамыйм:
Син бик какай бала, дим,
Авыз-борының кара, дим.
Иреннәрең кыек, дим.
Буыннарың сыек, дим.
Инде бәби терелә,
Тәтиләргә үрелә:
Терелмичә нишләсен —
Күз тидерәм кирегә.

*1974*

## АЙНУР

Тәртип ярата Айнур —
Юа, чистарта, сөртә.
Өйгә дә ул һәркемне
Тикшереп кенә кертә.
Әткәсе кайтса эштән,
Ул чабып чыга эчтән:
Итекләрең салып кер,
Бүрегеңне кагып кер.
Әнкәсенә дә әйтә:
Якаңа кар кунган, ди.
Эремәсен идәнгә,
Аны яңа юган, ди.
Сеңлесенә болай ди:
Бүген суык ай-яй, ди.
Чыгып йөрмә, туңарсың,
Туңарсың да еларсың.
Ә ял көне идәнне
Әнкәләре юа гел.
Андый көннәрдә Айнур
Аяк сөртеп керергә
Үзе онытып куя шул.

*1974*

## КАЯН БЕЛГӘН БАЛ КОРТЛАРЫ

Абыйсы һәм энесе —
Барый, Хәсән — икесе
Беркөн өйдә калдылар
Һәм бал эзләп алдылар.
— Ашыйбыз, — диде Барый,
Телләрен ялый-ялый.
Кыстатмады Хәсән дә —
Кулын тыкты тәпәнгә.
Кереп-кереп чыктылар,
Ашадылар туйганчы.
Утырып та, басып та,
Бармаклары шәп булгач,
Кирәкмәде кашык та.
Әнкәләре кайтты да
Күреп алды бу хәлне,
Сорады улларыннан:
— Йә, кем ашады балны?
Барый әйтте: мин түгел.
Хәсән әйтте: мин түгел.
Берәр песи кергәндер,
Балыңа шул тигәндер.
Икесе дә тындылар,
Тәки әйтми калдылар.
Һәм чыктылар уйнарга,
Йөгереп көч җыйнарга.
Ә урамда боларны
Кортлар сырып алдылар.
Селтәнмичә, сукмыйча
Җиргә егып салдылар.
Якадан да керделәр,
Җиңнәрдән дә керделәр,
Барый белән Хәсәнне
Бик шәпләп «пешерделәр».
Иреннәр күмәч булды,
Күзләре күрмәс булды.
Ә телләре зураеп
Авызда йөрмәс булды.
Чүпләделәр малайлар
Елый-елый укларын:
— Әнкәй дә белмәгәнне
Белде, — дип — бал кортлары.

*1974*

## КАРГАЛАР ТЕЛЕ

Күктә бик күп карга,
«Кар», «кар» килә бар да.
Телләрендә шул сүз,
Кунсалар да талга.
Әни әйтә: «Димәк,
Тиздән яңгыр явар.
Әнә шулай «кар», «кар»
Яңгыр тели алар».
Каргаларның теле
Кызык кына икән:
Яңгыр дияр чакта
Кар сорыйлар күктән.

*1975*

## ӘЙТЕРГӘ БИК АВЫР СҮЗ

Авылдан беркөнне бабай
Алып килде алмалар.
Алмалары, алмалары
Ут шикелле яналар.

Иң зурысын сайлап кына
Миңа бирде бабакай:
— Менә шушы алма кебек
Тәгәрәп үс, балакай.

Аннары сузды энемә
Янып торган кызылын:
— Мә, мә, улым, бусы сиңа,
Кил болайрак, суз кулың.

Ләкин энем куркып кына
Алды аның алмасын.
Һәм өстәл астына кереп
Утырды ул аннан соң.

Нигә алай алма дигәч
Качты икән дисезме? —
Рәхмәт әйтүдән курыкты,
Әйталмый ул шул сүзне.

*1975*

## ЯЛКАУ ЯЛЫ

Әти әйтә: «Әй, улым,
Бигрәк әллә нинди син.
Эш турында әйтмим дә,
Ял итә дә белмисең».

Ял итәргә аңарга
Нинди белү кирәктер?!
Минем кебек ял иткән
Болай да бик сирәктер.

Көннәр буе өйдә мин,
Ятамын гел диванда.
Телевизор карыймын,
Мультфильмнар булганда.

Йөгермимен, чапмыймын,
Сазга батып кайтмыймын,
Чапсын әйдә юләрләр,
Мин аякны саклыймын.

Киерелеп, сузылып
Тып-тыныч ял итәмен.
Әнә шулай ял итеп
Хәтта арып бетәмен.

Бәйләнәләр юкка да,

Кызык та бу өлкәннәр,
Әйтерсең лә үзләре
Миннән шәп ял иткәннәр.

*1975*

## БЕРЕНЧЕ ЗВОНОК

Яшел чирәмдә
Япь–яшь бер бозау.
Нәни муенында
Көмеш кыңгырау.
Тоягы белән
Чирәмне таптап
Әрле дә бирле
Йөри уйнаклап.
Атлаган саен
Кыңгырау чыңлый.
Кыңгырау җырын
Басулар тыңлый.
Тәүге звонок
Яңгырый ерак,
Урман–кырлардан
Кайта ул урап.
Кырлар уяна,
Басулар гөрли.
Һәрбер үсемлек
Кояшка үрли.
Ә шаян бозау
Чаба да чаба.
Язлар җитә дип
Кыңгырау кага.

*1975*

## ЯШЕН ҺӘМ ЯҢГЫР

Кылычын болгап
Әйткән ут-яшен:
— Мин бар нәрсәне
Куркытып яшим.
Чиксез-чамасыз
Гайрәтем, көчем.
Мин туам бары
Җимерер өчен.
Кылыч селтәсәм,
Ава имәннәр.
Очкын төшерсәм,
Яна кибәннәр.
Ташларны ватам,
Тауларны ярам.
Үткән җиремне
Көл итеп барам.
Яшенгә әйткән
Болай дип яңгыр:
— Көл итү җиңел,
Гөл итү авыр.
Егып атканчы
Йөз яшь имәнне
Үстереп кара

Син бер үләнне.
Көчлеләр төзи,
Көчсезләр вата.
Һәр начарлыкта
Куркаклык ята.

*1975*

## КЕМНӘР ТИБЕП ҖИБӘРГӘН?

Күн туп китте тәгәрәп —
Йомшак яшел чирәмнән.
Куа чыкты малайлар
Якындагы өйләрдән.
Борылды туп уңга да,
Борылды туп сулга да.
Капкага да керде ул,
Чыкты олы юлга да.
Малайлар туп артыннан
Чыктылар да чаптылар.
Барган саен үзләре
Ишәйделәр, арттылар.
Куа чыкты Зариф та,
Куа чыкты Гариф та:
Торган саен ныграк
Кыза барды ярыш та.
Айлар үтеп киттеләр,
Еллар үтеп киттеләр.
Туп тибүче малайлар
Егет булып җиттеләр.
Ә туп бара һаман да,
Тәгәри ул чирәмнән.
Кемнәр аны шулкадәр
Каты тибеп җибәргән?

*1975*

## МИНЕМ ЧАНА

Агач-богач таптым,
Чана ясап аттым.
Бик шәп чыкты чанам,
Күз алалмыйм аннан.
Табаннары көзге,
Очып бара үзе.
Выж-выж менә үргә,
Туктап калмый бер дә.
Моторсыз да чаба,
Әйбәт булды чана.
Батмыйм йомшак карда,
Мактый аны бар да.
Ничек йөри? Әйтәм:
Мин бит аны тартам.
Өстәвенә энем
Этеп йөри арттан.

*1975*

## ҖИҢЕЛӘЙТҮ ЧАРАСЫ

Әнисе белән Ләйлә
Кибеттән кайтып килә.
Кайтасы юл шактый бар,
Әкрен генә атлыйлар.
Ләйлә кулында сумка,
Сумкасында өч булка.
Булкаларымы зурлар —
Күтәрергә авырлар.
Алыр иде әнисе,
Кулында бар бәбисе.
Кемнән ярдәм көтәргә,
Ничек кайтып җитәргә?
Ярты юлны үткәчтен,
Куллар талып беткәчтен,
Тагын кибет күрделәр —
Ансына да керделәр
Һәм алдылар шоколад,
Шоколадка Ләйлә шат.
Сал, ди, әнкәй, син монда,
Урын бар, ди, сумкамда.
Юлның калган яртысын
Кайтты Ләйлә җил дә җил:
Шоколад та салгачтын
Сумка булды җип-җиңел.

*1975*

## «ӘЙБӘТ» ЯВЫЗ

Дөньяда яши
Бер «әйбәт» явыз:
Эретә кулында,
Итә балавыз.
Кизәнми, сукмый —
Йомшак кылана:
Куеныңны ачсаң,
Килеп сылана.
Йокыңнан торыйм
Дисәң әгәр дә —
Башыңнан сыйпап
Сала мендәргә.
Дәресең укырга
Утырсаң, тагын
Йөгереп килеп
Яба китабың.
Мәктәбеңә дә
Барма, дип тора.
Чаңгы шу әнә
Тауда, дип тора.
Йомшак җәя дә
Катыга сала.
Ярата аны
Күп кенә бала.
Җайлый җайсызны,
Көйли көйсезне.
Бу нинди әйбәт
Явыз дисезме?

Исемен әйтәм,
Белеп калыгыз:
Ялкаулык булыр
Бу «әйбәт» явыз.

*1976*

## КРАН

Урамда эшли кран,
Муенын алга сузган.
Хәрәкәте бик салмак,
Цирктагы фил сымак.
Әнә ул зур панельне
Нинди җиңел күтәрде,
Әйтерсең фил үрелеп
Учтан алды шикәрне.

*1976*

## ҖИРГӘ ЯКЫН БУЛСА КЕШЕ

Җирдә ята бүрәнә,
Бүрәнәдә нәни кыз, —
Бер башыннан бер башына
Йөреп тора тыз да быз.
Титаклап та йөри ул,
Уйнаклап та йөри ул.
Тик кайсылый йөрсә дә,
Егылуны белми ул.
...Бүрәнәне беркөнне
Өрлек итеп куйдылар.
Өрлек итеп куйдылар да
Менүләрне тыйдылар.
Ләкин кызчык түзмәде,
Менеп китте өрлеккә.
Ике генә атлады да
Тигез җирдә сөрлекте.
Нәрсә булды? Нилектән
Баралмады биектән?
Күз йомып та үткән иде
Җирдә шушы өрлектән.
Кичәгенәк бу кызның
Егылмавы шундадыр:
Җиргә якын булса кеше
Батыррак буладыр.

*1976*

## БӘП-БӘЛӘКӘЙ БУЛСАМ ДА

Ярый елга булмаганмын,
Юллар сөйгәнгә генә;
Елгаларның нindie дә
Ага түбәнгә генә.

Ярый мин тау булмаганмын,
Күңелем биеккә генә;

Тауларның бит барысы да
Карыйлар күккә генә.

Ярый диңгез булмаганмын,
Ярсуым күпкә генә;
Диңгезләр бит үз байлыгын
Яшерә төпкә генә.

Сөенәмен тауларга һәм
Суларга карый-карый;
Бәп-бәләкәй булсам да мин,
Кеше булганмын ярый!

*1977*

## МУ-МУ-МУ...

Өзми дә, куймый да —
Әй елый энебез.
Нәрсәгә елавын
Беребез белмибез.
Тоттырып карыйбыз
Тәтинең төрлесен:
Дәү, чатан Аюын,
Уткойрык-Төлкесен.
«Атлан, — дип, — үземә», —
Ат килә каршына.
Аттан да уздырып
Выжылдый машина.
Тик энем туктамый,
Елавын белә гел.
Нәрсәдер әйтмәкче:
«Му-му-му...» килә гел.
— Ни соң ул «Му»? — дибез,
Юк инде, белмибез.
Төрлечә юатып,
Төрлечә көйлибез.
Телебез арыгач,
Кул селтәп аңарга
Утырдык барыбыз
Мультфильм карарга.
Туктады энем дә
Елаудан шул вакыт.
— Му-му, — дип сөйләнә
Куанып, шатланып.

*1977*

## ӘНИ

Иң матур юллар —
Син йөргән юллар.
Иң тәмле сулар —
Син биргән сулар.
Иң йомшак куллар —
Син сөйгән куллар.

Иң якты моңнар —
Син белгән моңнар.
Иң кайнар эзләр —
Син баскан эзләр.
Иң моңлы күзләр —
Син баккан күзләр.
Иң тугры сүзләр —
Син әйткән сүзләр.
Иң сабыр йөрәк —
Синең йөрәгең.
Иң изге теләк —
Синең теләгең.
Иң бөгелгән бил —
Ул синең билең.
Гөл сибелгән тел —
Ул синең телең.
Үч тотмас күңел —
Синең күңелең,
Әни!

*1977*

## ТАПКЫР ҖАВАП

Бабасы сорый малайдан:
— Үскәч кем буласың, балам?
Җавап бирә аңа малай:
— Үскәч мин дәү кеше булам.

*1978*

## АВЫР КӨН

Әни әйтә: «Ни булды,
Авырыйсыңмы әллә? — ди. —
Алай диеп әйтергә
Кызуың юк тәндә», — ди.

— Юк, әнием, авырмыйм,
Ләкин хәлем авыр, — дим, —
Шуңа кәеф юк минем,
Булмый бүген мультфильм.

*1978*

* * *

Радиодан әйттеләр:
— Бүген җәяүле буран!
Тәпиле җилләр күрмәдем
Күпме урап та урам.

Кая китте икән соң ул,
Каян эзләп карарга?
Әллә өйгә керде микән
Итекләрен кагарга?

*1978*

## КЕМ ЯЛГЫШКАН?

Әй сайрады бер саескан
Күрше бакчада чыр–чыр.
Әни әйтте: «Күршеләргә
Кунак килер, күр дә тор».

Кунаклар безгә килде шул,
Уйлап йөримен эчтән:
Саескан ялгышты микән,
Әллә кунаклар микән?

*1978*

## КИБЕТТӘ

Әтисенә ияреп
Кибеткә килде Шәриф.
Йөри торгачтын залда
Зур шкаф күрде анда.
Әйтте: «Әти, ал шуны,
Шундый шәп, шундый олы.
Төргән кәгазе моның
Җитәр миңа ел буе.

*1978*

## ФАЗЫЛ

Кисәтәләр Фазылны
Әтиләре гел генә:
— Салкын тидерә күрмә;
Җылырак ки өстеңә.
Аннан-моннан киенеп,
Чаба Фазыл урамга.
Җилсез көнне җил куба,
Ул урамда булганда.
Салкын аны күрүгә
Табанын ялтырата:
Берәрсенең тун эчендә
Дер-дер калтырап ята.

*1978*

## ШУЛ ЯВЫЗНЫ КҮРСӘЛӘР

Әнинең йөзе сытыла,
Әтинең йөзе сытыла —
Барсының йөзе сытыла,
Әйтерсең кояш тотыла,
Шул явызны күрсәләр,
Ишетсәләр, белсәләр.
Беркем дә сөйми аны,
Их, шәп син, дими аны.
Мөмкин булса — кермәсен дип,

Бу тирәдә йөрмәсен дип,
Ипләп кенә, бикләп кенә
Куяр идек капканы.
Ләкин ул бик хәйләкәр,
Җаен көтеп ята гел:
Абыйга йә апага
Иярә дә кайта ул.
Сыртыңа да атланыр,
Атланыр да шатланыр.
Ул бит елан шикелле —
Дәфтәрдәге икеле.

*1978*

## АИДА

Күрше кызы Аида
Керә безгә һәр кичне.
Нәни генә булса да
Бик ярата ул эшне.
Йә гөрләшә-гөрләшә
Өстәлләр әзерләшә.
Чынаяклар тезеп чыга
Һәм кашыклар өләшә.
Йә савытлар юам дип
Йөри ул бөтерелеп.
Кранга да көчкә-көчкә
Җитә буе үрелеп.
Чыгып киткәндә әйтә:
Мин керермен әле, ди.
Мин юган савытларга
Тотынмагыз, яме, ди.

*1978*

## УКЫР ИДЕМ БИШКӘ ГЕНӘ

Укыр идем бишкә генә —
Кермәс иде ул бишлеләр
Бары минем төшкә генә:
Рус теленнән язмаларны
Кагыйдәсез яздырсалар,
«Е»лар, «И»ләр аз булсалар.
Өтер, сызык, нокталарны
Куйдырсалар теләгән җиргә,
Начар алмас идем бер дә.
Менә тагын бер яманы —
Ярата гел санаганны.
«Икс»ларны, «игрик»ларны
Аны чуртым аңлаганмы!
«Икс»ны да, «игрик»ны да
Бабайлар бит белмәгәннәр,
Аңа карап үлмәгәннәр.
Географиясен әйтер идем,
Бер юләре уйлап тапкан.
Миллион төрле елгалары
Миллион якка таба аккан.
Диңгезләргә кереп китсәң,
Батмый гына чыгам димә.
Африкалар, Азияләр,

Европалар миңа нигә?
Мин барыбер ятам өйдә.
Начар билге алмас идем,
Авыр фәннәр кермәсәләр.
Өйгә эшләр бирмәсәләр,
Дәрестә сөйләтмәсәләр.
Һәркөн саен яңа дәрес
Өйрәтеп йөдәтмәсәләр.
Йә бөтенләй бетерсәләр
Берле, икеле, өчлеләрне.
Калдырсалар көләч йөзле
Матур-матур бишлеләрне,
Укыр идем бишкә генә.

*1978*

## БӨЕК ШАГЫЙРЬ

Апрель, апрель — бөек шагыйрь,
Шигырь синең һәр сулышың.
Гөрләвекләр белән җиргә
Шигърият һәм җыр юллыйсың.

Аңлашыла синең иҗат
Дөньядагы һәрнәрсәгә.
Мәңгегә үз итәр өчен
Ишетү җитә бер мәртәбә.

Урман кызы — умырзая
Гашыйк синең җырларыңа —
Кар суында коена-коена
Карый килер юлларыңа.

Кыр йөрәге — сайрар кошлар
Ялкын өстәп талантыңа,
Җырларыңны күтәрәләр
Үзләренең канатында.

Яз ирене — бөреләр дә
Синең җырны пышылдый гел;
Табигатьнең теле ачылган
Синең җырың белән, Апрель.

*1979*

## АРУ ТУРЫНДА

Эшләп ару — рәхәт ару,
Эшли–эшли арылсын;
Эшсезлектән арылмасын,
Күрсәтмәсен анысын.

Көтеп ару — өметле ару,
Көтеп арта януың.
Билгесезлек арытмасын,
Табу кыен даруын.

Юлда ару — татлы ару,
Арылса да барылсын;

Адашулар арытмасын,
Юл тапмасаң авыр соң.

Җиңел эшләр таләп итмим,
Талчыктырсын, арылсын:
Яшәү генә арытмасын,
Күтәралмам анысын.

*1979*

## ТЫЛСЫМЧЫ

Беләсезме? —
Шундый тылсымчы бар җирдә.
Ул тылсымчы
Гайрәтле дә, бик өлгер дә,
Канаты юк,
Ләкин килеп җитә очып
Һәм тотына
Үз эшенә бик тырышып.
Җилләр чыга
Ул тылсымчы сызгырудан.
Күккә бакса,
Кояш туктый кыздырудан.
Сулышын өрсә,
Чәчәкләр таҗларын сала.
Бер селтәнсә,
Урманнар шәп-шәрә кала.
Булыр аның
Өстендә гел болыт-җилән,
Селтәнер ул
Офыкларга шуның белән.
Әгәр аны
Очратсагыз, танырсыз сез.
Танымасаң,
Ачуланыр тылсымчы-көз.

*1980*

## УЗЫШ

Өч кыз бала — өч туган
Ярышалар үзара.
Исе китә һәркемнең
Менә шушы кызларга.
Әле уза олысы,
Әле уза кечесе.
Ә кайвакыт ярышта
Тигезләшә өчесе.
Узам, узам, узам, дип,
Ярышалар туктаусыз.
Артта калса берәрсе —
Төн уздыра йоклаусыз.
Әнкәләре һәрвакыт
Әйтә килә кызларга:
«— Тырышмагыз ул кадәр
Бер–берегезне узарга».
Юк, тыңламый берсе дә.

Язардай булып һуштан
Өч кыз бала — өч туган
Киенәләр узыштан.

*1980*

## СЕРЛЕ ЧИШМӘ

Дөньяда бар
Төрле чишмә.
Шуның берсе
Серле чишмә.
Суы тирән —
Төпсез аның.
Юлы ерак —
Чиксез аның.
Олыга да,
Кечегә дә,
Батыр, көчле
Кешегә дә
Бу чишмәнең
Татлы суы
Бик тә кирәк
Гомер буе.
Әгәр кеше
Юлга чыкса,
Юлга ала
Аның суын.
Серле чишмә
Суы белән
Ләззәтләнгән
Күпме буын.
Бу чишмәнең
Суын әле
Бездән соң
Күпләр эчәсе.
Саекмасын,
Гел саф калсын
Серле чишмә —
Тел чишмәсе.

*1980*

## ЮЛЛАР ЮЛЫ

Кая гына
Илтми юллар:
Далаларга,
Калаларга,
Чит-ят илгә,
Кайнар чүлгә,
Кар-буранлы
Котыпларга,
Ерак-ерак
Офыкларга,
Йолдыз, Айга,

Биек тауга,
Ак бәхеткә,
Дан-тәхеткә.
Зур максатка —
Ачышларга,
Табышларга,
Ялгышларга,
Илтә хәтта
Киләчәккә.
Кешеләрнең
Язмышы — юл.
Һәркем аны
Үзе яза,
Үзе уза,
Үзе сыза,
Үзе боза.
Бөтен якка
Юллар киткән:
Җирдән, судан,
Зәңгәр күктән.
Хәтта безнең
Үткәннәргә
Борма-борма
Юллар киткән.
Бу юл озын
Һәм бик олы.
Бу юл барлык
Юллар юлы,
Бөтен юллар
Кушыла монда —
Бу юл безнең
Хәтер юлы.

*1980*

## МИНЕМ САКЧЫМ

Син гел солдат,
Син гел сакта.
Мин тып–тыныч
Син бар чакта.
Уяулыгың
Җуймыйсың син,
Ялгыш күз дә
Йоммыйсың син.
Әзме була
Янаучылар
Яки күрә
Алмаучылар
Син саклаган
Гөлбакчага
Йә көнләшеп
Караучылар.
Курыкмыйсың
Таш атсалар.
Алданмыйсың
Аш атсалар.
Син гел уяу,

Син гел сизгер.
Карашың нык,
Күзең үткер.
Бик арысаң,
Бик талсаң да,
Яралансаң,
Кан саусаң да —
Юк алмашың,
Юк бер ялың;
Мәңге сакта
Син, Вөҗданым.

*1980*

## ТУЙМЫЙМ

Мин бер комсыз кеше түгел,
Зарланмыйм бай булмаудан;
Туймыйм ләкин туган җирнең
Саф һавасын сулаудан.

Туймыйм күпме тыңласам да
Газиз ана телемнән;
Дөньяның тәүге серләре
Шуның аша беленгән.

Туймыйм йолдызлар сибелгән
Биек, аяз күгеннән;
Зәңгәр күкләр йолдыз белән
Йөрәгемә чигелгән.

Туймыйм кара туфрагыннан,
Туймыйм аккан суыннан,
Туймыйм искән җилләреннән,
Туймыйм озын юлыннан.

Туймыйм карлы буранынннан,
Яшеннәре яшьнәүдән;
Туймыйм Туган илкәемә
Гаҗәпләнеп яшәүдән.

*1980*

## КУЛЛАР

Куллар мәңге иҗат итеп торган,
Шулай килгән борын-борыннан.
Куллар белән туган бөтен нәрсә,
Куллар белән дөнья корылган.

Тормыш дигән төзелеш мәйданында
Төземәгән куллар ни генә!
Ташны ташка бәреп утлар тапкан,
Җылы керткән куыш-өенә.

Шәрә тәнне куллар киендергән,
Ач тамакны куллар туйдырган.
Кешеләрне хезмәт кеше иткән,
Ә хезмәтне кеше тудырган.

Иң беренче нинди сүз әйткәнмен,
Дөньяны мин ничек ачканмын?
Әниемнең итәгенә тотынып,
Кайчанрак тәпи басканмын? —
Белмим.

Күп нәрсәләр инде онытылган,
Сакламаган хәтер боларны.
Мин, ахрысы, күзем ачу белән
Күргәнмендер эшчән кулларны.

Хәтеремдә: әнкәй киндер суга,
Ярты өйне алган станы.
Кулы ничек тотып өлгерәдер
Җеп корсаклы шома сосаны.

Ак җеп сузып выж-выж йөри соса
Әле сулга, әле уң якка:
Әйтерсең лә шаян үрдәк йөзә
Су салынган тирән улакта.

Ярдан ярга килеп бәрелә дә
Тагын чума дулкын-җепләргә.
Тәрәзәдән кергән нурлар белән
Әнкәй җебе сузыла күкләргә.

Җепләр, җепләр! Күпме эрләнгән дә
Күпме киндер шулай сугылган.
Ничә еллар кылыч төшмәгән бит
Ару белмәс әнкәй кулыннан.

Кылыч, ләкин сугыш кылычы түгел,
Тормыш кылычы, хезмәт кылычы.
Салкыннардан безне саклап калган
Әнкәй кулларының җылысы.

Җылы безгә бик күп кирәк булды.
Салкын иде бигрәк еллары —
Кочаклардан безнең каерып алып
Әтиләрне сугыш урлады.

Вакыт аргамагы алга чаба,
Куып тора еллар елларны.
Үткән белән бүгенгенең җебен
Тоташтырган әнкәй куллары.

*1980*

## СОРАУ ҺӘМ ҖАВАП

Кабатлыйм бер сорауны
Өнемдә һәм төшемдә:
«Кеше булып яшәргә
Нәрсә кирәк кешегә?»
Диңгез әйтә: — Тирәнлек.
Урман әйтә: — Бердәмлек.
Таулар әйтә: — Горурлык.

Юллар әйтә: — Турылык.
Җир эндәшә: — Юмартлык.
Чык суы әйтә: — Сафлык.
Яшен әйтә: — Кыюлык.
Ипи әйтә: — Олылык.
— Гүзәллек, — диләр гөлләр.
— Иркенлек, — диләр җилләр.
— Нык канат, — ди бөркетләр.
— Биеклек, — диләр күкләр.
Һәм шушылар өстенә
Кирәк тагын иң элек,
Кешене кеше иткән
Бер нәрсә — Кешелеклелек.

*1981*

## КЫШ

Син ирләрдәй каты куллы,
Тоткан җирдән сындырасың.
Тамчың ялтыраса кайчак,
Күз яшеңнән оялгандай,
Тизрәк кире туңдырасың.
Йә башын җуйган гашыйктай,
Юмарт кылана башлыйсың.
Бүләк арты бүләк ташып,
Ап-ак чәчәкләрең белән
Дөньяны күмеп ташлыйсың.
Ә кайвакыт көне-төне
Ярсыйсың һәм шашынасың.
Максатыңа җиткәч кенә
Тын каласың, басыласың.
Күп нәрсәгә сәләтле син,
Синнән барсын була көтеп:
Ялкыннарың җитмәгәндә
Салкыннарың ала өтеп.
Теләгәндә, очкан кошны
Төшерәсең егып җиргә.
Бар яклап та охшагансың
Сүзен сүз итүче иргә.

*1981*

## ТӨГӘЛ ҮЛЧӘҮ

Кулымда ипи телеме,
Әй йомшак ул, уңган ул.
Күзәнәге саен һава —
Шундый җиңел булган ул.
Үлчәүгә салып карасаң
Әгәр шушы телемне,
Герләр аның авырлыгын
Әйтеп бирер идеме?
Юк, юк, аны үлчәр өчен
Җитмәс гер көче генә.
Аның төгәл авырлыгын
Белә игенче генә.
Еллар елларга охшамый,
Үзгәреп тора һава,

Иген үскәндә көйдерә,
Җыйганда яңгыр ява.
Ә игенче үз иңендә
Күтәрә бит барчасын:
Коры елларның хәсрәтен,
Явым еллар җәфасын.
Ипине дөрес үлчәмәс
Хәтта аптек герләре,
Аны төгәл үлчи бары
Игенченең иңнәре.

*1981*

## ШУНДЫЙ УЛ

Иелгәнне ярата,
Бөгелгәнне ярата;
Иелгәнгә, бөгелгәнгә
Бүләкне мул тарата.
Яшим дисәң муллыкта,
Көн дә башың и аңа:
Үрә катып йөргәннәргә
Бик саран ул Җир-ана.

*1981*

## КЫШ БАШЫ

Җылы ипи өстенә
Ягылган ак май сыман
Эреде дә бетте кар —
Калды тик сыек томан.

Бу — кышның башы гына,
Карлар күп явар әле.
Юмарт кыш җир өстенә
Майны күп ягар әле.

*1981*

## ТИРГӘҮ

Әтине эштә
Начальник тирги.
Әти кайта да
Әнине тирги.
Әни — абыйны,
Ә абый — мине:
Соң, кемнең кемгә
Көче җитә инде.
Мин дә берәрсен
Тиргәр идем дә:
Юк шул энем дә,
Юк шул сеңлем дә.

*1981*

## КОМ ӨСТЕНДӘ ИКЕ МАЛАЙ

Зур йортның ишегалды.
Ике малай — комлыкта.
Борылып-борылып каядыр
Карый алар юк-юк та.
Ә алардан читтәрәк
Пәһлевандай бер ата
Үзенең улы белән
Мәш килеп уйнап ята.
Бу малайның эш көйле:
Уйный, тәгәри, көлә.
Һәрбер кыланышыннан
Чиксез шатлык бөркелә.
Шулчак комда утыручы
Малайның әйтте берсе:
— Минем әти — капитан,
Минем әти — диңгезче.
Кайта алмый тиз генә,
Йөзеп киткән еракка.
Мин дә уйнармын әле
Әти кайтса кунакка...
Тыңлап–тыңлап торды да
Иптәшенең сүзләрен,
Әйтте икенче малай,
Читкә текәп күзләрен:
— Минем әти — генерал,
Ерактарак тагын да,
Беләсең килсә, аның
Наганы бар янында.
Үскәчтен, зур булгачтын
Мин дә наган тагармын.
Әти кайтып җитмәсә,
Үзем эзләп табармын.
...Хыял белән малайлар
Китте әллә кайларга...
Хыял да — зур юаныч
Атасыз малайларга.

*1981*

## ӘЙБӘТ КЕШЕЛӘР

Фәрит тә бик әйбәт кеше,
Шәриф тә бик әйбәт кеше.
Дөньяда тагын берәү бар
Әйбәт кеше алар ише.

Фәрит тә мине дус итә,
Шәриф тә мине дус итә,
Кирәк булса икесе дә
Минем өчен үлеп китә.

Ә бит бездә, дустың, диләр,
Үзеңнән шәп булсын, диләр.
Димәк, мин шәп Фәриттән дә,
Димәк, мин шәп Шәрифтән дә.

*1982*

## АРТТАН ЙӨРЕР ИДЕГЕЗ

Хәмитне мактый кешеләр,
Ул оста, диләр, эшкә:
Шундый итеп ясап куйган
Китапларына киштә.
Имеш, Хәмит алтын куллы,
Булдыра нәрсә тотса;
Ботинкасын да төзәтә,
Йөреп табаны купса.
Ә мин булдырмас идемме?
Мин дә калмаган төшеп.
Рәхәтләнеп ямар идем
Күрсәм бер ертык, тишек.
Юк шул бездә ертык-тишек,
Бездә бар нәрсә яңа.
Китап төзим дисәң, шкаф
Күзеңнең явын ала.
Ә ботинка, итекләрнең
Купмый бер дә табаны.
Ничек куптарып өлгертим,
Алалар гел яңаны.
Кайчак минем бар нәрсәне
Ватып ташлыйсым килә.
Ватып ташлап, өр-яңадан
Үзем ясыйсым килә.
Минем кем икәнлегемне
Шунда күрер идегез...
Шулай ит тә болай ит, дип,
Арттан йөрер идегез.

*1982*

## КӨНЛӘШМИМ МИН

Бөтен матур нәрсәләрне
Сеңлем елап үзенә ала:
Иң матур уенчык аңа,
Иң матур урындык аңа.
Бар да аңа: яулыкның да,
Башлыкның да иң матуры;
Чынаякның, тәлинкәнең,
Кашыкның да иң матуры.
Әйдә алсын, көнләшмим мин,
Уйламыйм да ул турыда.
Ә мин менә укып йөрим
Мәктәпнең иң матурында.
Парталарда, такталарда
Тора кояш уйнап кына.
Сеңлем инде аны миннән
Ала алмый елап кына.

*1982*

## КАРАБАЙ

Минем этем Карабай,
Нәкъ менә шук баладай:
Нәрсәнедер тарткалый,
Нәрсәнедер ваткалый.
Йә өстери балактан
Яки үбә яңактан;
Ул да мине ярата,
Мин дә аны яратам.
Тик менә бер ягы бар:
Өрә белми юри дә.
Сузыла да ята гел,
Уйнап-уйнап йөри дә.
Әни әйтә, эт булгач,
Һау да һау өрсен ул, ди.
Явызларны, бурларны
Куркытып йөрсен ул, ди.
Ә бу нәрсә? Төннәрен
Күренми дә күзгә, ди.
Бакчаны сакламагач,
Эт ник кирәк безгә, ди.
Аның шулай икәнен
Беләм лә мин, беләм лә.
Чаптым инде мунчада
Кычытканнар белән дә.
Койрыгыннан йон кисеп,
Бер сыйлап та карадым.
Авырттырмыйча гына
Бер кыйнап та карадым.
Юк, өрми инде, өрми.
Бакчаны саклап йөрми.
Әллә чын өрә белми,
Әллә кылана юри.
Уйлый торгач шулай да
Бер чарасын таптым мин:
Карабайның муенына
Бер кыңгырау тактым мин.
Хәзер менә бакчада
Кыңгырау чың-чың итә.
Кыңгырау чың-чың иткәч,
Караклар керми китә.
Әни дә тынычланды,
Әби дә тынычланды.
Карабай уйнап йөри,
Күңелле ишегалды.
*1982*

## КҮЗЕ КИТАПТА ГЫНА

Гөлнар дәрес әзерли,
Китабыннан күз алмый:
Озын сәгатьләр буе
Урыныннан кузгалмый.

Әткәсе һәм әнкәсе
Бик канәгать бу хәлгә.
Аяк очында гына
Йөри алар идәндә.

Нәниләргә әйтәләр,
Шыпырт, диләр, шашмагыз.
Әнә ничек тырышып
Дәресен карый апагыз.

Эш кушмыйлар Гөлнарга,
Укысын гына, диләр.
Кыз акылга утырды,
Сөеник шуңа, диләр.

Ә Гөлнар баш күтәрми,
Китапта гына күзе.
Ябар иде китабын,
Китап эчендә көзге.

*1982*

## ЯЗ

Яз — табигатьнең вәгъдәсе.
Шуннан китә зур эш:
Агачтагы һәрбер бөре
Вәгъдә итә җимеш.
Җәелеп яткан басу-кырлар —
Көшел-көшел бодай.
Болыннарның вәгъдәләре
Тау-тау печән бугай.
Сөенечле яңгыр гына
Вәгъдә итә күкләр,
Кояш — шифалы җылылык,
Тәнгә сихәтлекләр.
Җилбәзәк җилләр — җитезлек,
Юллар — очрашулар.
Ә яшеннәр — тетрәнүләр
Һәм дә бушанулар.
Таңнар мәңге онытылмаслык
Сөю шатлыклары.
Яшәрүләр, дәртләнүләр,
Күңел сафлыклары.
Яз — табигатьнең вәгъдәсе,
Ә вәгъдә ул — өмет.
Җанда мең өмет уяна
Язлар килсә көлеп.

*1982*

## АРИФМЕТИКАНЫҢ ДҮРТ ГАМӘЛЕ

Берле санын шулай
Җидегә бүлү серен
Әни каян белгән? —
Бер сыныкны ул бит
Һәрчак тигез итеп
Җиде өлешкә бүлгән.
Кушу-алуны да
Укытучыдан түгел,
Өйрәнгән тормыштан:

Безгә җитми икән —
Үз өлешеннән алган,
Безнекенә кушкан.
Тапкырлау гамәле
Һәркайсыбыз өчен
Җиңел түгел, беләм.
Тик аның да серен
Безгә караганда
Әни яхшы белгән.
Без бер эш эшләсәк,
Әни аны эчтә
Яшереп яткырмаган —
Безнең эшебезне
Кешегә сөйләгәндә
Унга тапкырлаган.

*1982*

## КЕЧКЕНӘ КЕШЕ

Әнисе әйтә
Өлкән кызына:
— Ипи юк икән,
Әтиең тузына.
Көзгең читкә ат,
Ипи алып кайт.
Берүк тиз-тиз йөр,
Аш пешә хәзер.
Кыз ачу белән
Атты көзгесен,
Чакырып кертте
Үзенең энесен:
— Бар әле, энем,
Кибеткә сыпырт.
Ипи алып кайт...
Сөйләнмә, шыпырт.
Тәрәзә ачып
Дәште энесе,
Урамда уйный
Иде сеңлесе:
— Әй син, чикерткә,
Йөгер кибеткә.
— Нигә?
— Ипигә,
Ипи юк өйдә.
Шап-шоп сикереп,
Керде йөгереп
Сеңел-«чикерткә».
Әйтте: «Әбекәй,
Йөгереп кенә
Барчы кибеткә».
Әби нишләсен? —
Киде бишмәтен,
Алды таягын —
Сөйрәп аягын,
Китте кибеткә,
Әйтми «эһ» дип тә.

*1982*

## ТАБУ ҺӘМ ЮГАЛТУ

Мәктәбеннән ручка табып
Кайтты Дилбәр:
— Әйбәт булган, — дип мактады
Өйдәгеләр.
Кыз күңленә мактау акмай
Булып ятты:
Икенче көн ул бер китап
«Табып» кайтты.
Сөенделәр: «Әйбер кадерен
Белә бала.
Ачык авызлар югалта,
Ә ул таба».
Дилбәр шулай төрле нәрсә
«Таба» торды.
Мәктәп белән өйгә юлны
Саба торды.
Вак-төякләр әкрен-әкрен
Җыела торды:
Һәрбер нәрсә җайлап кына
Куела торды.
Пошынмады ата-ана
Бу хәлгә һич.
Ник пошсыннар: таба гына,
Югалтмый ич.
Дилбәр үсте, үскән саен
Күбрәк «тапты».
Һәм беркөнне ычкынмаслык
Булып капты.
Һәр тапканны куанышып
Ала-ала,
Кызларын югалтты шулай
Ата-ана.

*1983*

## СҮЗСЕЗ ГЕНӘ

Һәммәсе зарлана Рифтән,
Бигрәк усал малай, диләр.
Бу кадәрле усаллыкны
Каян алган алай, диләр.
Аптырашта ата-ана:
— Нәрсә карый соң бу мәктәп?
Тәрбия алар эше бит,
Ник акыл бирмиләр шәпләп?!
Укытучылар гаҗәпләнә:
— Ник тыймый, — дип ата-ана, —
Әгәр кулга алмасалар
Бозылачак бит бу бала.
Мәктәп белән ата-ана
Бәхәсләшә кубып зурдан.
Бәхәсләргә керми генә,
Беркемгә дә бирми генә
«Тәрбияли» Рифне урам.

*1983*

## АЙ ТУРЫНДА ӘКИЯТ

Ай турында әкиятне
Беләсезме, дуслар, сез?
Белмәсәгез, сөйлим әле,
Бер утырып тыңларсыз.
Имеш, ниндидер авылда
Бер малай яшәгән, ди.
Уймакта ботка пешереп,
Унар көн ашаган, ди.
Тик боткасына салырга
Мае булмаган икән.
Майны сатып алыр өчен
Җае булмаган икән.
Ә малайның майлы ботка
Бик ашыйсы килгән, ди.
Шуннан соң малай нишләгән? —
Тал башына менгән, ди.
Тал башында нишләгәнме? —
Аннан Айга караган.
Айга карап нишләгәнме? —
Түбәтәен ямаган.
Аннан ары, нишләгәнме? —
Әй, Ай, дигән, Ай, дигән.
Ай булганчы булсаң иде
Бер йомарлам май, дигән.
Майлы ботка ашап кына
Әй яшәр идем, дигән.
Шуннан соң нәрсә булганмы? —
Шуннан соң җил купкан, ди.
Ай тәгәрәп төшкән чакта
Малай аны тоткан, ди.
Җайлап кына алган, ди,
Түбәтәйгә салган, ди.
Түбәтәйгә салгачтын Ай
Акмай булып калган, ди.
Түбәтәйләрне тутырып
Кулда эреп тора, ди.
Мине аша, дип, авызга
Үзе кереп тора, ди.
Малай талдан төшкән дә, ди,
Аннан торып чапкан, ди.
Кеше күрмәсен дип, майга
Бер әрекмән япкан, ди.
Аннары нәрсә булганмы? —
Кинәт дөнья дөм булган.
Юлчылар юлдан язарлык
Кап-караңгы төн булган.
Малай үзе дә өенә
Кайтыр юлын югалткан.
Этләр өргән елап-елап
Әллә каян, ерактан.
Аннары нәрсә булганмы? —
Малай туктап калган, ди.
Ә аннары, ә аннары
Майны күккә чөйгән, ди.
Айсыз калгач, күкләр ямьсез,
Кире Ай бул, дигән, ди.

Ай менеп җиткән дә күккә
Гөлт итеп кабынган, ди.
Ә дөнья сөенеченнән

Ак шәлен ябынган, ди.
Төннәр Айсыз калмады, дип,
Малай бик куанган, ди. —
Ә ботка майсыз да әйбәт,
Дип эчтән юанган, ди.
Әкият тыңлый-тыңлый әнә
Ай да йоклап киткән, ди.

*1983*

## АУНАР ИДЕ

Шундый малай Искәндәр —
Карап торса бүтәннәр
Нәрсә генә кыланмый,
Кемгә генә сыланмый:
Этешә дә төртешә,
Кәҗә кебек сөзешә.
Маймыл булып сикерә,
Дөя булып төкерә.
Эт күренсә, таш ата,
Мәче мыегын тарта.
Һич булмаса, ул үзе
Пычракка кереп бата.
Иптәшләренә кызык,
Көләләр шырык-шырык.
Искәндәр-шук йөрәккә
Тик шул гына кирәк тә.
Ялгыз калса Искәндәр,
Аннан әйбәт кеше юк:
Этләрдә дә эше юк,
Мәчедә дә эше юк.
Маймылдай сикерми дә,
Дөядәй төкерми дә,
Чыпчыкка да янамый,
Пычракта да аунамый —
Аунар иде, янар иде,
Мең юләрлек табар иде,
Аңа беркем карамый.

*1983*

## ТЫРЫША ТОРГАЧ

Яшел күзле җәйләр килеп
Җитү белән,
Мәктәпләрдә бар дәресләр
Бетү белән,
Йөрдек быел кырга эшкә,
Сүз берләшеп:
Сеңлем, энем һәм мин үзем
Өчәүләшеп.
Үстердек без яшелчәнең
Төрлеләрен:
Кишер, шалкан, кәбестәнең
Эреләрен.
Утавын да утадык без,
Карышмадык.
Нишләсәк тә бер-беребездән

Калышмадык.
Тырыша торгач бөтен-бөтен
Көчебезгә
Ике норма үтәдек без
Өчебезгә.

*1983*

## ИҢ ӘЙБӘТ НӘРСӘ КЕМДӘ?

Мактаныша малайлар,
Гөр килеп тора урам.
Айрат әйтә: «Чаңгым бар
Җәй көне шуа торган».
Айратны бүлә Марат:
«Ә минем бар мопедым.
Чабам аның белән мин
Этләрнең алып котын».
Читтә калмый Зиннур да,
Күрсәтә ул сәгатен:
«Алдык әти белән, — ди,
Сайлап иң-иң әйбәтен».
Бер якта тора Рәфкать
Бәхәсне тыңлап кына.
Сәгате дә юк кулында,
Өс-баш та тыйнак кына.
Көлә аннан дуслары:
— Берние юк Рәфкатьнең!
Рәфкать әйтә: минемме?
Минем бар ун рәхмәтем.

*1983*

## ӘДӘПЛЕ БАЛА

Алма бирсәң дә,
«Рәхмәт» дип ала,
Хәлвә бирсәң дә,
«Рәхмәт» дип ала, —
Илгиз шулкадәр
Әдәпле бала.
Эшкә кушсаң да,
«Рәхмәт» дип кала.

*1983*

## ӘТИ КАРАП ТОРГАНДА

Курыкмыймын мин бүген,
Өрекмимен мин бүген
Явыз малайлардан да,
Явыз маэмайлардан да.
Ата казлар ысылдап
Муенын сузып калса да,
Сөзгәк усал тәкәнең
Күзе уттай янса да —

Курыкмыймын бер тамчы,
Уйнап йөрим урамда:
Әй рәхәт соң уйнавы
Әти карап торганда.

*1983*

## ЯЛКАУ ПЕСИ

Язгы көн. Кояш кыздыра.
Тып-тын. Җил исми.
Өй түбәсендә утыра
Бер ала песи.
Яктылыктан күзләрен ул
Яртылаш йомган.
Күзләрен яртылаш йомып,
Хыялга чумган:
«Их, зәңгәр күк, син зәп-зәңгәр
Күл булсаң иде;
Теп-тере балыклар белән
Гел тулсаң иде.
Ул балыклар җиргә егылып
Төшсеннәр иде;
Сары майда тыпырдашып
Пешсеннәр иде.
Аннары минем авызга
Керсеннәр иде;
Башка песиләр көнләшеп
Үлсеннәр иде.
Ә мин тәмләп ашап туйгач,
Мыекны сөртеп,
Кояшны мендәр иттереп,
Борынны төртеп,
Йоклар идем менә болай
Шәпләп, йомылып...» —
Дип әйткән дә ялкау песи,
Төшкән егылып.

*1983*

* * *

Шигырь кайда — бөтен төштә:
Зур диңгездә һәм инештә,
Күктә, җирдә, урманнарда,
Рәшәләрдә, бураннарда,
Яшеннәрдә, күкрәүләрдә,
Мәхәббәттән тетрәүләрдә,
Ал битендә алмаларның,
Шат йөзендә балаларның,
Елгаларда, ташуларда,
Чәчәкләрнең таҗларында,
Урамнарның ташларында,
Дәртле кошлар сайравында,
Игеннәрнең шаулавында,
Ярсып типкән йөрәкләрдә,
Ашлык тулы келәтләрдә,

Бөтен җирдә шигырь һәм моң
Ургыла, гел ага гөрләп.
Барсын язып алыр өчен
Шагыйрь булу гына кирәк.

*1974-1983*

## КҮЧТӘНӘЧ

Әнкәй күмәч җибәрә
Кем килсә дә авылдан.
Аерылмасын ди микән
Улым туган ягыннан.
Күмәче уңган булыр,
Күпереп торган булыр.
Һәрбер күзәнәгенә
Бер кояш сыйган булыр.
Телем итеп кисәргә
Җитмәс пычак буйлары.
Кулларыңа тотуга
Килер авыз суларың.
Кискән саен яңарыр,
Кыскан саен кабарыр,
Басу исе, кыр исе
Өйләреңә таралыр.
Күчтәнәч ул еркатан,
Чүпрәләре колмактан.
Дару итеп тотарсың
Калган чакта тамактан.
Әнкәй күмәч җибәрә
Кем килсә дә авылдан.
Өзелмәсен ди микән
Балам туган ягыннан.

*1983*

* * *

Сабан туе бара. Ә бер читтә,
Төп мәйданнан шактый еракта
Дуга биеклеге ике малай
Җан-фәрманга көрәшеп ята.
Әле берсе, әле икенчесе
Өскә калкып чыга аларның.
Тик көрәшне туктатмыйлар һаман,
Басмаганнар әле каннарын.
Судья да юк, тамашачы да юк —
Ике малай монда нибары.
Туктап кала алар, берәрсенең
Бушап китсә генә чалбары.
Көрәш кискен. Бүген чишелә, ахры,
Зур бәхәснең каты төене.
Һәрнәрсәнең буладыр, күрәсең,
Үз сәгате суккан үз көне.
Җиңүчегә монда тәкә дә юк,
Кызлар сузмый чиккән яулык та.
Ә шулай да ике малай бүген
Көч сынашып ята таллыкта.
Димәк,

Көрәшчеләр бетми халыкта.

*1983*

## ЯКТЫ ТӘРӘЗӘМ

Туган авылым, якты тәрәзәм син, —
Иң беренче менә синең аша
Күзәттем мин серле җиһан серен
Аяк очларына баса-баса.

Иркен кырым иң беренче тапкыр
Бил алышкан, көч сынаган мәйдан.
Синдә билне ныгытмасам әгәр
Бу гайрәтне алыр идем кайдан?

Авылымның горур, гүзәл кызы,
Яшьлек күгемдәге якты аем.
Мәхәббәткә булган тугрылыкны
Синнән алганмындыр мин, мөгаен.

Тел ачкычын — тирән сер ачкычын —
Син биргәнсең миңа, туган халкым.
Телем якынга да халкым якын,
Халкым якынга да илем якын.

*1983*

## КҮҢЕЛЛЕ МӘШӘКАТЬ

Каршыбызда зур эш бара —
Яшь гаилә өй сала.
Бар да бергә кайнашалар —
Ата, ана һәм бала.
Әй күңелле мәшәкать бу,
Әй күңелле күренеш:
Кешеләрне бер җан иткән,
Бер тән иткән төзелеш.
Һәммә йөздә татулык та
Һәммә йөздә яктылык,
Йомычкалар очып тора,
Шатлык булып, атылып.
Пычкы выж-выж гармун тарта,
Биеп тора балталар.
Биегән чакта балталар,
Кул чабалар такталар.
Чалкан яткан бүрәнәләр,
Ялга яткан батыр күк.
Эшнең гөрләп баруына
Бөтен дөнья шаттыр күк.
Мин дә менә исем китеп
Карап торам аларга —
Тырышамын өй салуның
Хикмәтләрен аңларга.

*1983*

## ЙОМГАК

Кардан йомгак урладым,
Һич аптырап тормадым.
Йомгагым бик дәү булды,
Чыпчыкларга тау булды.

Йомгагыңны сүтәм дип
Һәм чуалтып китәм дип,
Җил тырышты бик озак,
Тик сүтелмәде йомгак.

Эшләр болай бармагач,
Һич тә сүтә алмагач,
Җил өстен салып атты,
Бер хәйлә уйлап тапты:

Алып китмәкче булды
Тәгәрәтеп йомгакны.
«Ах» итте дә «ух» итте,
Әмма билен кузгатты.

Менә шулай бик озак
Сүтелми торды йомгак.
Тиздән җылы яз җитте,
Кар йомгагымны сүтте.

*1983*

## МӨГЕЗ

Бер тәкә мактана икән:
«Менә минем мөгез, — диеп. —
Бормалары сигез, — диеп, —
Сыры йөзгә тигез, — диеп. —

Мин бер сөзсәм, такта ава,
Ике сөзсәм, капка ава.
Өч сөзгәндә, таш ярыла,
Дүрт сөзгәндә, баш ярыла.

Әйе, шәп шул минем мөгез,
Миннән курка хәтта үгез:
Телим икән, мин бит аның
«Эһ» дигәнче алам җанын».

Мактанганда тәкә шулай,
«Һау» дигән икән бер маэмай.
Тәкә куркып сыпырткан, ди,
Мөгезе барын оныткан, ди.

*1984*

## ЧЕЛӘН

Челән килгән безнең күлгә,
Белмим, нинди челәндер.
Нинди булса да, мөгаен,
Безне сагынып килгәндер.

Сыңар тәпиенә басып,
Кузгалмый ул көнозын.
Балыкчы кебек сабыр ул,
Сунарчы кебек түзем.

Үткән-сүткән кешеләрнең
Күзе гел анда гына.
Керә ул камышлыгына
Бары тик ялга гына.

Явыз малайлар да аңа
Таш атмыйлар нигәдер.
Күрәсең, матурлык шулай
Явызлыкны җиңәдер.

*1984*

## СҮЗДӘ ТОРУЧАН КУНАК

Бик сүзендә торучан ул,
Киләм дидеме — килә.
Аның инде бу гадәтен
Барлык кешеләр белә.

Белә һәм көтә зарыгып
Сәгатькә карый-карый.
Бер минут иртә килми ул,
Бер минут соңга калмый.

Килә ул елгалар кичеп,
Килә урманнар аша.
Килә аю-бүреләрнең
Эзенә баса-баса.

Килә, юлларда адашмый,
Бураннарда таба юл.
Без көткәнне белгәнгәме —
Һич соңармый Яңа ел.

*1984*

## БЕЗ БАРСЫН ДА БЕЛӘБЕЗ

Болар әле бик бәләкәй,
Берни белми, димәгез.
Без — замана балалары,
Без барсын да беләбез.
Беләбез, әти соңарса,
Әни тузыначагын:
Безгә тукмак төшәчәген,
Безне кыздырачагын.
Беләбез, әти-әниләр
Яшерен тиргәшсәләр дә,
Без кайткач, берни юк кебек
Ипле сөйләшсәләр дә,
Беләбез бер карау белән,
Бөтенесен беләбез.
Өлкәннәр килешсен өчен,
Елар чакта көләбез.
Әрләшүен без дә инде

Әрләшәбез кай чакта,
Ләкин без бит әрләшсәк тә,
Сугышкалап алсак та,
Бер сәгатьтән дуслашабыз,
Шаярабыз, көләбез.
Кесәдәге конфетларны
Барыбызга бүләбез.
Өлкәннәр тиргәшсәләр,
Озак саклый үпкәсен.
Белми алар моның белән
Безгә кыен итәсен.
Нигә инде аларга да
Безнең кебек булмаска —
Бик тиз генә дуслашмаска,
Конфетлы кул сузмаска?!
Юк шул әле, бу өлкәннәр
Без белгәнне белмиләр:
Бергә-бергә уйнамыйлар,
Бергә-бергә көлмиләр.
Безнең хәтле белсәләрме?
Ул чактамы? Ул чакта —
Әй күңелле булыр иде
Чынлап та бит, чынлап та.

*1984*

## ТАУ СЫРТЫ

Тайның да сырты була,
Тауның да сырты була.
Тайга атланганым бар,
Тауга атланганым юк. —
Ләкин әле тауга да
Бер атланып алырмын.
Болыт-ялга тотынып
Барырмын да барырмын.
Төшмәм, җилләр өрсә дә,
Күзгә кояш керсә дә.
Әйләнермен дөньясын —
Чалбар гына чыдасын.

*1984*

## ТАУ БИТЕ

Кара әле, карагыз,
Тауның бите кызарган.
Оялганмы әллә ул
Шунда йөргән кызлардан.

Әй, юк икән, юк икән,
Сәбәп монда бүтәндә:
Тау битендә кызарып
Җиләк пешкән икән лә.

*1984*

## УРМАН АВЫЗЫ

Безнең урман авызы
Әй зур инде шулчаклы:
Әнә аңа чаптырып
Кереп китте бер атлы.
Анда-монда бармады,
Туктап-нитеп тормады,
«Эһ» дигәнче югалды —
Юлда эз генә калды.
Ул гынамы соң әле! —
Алда әле иң зуры:
Чумды ике машина
Шул авызга туп-туры.
Тырма тоткан апалар,
Чалгы тоткан абзыйлар,
Тубал тоткан малайлар,
Тырыс тоткан кызыйлар
Шунда кереп югалды,
Барсы бергә буталды.
Тик бер куян баласы,
Шикләнепме нидәндер,
Кырга чапты. Ахрысы,
Шул урманның авызына
Койрык сыймас дигәндер.

*1984*

## ЕЛГА КУЛТЫГЫ

Әти белән икәүләп,
Алабайны җитәкләп,
Балыкка киттек кичен.
Сөйләсәң, китәр исең.
Әй бардык без, бардык без,
Бара-бара ардык без.
Кичеп чыктык болыннар,
Кешнәп калды колыннар.
Шулай бара торгачтын,
Арыгачтын, талгачтын —
Елга култыгы таптык,
Таптык та шаклар каттык.
И андагы матурлык!
Бетәрме сөйләп кенә.
Юри җыйган шикелле
Су тулы үрдәк кенә.
Йөзүләре дисеңме,
Чумулары дисеңме!
Шаярышып, бер-берсен
Куулары дисеңме!
Әйе, әйе, шыттырмыйм,
Шәп иде култыгыбыз.
Ләкин өйдә онытылып
Калган шул мылтыгыбыз.
Әгәр мылтык булсамы?
Әти корып торсамы?
Үрдәкләр яр буенда
Тезелеп утырсамы? —
Атып җибәрер идек,
Тормас идек төзәп тә:

Тияр иде берьюлы
Кимендә ун үрдәккә,
Ә тимәсә, дисезме?
Тимәсә соң — тимәсен.
Мин барыбер яратмыйм
Майлы үрдәк өйрәсен.
Миңа тик балык булсын,
Ялт та йолт кабып торсын.
Койрык болгап янымда
Алабай чабып торсын.
Ә бу юлы балыкны
Каптырдык соң, каптырдык:
Көймә буе җаенне
Ярга сузып яткырдык.
Ышанмыйсыздыр әле,
Алай булмас, дисездер.
Бер баруда шулхәтле
Юллар уңмас, дисездер.
Әйе, мин бит балыкчы,
Бераз гына арттырдым.
Ә дөресен әйткәндә,
Бер маймычны каптырдым.

*1984*

## БЕР ГЕНӘ

Ничек без уйламыйк
Туар көн турында,
Ничек без уйламыйк
Узар юл турында.

Ничек без тукталыйк,
Ничек без бирешик?
Явызлык белән без
Ничек соң килешик? —

Бер гомер бирелгән
Сиңа да, миңа да.
Бер гомер, бер яшәү —
Һәркемгә дөньяда.

Без кемнәр булсак та,
Кайларда тусак та,
Син миннән, мин синнән
Еракта торсак та,

Ничек без тын торыйк,
Бомбалар атканда,
Мылтыклар йөрәккә
Төзәлеп ятканда —

Син дә бит бер генә,
Мин дә бит бер генә.
Бергәләп яшисе
Җир дә бит бер генә.

*1984*

## ИНДЕ ТАНЫП АЛГАНСЫЗДЫР

Борыны аның кызыл булыр,
Үткән юлы озын булыр,
Аркасында капчык булыр,
Күчтәнәче тансык булыр.
Клубларга кереп чыгар,
Мәктәпләргә кереп чыгар,
Һәр кешегә капчыктагы
Күчтәнәчен биреп чыгар.
Сакалына карлар кунар,
Керфегенә нурлар кунар,
Аны күргәч, күңелләргә
Сөенеч һәм шатлык тулар.
Юмарт булыр, бик бай булыр,
Әйткән сүзе бал-май булыр.
Инде танып алгансыздыр —
Әйе, бу — Кыш бабай булыр.

*1984*

## БӨТЕНЕСЕ КИРӘК

Кирәк безгә, бөтен нәрсә кирәк.
Комсыз булмасак та чынында без.
Бер баласы бит без табигатьнең,
Гомер буе аның кулында без.

Кирәк безгә ишелеп аккан болыт,
Хыялларда ерак китәр өчен.
Кирәк безгә зилзиләле давыл,
Егылмаслык көчле итәр өчен.

Аяз күкләр, якты кояш кирәк,
Күңелебезгә аклык салыр өчен.
Очы күренмәгән юллар кирәк,
Өметләнеп алга барыр өчен.

Ярсу елга, шаулы диңгез кирәк,
Дулкыннары җанга күчсен өчен.
Сокландыргыч гөлбакчалар кирәк —
Сөю чәчәкләре үссен өчен.

Биек ярлар, текә таулар кирәк,
Үҗәтләнеп өскә менәр өчен.
Алсу таңнар, зифа таллар кирәк,
Яшерен серебезне сөйләр өчен.

Табигатьтә берни артык түгел,
Табигатькә кирәк бөтенесе:
Караңгы төн, озын кышкы кичләр,
Зәһәр салкын, түзалмаслык эссе.

Төшенмәслек тирән серләр кирәк,
Зиһен кылычларын чарлар өчен.
Кирәк безгә бар да, үзебезнең
Кеше икәнлекне аңлар өчен.

*1984*

## УЛ БЕЛМӘГӘННЕ БЕЛӘ

Гөлгенәнең әнкәсе
Ни тотса да булдыра:
Уа, юа — ялт иттерә,
Ипи салса — уңдыра.

Чигә, бәйли, кисә, тегә
Йә үтүкли, йә эрли.
Бөтен эшне дә белә ул,
Тик тора гына белми.

Ә Гөлгенә? Гөлгенә
Ул белмәгәнне белә.

*1985*

## ТЕЛ АЧКЫЧЫ

Алай итеп карадым,
Болай итеп карадым,
Камиләне барыбер
Сөйләштерә алмадым.

Конфет бирдем — суырды,
Алма бирдем — ашады.
Бары шуннан соң гына
Теле ачыла башлады.

Бүген ачкыч табылды —
Конфет, алма ярады.
Тик һәр көнне «ачкыч»ның
Кирәк башкачарагы.

*1985*

## КӨЗГЕ ТАБЫН

Көзге табын — бай табын,
Кыяр, карбыз һәм кавын
Телем-телем теленгән,
Өем-өем өелгән.

Алмалары ал төсле,
Балкып туган таң төсле.
Капсаң, эри авызда,
Һәр кисәге бал төсле.

Ә җимеше, җимеше,
Ачысы бар, төчесе!
Яңа пешкән күмәчтер
Кайнар кояш төслесе.

Әткәм кебек тырыш көз,
Әнкәм кебек юмарт көз.

Күзләр юмарт булганга,
Бик бәхетле, бик шат без.

*1985*

## ШАККАТУ

Алдым мин буяу,
Алдым пумала
Һәм чыгып киттем
Капка буярга.
Әй буйыйм, малай,
Карамыйм артка.
Ялт итсен әле
Безнең дә капка.
Алай иттердем,
Болай иттердем.
Менә бермәлне
Буяп бетердем.
Бабай шаккатты,
Әби шаккатты,
Әти шаккатты,
Әни шаккатты.
Менә кич җитте,
Көтүләр кайтты:
Кәҗә шаккатты,
Сарык шаккатты.
Хәзер үзем дә
Шаккатып торам:
Булдырам икән,
Тотсам... булдырам.
Хәзер сезгә мин
Бер серне чишим:
Бу әле минем
Беренче эшем.

*1985*

## МИН АНДЫЙ МАЛАЙ ТҮГЕЛ

Ялкау малай, диләр мине,
Белмиләр алар берни:
Ялкау түгел мин,
Бары тик
Укыйсым гына килми.

Тәртипсез, дип тә әйтәләр,
Эч поша шуңар менә.
Тәртипле мин,
Минем бары
Тик тормый куллар гына.

Хыяллана белмисең, дип
Тиргиләр кайчагында.
Әйтсәм әйтим: бу сүзләргә
Ачу килә тагын да.

Укымый галим булырга
Кем хыяллана? — Мин ул!
Эшләми дан казанырга

Кем хыяллана? — Мин ул.

И-и, әгәр саный китсәң
Хыялларымның барсын.
Хыялый дияр идегез —
Белеп торам мин ансын.

Күккә очам, суда йөзәм,
Сикереп менәм атларга...
Тагын әллә ниләр уйлыйм
Иренмәгән чакларда.

*1985*

## ЕЛГА МОНОЛОГЫ

Җәйләр агам, кышлар агам,
Айлар агам, еллар агам.
Ага-ага ерак китәм,
Таулар күрсәм, урап үтәм.

Суырталар суларымны,
Саегамын эсселәрдә.
Саексам да, ялыксам да,
Үпкәләмим кешеләргә.

Чөнки язлар килгән саен
Өр-яңадан гайрәтләнәм.
Ярларыма сыймый башлыйм,
Юмартланам, әйбәтләнәм.

Сокландырам, сөендерәм,
Коендырам, туендырам.
Куеныма никадәрле
Җан иясен сыендырам.

Бирешмим мин суыкларга,
Бирешмим мин эсселәргә.
Минем үлемем — пычрануда,
Белсен шуны кешеләр дә!

*1986*

## РӘНҖЕМӘСЕН

Тезелешеп очкан кыр казлары
Чагылып китсә әгәр офыкта,
Кемдер карый кулын кашына куеп,
Кемдер — бармак салып курокка.
Кош-кортларга кемдер җимнәр куя
Һәм ышыклый зәһәр суыктан.
Ә кемнәрдер читлек элеп куя,
Үреп каты тимерчыбыктан.
Кемдер чишмәләрнең юлын ача,
Ә кемнәрдер китә томалап.
Дөнья бит бу, ә дөньяда инде
Төрле хәлләр тора булгалап.
Табигать ул үзен яклый алмый,

Үч тә ала алмый кешедән.
Ул бары тик рәнҗи генә ала,
Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.
Рәнҗемәсен безгә очар кошлар,
Рәнҗемәсен күлләр, урманнар.
Рәнҗемәсен кояш, җир һәм күкләр,
Рәнҗемәсен безгә ал таңнар.
Рәнҗемәсен, үзенең яклаучысы
Кеше икәнлекне белсен ул.
Яңгырлары белән еласын да
Кояшлары белән көлсен ул.

*1986*

## ҖЫР БАШЫ

Яшел кара белән язды шагыйрь,
Һәр сүзендә аның наз иде.
Укыдылар бу шигырьне һәркем,
Ә шагыйрьнең исеме яз иде.

Нота язды яшен бу шигырьгә,
Һәм яфраклар аны җырлады.
Дәртле җилләр дирижерлык итте,
Башын иеп, дөнья тыңлады.

Күңелләрдә ярсу елга булып
Әллә нинди якты нур акты.
Кошлар каурыеннан моңнар тамды,
Ак болытлар булып җыр акты.

Шушы җырда, гади генә җырда,
Күпме көч бар, күпме ашкыну!
Кырда иген булып шаулаячак
Җәйге симфониянең башы бу.

*1986*

* * *

Яз килә, боз сөңгеләрен
Төбәп кышның күкрәгенә.
Аждаһа йоткан диярсең —
Елгалар гел үкерә генә.

Туп ата бозлар шарт та шорт,
Ядрәләр ярга сибелә.
Кышның гаскәре кырлардан
Урманга таба чигенә.

Кырлар әсирлектән котылып,
Күкрәкләрен тутырып сулый.
Үтәләр кошлар һавадан,
Кулъяулыклар болгый-болгый.

*1986*

## ҖИР ӨСТЕНДӘ ҖИЗ КЫҢГЫРАУ

Җир өстендә җиз кыңгырау,

Чың-чың итә тавышы;
Анда җирнең шатлыгы һәм
Анда җирнең сагышы.

Аңа тия җил иссә дә,
Күкләр куйса да күкрәп.
Һәр тавышка сискәнә ул
Һәм китә тетрәп-тетрәп.

Тоташкан аның теленә
Дөньяның бар җепләре:
Юллар, сулар, урман, кырлар,
Ай-йолдызлы күкләре.

Сизә йолдыз атылса да,
Көне-төне ул уяу.
Җир өстендә мәңге сакта
Кеше — сизгер кыңгырау.

*1986*

## ТӨНГЕ МАҖАРА

Йоклый алмый ята идем,
Тәрәзәдән ай керде.
Тәрәзәдән ай керде дә
Миңа бер дару бирде.

Ул даруны кулга алып
Эчим генә дигәндә,
Тәгәрәде дә учымнан
Төште-китте идәнгә.

Идәндәге ул даруны
Бер тычкан барып тотты.
Бер тычкан барып тотты да
Һам итеп кабып йотты.

Шундук гырылдый-гырылдый
Йокыга китте тычкан.
Ул тавышка йөгерә-йөгерә
Мәчебез керде тыштан.

Әлбәттә инде, мәчебез
Озак тормады уйлап —
Бу тычканны кабып йотты,
Һәм ул да китте йоклап.

Шуннан соң нәрсә булдымы? —
Әйтә алмыйм анысын.
Мин дә йоклап киткәнмен шул,
Йоклаткачтын барысын.

*1987*

## КАЛЫР ИДЕМ

Көннәр — канатлы ат,
Томырылып чаба.
Тотып алып йөгән
Кидереп булмый аңа.
Тотып булса, йөгереп
Каршы чыгар идем.
Иң бәхетле көнне
Бәйләп куяр идем.
Йә атланыр идем
Тотынып ялларына.
Барып карар идем
Килер таңнарыма.
Арсам, талсам да, мин
Төшмәс идем бер дә:
Калыр идем мәңге
Иң бәхетле көндә.

*1987*

## ҮСЕП КЕНӘ ҖИТИМ ӘЛЕ

Балтасыз һәм пычкысыз,
Өтергесез, ышкысыз
Өй сала беләмен мин.
Бәлки әле, көләсездер,
Ялган сөйли диясездер —
Юк, ялган сөйләмим мин.
Өйне бик матур салам,
Күргәннәр хәйран кала —
Молодец, Зөлфәт, диләр.
Балтасыз да, тактасыз да
Менә шундый өй салырга
Безне дә өйрәт, диләр.
Өйрәтермен — килегез,
Тик сез шуны белегез:
Минем өем шырпыдан.
Тик шырпыдан булса да ул,
Сыңар учка сыйса да ул,
Ким түгел чын йортыңнан.
Ә үскәчме, үскәчме,
Егет булып җиткәчме?
Салырмын мин чын өйләр.
Анда торыр әбиләр дә,
Анда торыр әниләр дә
Һәм тагын әллә кемнәр.
Мәчегә һәм эткә дә,
Кәшәкә һәм тупка да
Ул өйдә булыр урын.
Үсеп кенә җитим әле,
Барыбызга да җитәрлек
Салырмын өйнең зурын.

*1987*

## ПЫЧРАК

Пычрак әйтә икән:
— Мин бит шундый нәрсә,
Юлда ятам да мин

Иярәм кешеләргә.

Ябышам итекләргә,
Ябышам читекләргә.
Чәчрим йөзләренә,
Чәчрим күзләренә.

Кайчак егылалар
Килеп минем өскә.
Миңа егылганнар
Керә минем төскә.

Мине читләп үтү
Җиңел түгел бер дә.
Мин сагалап ятам
Иң көтмәгән җирдә.

Мин һәрвакыт сизгер,
Мин һәрвакыт уяу.
Шундый кызык нәрсә —
Кешеләрне буяу.

*1987*

## ШӘП КОРАЛ

Әти гармунда шәп уйный,
Әни уйный арфада.
Кемне алма — музыкантлар
Безнең өйдә барсы да.

Апам сыңар бармак белән
Пианино чирттерә.
Энем, барабанын кагып,
Өйне дер-дер иттерә.

Ә мин уйныймын кашыкта,
Шәп корал бит ул кашык:
Мин ашарга утырдыммы,
Авыз итә шап та шоп.

*1988*

## НӘРСӘГӘ?

Алтын әйберләр нәрсәгә?
Яшереп саклар өчен.
Матур китаплар нәрсәгә?
Соң, тузан каплар өчен.

Бәллүр савытлар нәрсәгә?
Шкафта тотар өчен.
Йомшак диваннар нәрсәгә?
Астында йоклар өчен.

Ә пианино нәрсәгә?
Гел ябык торыр өчен.
Идәндә келәм нәрсәгә?
Чит-читләп йөрер өчен.

Тәмле ризыклар нәрсәгә?

Бозылгач ашар өчен.
Безнең матур өй нәрсәгә?
Урамга качар өчен.

*1988*

## СӨЕНӘ БЕЛӘСЕҢМЕ?

Тормыш шатлык кына түгел,
Күрәсең күрәсеңне.
Яшең барында күзеңдә,
Өмет сүндерми үзеңдә,
Сөенә беләсеңме?

Үзеңне ашаткан җиргә
Көн дә бер иеләсеңме?
Кояш елмаеп көлгәнгә,
Гел тыныч көннәр килгәнгә
Сөенә беләсеңме?

Барган саен максатыңа
Якынрак киләсеңме?
Алга киткән һәр адымга
Рәхәтлек тоеп җаныңда
Сөенә беләсеңме?

Кеше елаганда елап,
Көлгәндә көләсеңме?
Кешегә кылган шәфкатьтән
Зур ләззәт алып, табып тәм,
Сөенә беләсеңме?

Беркем дә мәңгелек түгел,
Белсәң дә үләсеңне —
Яшәлгән һәрбер көнеңә,
Үстергән һәрбер гөлеңә
Сөенә беләсеңме?

*1988*

## МЕНӘ ШУНДЫЙ ХЫЯЛЛАР

Әнисе камыр баса.
Фәннүр аның янында
Бөтерелә, сөйләнә —
Хыял аның җанында.

Әни, ди, бу камырны
Кабат-кабат яңартсаң;
Кабат-кабат яңартып
Озак-озак кабартсаң,

Нишләр иде, әйтимме?
Ташыр да ташыр иде.
Ташый торгач, бермәлне
Кухняны басар иде.

Кухняга сыялмагач,
Зур якка күчәр иде.
Зал да тулгач, балконнан
Урамга төшәр иде.

Ә аннары, аннары
Урамны басар иде.
Йорт, кибет һәм мәктәпләр
Камырга батар иде.

Урамда машиналар
Йөри алмаслар иде.
Камырны дворниклар да
Көри алмаслар иде.

Ул чагында мәктәптә
Укулар булмас иде.
Укытучылар безгә
Икеле куймас иде.

...Шундый хыяллар уза
Фәннүр күңеле аша.
Әнисе улын тыңлап
Елмаеп камыр баса.

*1988*

## УЗАР ИДЕМ

Дамир укуда беренче,
Сабир спортта көчле.
Әни әйтә, нигә син дә
Түгел соң шулар төсле?!

Рәфис эшчән дип мактала,
Вил ярдәмчел, янәсе.
Кайсы да булса бер яктан
Алдын алар һәммәсе.

Эһ тә итми узар идем
Мин боларның барысын,
Әгәр ачып җибәрсәләр
Ялкауларның ярышын.

*1988*

## ТЫҢЛАУСЫЗ ТУП

Бу туп минем әллә нинди
Бик тыңлаусыз туп булды.
Бер китереп типкән идем,
Үпкәләде, юк булды.

Көчкә эзләп табып аны
Типтем тагын капкага —
Барып төште тәртипсез туп
Күршедәге бакчага.

Ул бакчада агач саен
Алмалар пешкән иде.
Кайберләре туп янына
Өзелеп төшкән иде.

Туп алырга кергән җирдән
Күз төште алмаларга —
Туры килде берничәсен
Кесәгә салгаларга.

Тәртипсез туп тагын мине
Оятлы итте менә —
Барып төште бер апаның
Кыярлы түтәленә.

Тупны алып чыккан чакта,
Өзелгән бит кыяр да...
Ничек инде түзеп торыйм? —
Ачу килде моңарга.

Шул ачудан бар көчемә
Китереп типтем тупка:
Очты тубым зәңгәр күккә,
Очты тубым болытка.

Һавада очып арыгач,
Төшәр дисәм алдыма —
Чумды тубым кинәт кенә
Ят бер ишегалдына.

Сикердем үзем дә шунда,
Кагып тормадым капка.
Ә анда, мин сиңа әйтим,
Бозау хәтле эт ята.

Авызына, һич алдаусыз,
Туп та, мин дә сыярлык.
Ә тешләрен казык итеп
Җиргә кагып куярлык.

Телен инде әйткән дә юк —
Билне биш кат урарлык.
Мине түгел, җиде башлы
Аждаһаны буарлык.

Ята туп шуның алдында,
Ә мин — ике адымда.
Иң-иң матур сүзләр әйтеп
Басып торам янында.

Син әйбәт, дим, син матур, дим,
Син дөньяда тиңсез, дим.
Мин үзем дә әйбәт малай,
Тубым гына юньсез, дим.

Әгәр инде кирәк икән,
Тупны сиңа бирәм, дим.
Тик, абзыкай, мине генә,
Зинһар өчен, җибәр, дим.

Юк, җибәрми, кузгалдыммы,
Авызын ачып «ыр-р-р» итә.
Ул «ыр-р-р» итсә, буыннарым
Минем кинәт дер-р-р итә.

Инде шушы эт авызына
Авам бугай дигәндә,
Әҗәлемне менә шунда
Табам бугай дигәндә,

Кайтып керде хуҗа абзый
Һәм үлемнән коткарды.
Тупны да алып тормадым,
Эт янында туп калды.

Әйдә калсын, һич кызганмыйм,
Бик тәртипсез туп иде.
Туп булмагач, бакчаларга
Минем кергән юк инде.

*1988*

## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕНДӘ

Әй ачу чыкты абыйга —
Шундый иртә торган ул.
Мин торганчы бөтен эшне
Бетергән дә куйган ул.
Утыннар да кисеп керткән,
Ишегалдын көрәгән.
Аның күпме эшләгәнен
Әнием дә күрмәгән.
Әнием мактый абыйны,
Әй уңган, улым, син, ди.
Бөтен эшкә өлгергәнсең,
Минем уң кулым син, ди.
Ә абыем рәхәтләнеп
Көлеп тора бер читтә.
Көл әйдә, көл, синнән әле
Үч алырмын ничек тә.
Әниләр бәйрәме тагын
Килеп җитәр бер елдан.
Шул чакта күрерсез менә —
Кем өлгер дә кем уңган.

*1989*

* * *

Урман — колак, кыр — күз,
Шулай булган элек:
Урман-кырлар барсын
Торган ишетеп, күреп.
Бермәлне без кинәт
Иркенлеккә чыктык:
Урман колагына
Балта белән суктык.
Чукракланды урман,
Ишетмәде берни.

Бульдозерлар анда
Йөрде бии-бии.
Химиябез белән
Сукырайттык кырны,
Соңгы тургай белән
Җиргә күмдек җырны.
Сукыр, чукрак иткәч
Урман-кырыбызны,
Сагына башладык без
Күмгән җырыбызны.
Күмелгән җыр, белмим,
Шытар микән кабат.
Ыңгыраша урман,
Безнең күзгә карап.

*1989*

## КАЛӘМ ЭЗЛИМ

Язар өчен каләм эзлим,
Сайлыйм елга камышларын.
Ул камышлар сөйләр миңа
Елгаларның агышларын.
Эзлим былбыл кунганнарын,
Эзлим дулкын юганнарын.
Эзлим җилдә сынганнарын,
Эченә моң тулганнарын.
Эзлим давыл күргәннәрен,
Яшеннәрдә көйгәннәрен.
Уйда башын игәннәрен,
Яшәү серен белгәннәрен.
Язар өчен каләм эзлим,
Сайлыйм аккош каурыйларын,
Ул каурыйлар сөйләп бирер
Аккошларның сагынуларын.
Алам ялгыз ятканнарын,
Илләр урап кайтканнарын.
Алам суга акканнарын,
Алам канга батканнарын.
Язар өчен каләм сайлыйм —
Төрле, төрле, төрлеләрен.
Табигатьнең үзе кебек
Гамьлеләрен, серлеләрен.

*1989*

## ГӨЛЛӘРЕМ

Бирде әнкәм
Өч хәзинә,
Өч саф гөл:
Берсе — гомер,
Берсе — исем,
Берсе — тел.

Әйтте миңа:
Гөлләремне
Шиңдермә.
Гөлсез дөнья

Тәрәзәсез
Бер төрмә.

Чыгып киттем
Олы юлга,
Ашкынып.
Барган саен
Арта барды
Каршылык.

Авызым ачсам
Тибрәтим дип
Телемне,
Җилләр бәрде
Алмак булып
Өнемне.

Күкрәде күк,
Очты яшен
Уклары:
Гомер гөлен
Телде яшен
Утлары.

Теләп җирдән
Исемемне
Җуярга,
Ташкын булып
Акты сулар
Юлларга.

Ялкын эчеп,
Ташу кичеп
Атладым.
Әнкәм биргән
Гөлләремне
Саkладым.

*1989*

## ӘНКӘСЕ БЕЛӘН УЛЫ

— Дөмбер-дөмбер кем йөри?
— Дөмбер-дөмбер җил йөри.
— Ник кага ул калайны?
— Чакыра бер малайны.
— Ә ул малай ник чыкмый?
— Малай дәресен укый.
— Дәресен укыр соңыннан...
— Юк, юк, улым... Җил тынган.

*1989*

## ИКЕ ДӨНЬЯ — ИКЕ ЕЛГА

Шулай язгандыр күрәсең —
Яшим ике дөньяда.
Әйтерсең бер үк вакытта

Коенам ике елгада.
Батам-калкам, батам-калкам,
Ташланам ярдан ярга.
Бөтереләм чоңгылларда,
Кыйналып дулкыннарда.
Бер дулкын чөя югары,
Бер дулкын китә күмеп.
Яшимен бер көн эчендә
Мең терелеп, мең үлеп.
Елгамның берсе болганса,
Берсе чистарып кала;
Берсе батырган чагында
Берсе коткарып кала.
Ике дөньям — ике елгам
Беткән бергә чорналып.
Берсе шигърият дөньясы,
Икенчесе — чынбарлык.

*1989*

## ЧЕРКИ

Черки әйткән: «Бу дөньяда
Миннән батыр беркем юк.
Һичкемнән дә курыкмыйм мин,
Башым — калкан, борыным — ук.
Телим икән, аюларның
Бер колагыннан кереп
Икенчесеннән чыгамын,
Башында очып йөреп.
Бүреләрнең борынын тешләп
Каната аламын мин.
Боланнарның маңгайларын
Кабарта аламын мин.
Теләсәм, арысланнарны
Үрле-кырлы сикертәм.
Җитезләрне егып салам,
Ялкауларны йөгертәм».
Менә шулай бик мактанып
Утыра икән черки —
Бер кош моны кабып йоткан,
Ачуы чыккан чөнки.

*1989*

## КЫЗ ҺӘМ КРАН

Нәни бер кыз, авыру бер кыз
Тәрәзәдән карап тора.
Яңак буйлап аккан яшен
Теле белән ялап тора.

Тышта аның яшьтәшләре
Көлә, уйный — килә чыр-чу.
Йөзләренә кояш капкан,
Җаннарында юк бер борчу.

Өй каршында кран эшли,
Бик зур кран, көчле кран.
Өсләренә менеп бассаң,
Күренәдер бөтен урам.

Пышылдый кыз: «Кран, кран!
Алчы мине бишегеңә;
Тәрәзәдән кереп була,
Сыялмасаң ишегемә.

Күтәр мине биек-биек,
Ап-ак болыт өсләренә.
Кереп китик ак шәһәрнең
Ак йолдызлы кичләренә.

Юллар нинди, йортлар нинди,
Шәһәрдәге утлар нинди? —
Күрсәтерсең миңа барсын,
Әкият итеп сөйли-сөйли».

Кран әйтә: «Ярый, ярый,
Хәзергә күп ләкин эшем.
Эшем беткәч, бишегемә
Утыртырмын сине кичен».

Вәгъдәсендә тора кран —
Кич җитүгә, тәрәз чиртә:
«Әйдә, дустым, тотын миңа,
Алып менеп китәм күккә».

Күтәрә дә кызны кран
Бик сак кына, иплә кенә
Тирбәтә ак бишегендә,
Матур көйләр көйләп кенә.

Кызга рәхәт, шундый рәхәт,
Кошлар куна иңнәренә.
Оча, оча битен куеп
Җәйнең ефәк җилләренә.

Җирдә утлар, күктә утлар —
Бөтен дөнья сихри, серле.
Җирләр белән күк тоташкан,
Аерып булмый күктән җирне.

Бик-бик озак тирбәлә кыз
Көчле дусты кочагында.
Керә өйгә таң кабынгач
Офыкларның учагында.

Тынычлана кызның җаны,
Йоклый төшләр күрә-күрә.
Ай, йолдызлар биешәләр,
Тәрәзәдән керә-керә.

*1989*

## ШУНДА МӨНИП КИЛЕП ЧЫККАН

Бәхәсләшеп киткән кызлар,
Нәрсә, диеп, иң кыен эш.
Бу сорауга җавап табу
Түгел икән бик уен эш.

Бер кыз әйткән: «Иртән тору!»

Икенчесе: «Чәчне тарау!»
Өченчесе: «Дәрес уку!»
Дүртенчесе: «Бала карау!»

Шунда Мөнип килеп чыккан
Һәм кызлардан шыр-шыр көлгән.
Иң кыен эш — кызлар күргәч
Үртәшмичә калу, дигән.

*1989*

## КАР ӨСТЕНДӘ КАРА МӘЧЕ

Кар өстендә кара мәче
Атлап бара вак-вак кына.
Кара итек, кара тунын
Кар тиюдән саклап кына.

Тәпиенә кар ябышса,
Тәпиләрен селкеп тора.
Мыегына кар ябышса,
Эрегәнен көтеп тора.

Кар өстендә кара мәче,
Дөнья бик тә гаҗәп аңа:
Кап-кара итекләреннән
Карда ап-ак эзләр кала.

*1989*

## ӘГӘР ИНДЕ ӨЧ ӨРСӘ

Ай-яй-яй-яй, җил көчле,
Әкияттәге җен төсле:
Бер өрсә, буран куба,
Кар белән урам тула.

Ике өрсә әгәр дә,
Мәхшәр куба шәһәрдә:
Бар нәрсә канатлана,
Очарга яраклана.

Өч өрсәме, өч өрсә,
Иртән, көндез, кич өрсә,
Бусы җен туе була,
Ул туй төн буе була.

*1989*

* * *

Бозның борыны җебегән,
Әллә язгы җил бәргән.
Сакланырга кирәк шул
Урамдагы җилләрдән.

Менә мин гел сакланам,

Чыкмыйм андый көннәрдә.
Курчагымны өйрәтәм
Шигырь, әкият сөйләргә.

Бозның борыны җебегән,
Ярый грипп булмаса.
Җебемәс иде борыны,
Әгәр әнисен тыңласа.

*1989*

## ЫЧКЫНДЫРМАМ, ЧЫДАРМЫН

Мин урамга чыктым исә,
Кояш кача каядыр.
Өйгә керсәм, килеп чыга,
Ачу килә аңар гел.

Әллә соң ул минем белән
Качышлы уйный микән?
Кая качканын күрмичә
Калыр дип уйлый микән?

Юк инде, алайга китсә,
Мин дә кызык итәрмен:
Өйгә кергән булырмын да
Качып кына көтәрмен.

Чыгарсың, чыкмый калмассың,
Тотып алырмын шунда.
Сине бераз тотып торсам,
Җылынып китәр кул да.

Бәлки әле, бик ошасаң,
Куенга да тыгармын.
Яндырсаң да, көйдерсәң дә,
Ычкындырмам, чыдармын.

*1989*

## ИҢ КӨЧЛЕ ДАРУ

Бер елак кыз булган, ди,
Гел-гел елап торган, ди.
Елар өчен ул һәрвакыт
Сәбәп эзләп торган, ди.

Елаган яңгыр яуса да,
Кояш чыкса да балкып,
Елаган ул көне-төне,
Һич булмаган туктатып.

Докторлар да елак кызга
Дәва таба алмаган:
Елаган да елаган ул,
Елаган да елаган.

Йокламаган бөтен авыл
Елак кыз аркасында.

Йоклап кына киттеләрме —
Уяткан барчасын да.

Менә беркөн бу кызларга
Бер әкиятче килгән, ди.
Елак кызга бик-бик матур
Әкият сөйләп биргән, ди.

Шуннан соңмы? Шуннан соң
Кыз елаудан туктаган.
Ул туктагач, бөтен авыл
Өч көн, өч төн йоклаган.

Тавыклар да йоклаганнар,
Әтәчләр дә йоклаган.
Сыер-сарыклар да йоклап
Көтүенә чыкмаган.

Шулай, дуслар, сүзләрем чын,
Әкият бит ул — тылсым.
Яхшы әкият бар чагында,
Дару бер якта торсын.

Сүзләремнең хаклыгына
Ышанмасагыз бер дә,
Әкиятләр укып карагыз
Елыйсы килгән көндә.

Онтырсыз шунда барсын да —
Дөньягыз матураер.
Ямьсезләр гүзәл булырлар,
Куркаклар батыраер.

Чирлеләр чирдән арыныр,
Нәниләр үсеп китәр.
Чынлап, дуслар, әкият сезне
Бик-бик бәхетле итәр.

*1989*

* * *

Котырды җил, котырды,
Агачларны сындырды,
Түбәләрне кубарып
Әллә кая тондырды.
Күзне ачсаң, чүп атты,
Бүрекне алып чапты.
Оясында йоклаган
Каргаларны уятты.
Бөтен дөнья шаулады,
Өйләр чак-чак аумады.
Ләкин хулиган җилне
Беркем тыя алмады.
Шул чагында бер кошчык
Килде дә җил-җил очып,
Үзенчә нидер әйтте,
Искән җилне туктатты.
Алай булмас дисезме?
Җил тиз тынмас дисезме? —
Кайчак бер сүз җитә бит,
Көйләр өчен көйсезне.

*1989*

## ИҢ ИРТӘ

Иң-иң иртә кем тора? —
Иң иртә әнкәй тора.
Без торганчы өстәлдә
Коймак белән чәй тора.

Иң-иң соңлап кем ята? —
Иң соңлап әнкәй ята.
Үз йокысын биреп ул
Безне күбрәк йоклата.

*1989*

## ӘБИ, БАБАЙ РӘХМӘТ ӘЙТӘ

Безнең өй егерме катлы,
Бик ерактан күренеп тора.
Түбәсендә антенналар
Болытларга үрелеп тора.

Безнең өйгә килсә әгәр
Таныш түгел әби, бабай,
Шаклар катып карап тора,
Биек, диеп, бу йорт, ай-һай.

Андыйларга мин һәрвакыт,
Курыкмагыз, курыкма, дим.
Сезгә ярдәм итешергә
Мин бар әле бу йортта, дим.

Кемгә кайсы катка кирәк —
Әйтсен генә — карышмыйм һич:
Алып менеп китәм өскә,
Бар ул бездә гайрәт һәм көч.

Күтәрешәм, төшерешәм —
Аска-өскә ташып торам:
Лифт дигән машинаның
Кнопкасын басып торам.

Әби, бабай рәхмәт әйтә,
Миңа рәхәт — авыз ерык.
Космоска ук илтер идем,
«Космос» дигән кнопка юк.

*1990*

## ӘТИ ЭЗЕ

Сыртын угалап
Күрсәтә Таһир:
— Менә монда, — ди, —
Әти суккан җир.

— Әти суккан җир

Нинди була? — дип
Кызыгып карый
Аңарга Мөнип.
*1990*

## КЫСКА ВАКЫТЛЫ ЯҢГЫР

Быелгы җәй күңелемдә,
Ахрысы, шулай калыр:
Сибәләде дә китте гел
Кыска вакытлы яңгыр.

Тауны тауга тоташтырды
Салават күпере — җәйгор.
Кояшка кушылып яуды
Кыска вакытлы яңгыр.

Күл буйларында бакалар
Туктамый суздылар җыр.
Гөлләрнең битләрен юды
Кыска вакытлы яңгыр.

Сизелми дә үтте бу җәй,
Калды тик эчтә бер нур.
Әллә балачак булды бу,
Әллә кояшлы яңгыр.

*1990*

## КАРГАЛАР КҮТӘРЕП КИТӘР

Телең булмаса, күптән
карга күтәреп китәр иде.

*Халык сүзе*

Ничә гасыр баш өстендә
Козгыннар һәм каргалар.
Өер-өер очып йөри
Каркылдашып кар да кар.

Көтеп йөри алар безнең
Телсез калуыбызны —
Карга өереннән куркып
Өнсез калуыбызны.

Телсез калгач, алар бик тиз
Күтәрепләр китәрләр.
Аннары безне дә шулай
Кара карга итәрләр.

Очарбыз без дә каркылдап,
Онтып кемлегебезне.
Йолкырлар туган җирләрдән
Шулай кендегебезне,
Җуйсак без телебезне.

*1990*

## ОЧА ТОРГАН ЧӘЧӘКЛӘР

Әй күп безнең бакчада
Төрле-төрле чәчәкләр.
Алар бар да матурлар,
Алар бар да бик шәпләр.

Кайсы кызыл, кайсы ак,
Кайсы боек, кайсы шат.
Җыеп алсаң һәммәсен,
Булыр иде ун кочак.

Чәчәкләрнең бар хәтта
Очып йөри торганы.
Түтәлләрдән түтәлгә
Күчеп йөри торганы.

Кайчагында шуларны
Җыймак булам чүгәләп.
Ләкин чәчәк дигәнем
Булып чыга күбәләк.

*1990*

## БАРСЫНА ДА ҖИТӘ

Мәхшәр ишегалдында —
Уйный бала-чагалар.
Бетсәләр дә әлсерәп,
Туктамыйлар, чабалар.

Кайчагында көтмәстән
Бәхәскә керешәлер:
Тарткалап та йолыккалап
Нәрсәдер бүлешәләр.

Киң булса да шулкадәр,
Җитми ишегаллары.
Чыга алар урамга —
Шунда тарта җаннары.

Әгәр инде күрсәләр
Нәни генә күлдәвек,
Барсына да шул җитә,
Бар да бата билдән үк.

*1990*

* * *

Үтте сызылып җәйге яшен,
Әйтте миңа: «Мине тот.
Шигыреңә ут кирәкме? —
Миндә дәһшәт, миндә ут».

Тамды комга язгы тамчы,
Әйтте миңа: «Эзләп тап.
Комнан тамчы табалмасаң,

Каләмеңне читкә ат».

Какты ярга ярсу дулкын,
Әйтте миңа: «Иярлә!
Каушап калсаң, хакың юктыр
Мин шагыйрьмен дияргә».

*1990*

## АТЛАР ЧИШМӘСЕ

Мине шулай атыйлар —
Исемем «Атлар чишмәсе».
Суым акмый улактан
Таш аралап эчәсе.

Имеш, бер шәп тай булган,
Маңгаенда ай булган.
Шул бер типкән — таш купкан,
Ике типкән — су чыккан.

Әнә шулай туганмын
Мин бу якты дөньяга:
Атлар эчте бар суны,
Мин акмадым елгага.

Әй ул атлар, ул атлар!
Җирәнкәйләр, бурлатлар.
Тартып барды дөньяны
Әйтерсең лә бурлаклар.

Килә иде ул атлар
Миңа арып, кыйналып.
Алар суым эчкәндә,
Кала идем уйланып.

Кайчагында ташыма
Яшьләре тама иде.
Атлар яше тамган җир
Каралып кала иде.

Кеше тормышка үчен
Атлардан ала иде.
Тугрылыклы туратлар
Юлларда ава иде.

Һич әйтмимен арттырып,
Шифалы иде суым:
Мине эчеп күп атлар
Ныгыта иде буын.

Суым эчкәч, хәлләнгәч,
Кешнәшә иде алар.
Шаярышып, куышып
Тешләшә иде алар.

Атлар җанында үч юк,
Кичерә белә атлар.

Арганлыкны иңнәрдән
Төшерә беләатлар.

Атлар йөргән тугайда
Котырып үсте үлән.
Атлар бит һәр үләнне
Сыйпый ирене белән.

Алар кешнәп җибәрсә,
Күкләр ярыла иде.
Болыт тиеп болытка,
Утлар кабына иде.

Ә колыннар, колыннар! —
Тугайның җаны иде.
Алар өчен суларым
Һәрвакыт баллы иде.

Үтте-китте ул көннәр,
Атлар калды үткәндә.
Аптырыйлар кешеләр
Минем суым кипкәнгә.

Әйе, мин дә җан бирдем
Соңгы ат белән бергә.
Аерым-аерым торалмый
Бернәрсә дә бу җирдә.

Уклар атсаң кошларга,
Очып барган җыр үлә.
Ә корытсаң суларны,
Ыңгырашкан җир үлә.

Таулар ватсаң, биеккә
Юлың кала киселеп.
Агач киссәң, өстеңә
Күкләр төшә ишелеп.
Менә шуны онытма
Һичбер вакыт, Кешелек!

*1990*

## АЛАСЫН АЛЫП БЕТЕРГӘЧ

Укырга керде Илшат,
Өч-дүрт көн йөрде бик шат:
Китаплар алып кайтты,
Дәфтәрләр алып кайтты.

Ә беркөн бик күңелсез
Кайтып керде ул өйгә:
— Бүтән бармыйм, инде хәзер
Бирмиләр, — ди, — берни дә.

*1990*

## БАТЫР ПЕСИ

Безнең Сим-Сим миннән батыр
Бөтен яктан:
Ул караңгыдан курыкмый,
Ә мин куркам.

Ул тычканнардан курыкмый,
Ә мин куркам.
Ул еланнардан курыкмый,
Ә мин куркам.

Менә шундый батыр була
Алсаң иде,
Караңгыда курыкмыйча
Калсаң иде.

*1991*

## ГАЛИМ ПЕСИ

Резидәнең песие —
Сим-Сим аның исеме.
Күргәнем юк иде мондый
«Укымышлы» песине.

Нинди китап күрмәсен —
Ялт та йолт «укып» чыга.
Һәр биттәге рәсемен
Берәмләп тотып чыга.

Бик күп укыгангамы —
Ике телне белә ул:
Урысча «кис-кис» дисәң дә,
Татарча «пес-пес» дисәң дә,
Йөгерә-йөгерә килә ул.
*1991*

* * *

Җирдә юллар бар чагында
Бетәрмени юлчылар?
Тыңлаучылар бар чагында
Бетәрмени җырчылар?

Күктә кояш бар чагында
Бетәрмени яктылык?
Җанда шәфкать бар чагында
Үләрмени яхшылык.

Ә яхшылык бар чагында
Яшәр әле кешелек.
Яшик шушы гап-гади бер
Хакыйкатькә төшенеп.
*1991*

## ӨЗМИМ ӘЛЕ АКЛАРЫН

Әй, гөлләр, гөлләр, гөлләр —
Ромашкалар, сиреньнәр.
Сез — язларның җырыдыр,
Сез — җирнең күз нурыдыр.

Өзмим әле акларын,
Үссен нәфис затларым.
Ак чәчәкләргә күчкән
Иң бәхетле чакларым.

Әй, гөлләр, гөлләр, гөлләр —
Резидәләр, сөмбелләр.
Сез — җирнең мәхәббәте,
Сез — җирнең мәрхәмәте.

Өзмим әле алларын,
Кинәнсеннәр, җаннарым.
Шиңмәсеннәр беркайчан,
Алар — яшьлек таңнарым.

*1991*

## КЫҢГЫРАУЛАР ТАВЫШЫ

Сагынам мин сабантуйларында
Чың-чың иткән кыңгырау тавышларын.
Алар хәзер чормаларда ята,
Эчләренә йотып сагышларын.
Ана теле кебек якын иде,
Аңлаешлы иде алар тавышы.
Шул кыңгырау телләренә сыйган
Күпме йөрәкләрнең дәрте, сагышы.
Ул телләрне күгәртмисе иде,
Чыңласыннар, тынмасыннар иде,
Бабалары моңын оныклары
Кайта-кайта тыңласыннар иде.
Кыңгыраусыз яшьләр кавышмаган,
Кыңгыраусыз төшмәгән бер килен.
Кыңгыраулап ат җикәннәр ирләр
Киткән чакта саклар өчен илен.
Ана теле кебек яшьтән сеңгән
Кыңгыраулар моңы күңелебезгә.
Моңның дәвамлыгы турында да
Онытмаска иде менә безгә.
Кыңгыраулар — бәйрәм тургайлары,
Сайрасыннар иде дугаларда:
Бабайлардан калган моң аларда,
Әтиләрдән калган моң аларда.
...Кыңгыраулар ята чормаларда.
*1991*

## ЯНУ

Вакыт аты алга чаба,
Тоягында юллар яна.
Күкрәгемә башын салып,
Иң кадерле уйлар яна.

Көннәр яна, төннәр яна,
Язлар яна, көзләр яна.
Язлар белән, көзләр белән
Без калдырган эзләр яна.

Хыял яна, өмет яна,
Дөрли-дөрли сулар яна.
Бәгыремдә бәргәләнеп,
Җырланмаган җырлар яна.

*1991*

## БҮГЕНГЕ КӨН

Кайныйлар халыклар,
Ирекккә омтылып:
Һәрбер республика —
Йомарланган йодрык.

Кая бара дөнья,
Кая бара эшләр?
Һәрбер халык бүген —
Нык кысылган тешләр.

Телләр тулы таләп,
Күзләр тулы сорау —
Республикам бүген
Гүя дәү кыңгырау.

Һәр йодрыкта — закон,
Һәр йодрыкта — гайрәт.
Һәрбер кеше бүген
Үзе аерым дәүләт.

*1991*

## ТАТАРСТАН БАЙРАГЫ

Җилфер-җилфер итә байрагыбыз,
Ниләр сөйли соң ул җилләргә? —
Көрәшүче татар халкыннан ул
Сәлам әйтә азат илләргә.

Ничә гасыр изелеп яшәдек без,
Телсез, динсез, илсез, байраксыз.
Коллар кулындагы байраклар бит
Азат халык өчен яраксыз.

Өч төс балкый безнең бу байракта:
Ак төс — безнең намус төсебез.
Яшел төсе — безнең яшәү төсе,
Кызылында чагыла көчебез.

Җилфер-җилфер итә безнең байрак,
Элеп куйдык аны биеккә.
Дөнья безнең шушы байрак аша
Омтылышны күрсен ирекккә.

*1991*

## ӘНИ, СИНЕҢ ХӘЕР-ФАТИХАҢ

Ашкынабыз ерак юлларга без
Яулау өчен күбрәк җиңү-дан.
Юлда безне бәлаләрдән саклый,
Әни, синең хәер-фатихаң.

Баш очында кайчак кояш сүнә,
Атмас кебек була якты таң.
Караңгыда безгә юл күрсәтә,
Әни, синең хәер–фатихаң.

Киңәшергә янда дус югында,
Бәргәләнгән чакта ялгыз җан —
Иң акыллы бер киңәшче була,
Әни, синең хәер-фатихаң.

Шунсыз җирдә яшәү мөмкин түгел,
Шунсыз булмас иде безгә сан —
Туган көннән үлгәнчегә кадәр
Кирәк, әни, хәер-фатихаң.

*1991*

## АЙДАГЫ ЧЫПЧЫК

Бер батыр чыпчык булган,
Барган да айга кунган.
Менә, дигән, карагыз,
Айда утыра абзагыз.

Йолдыз чүпләп ашыймын,
Кабыгын җиргә ташлыймын.
Айдан карап түбәнгә
Үземә кызык ясыймын.

Тагын әйткән бу чыпчык:
Ай миңа бер атынчык.
Шунда атынам, дигән,
Уктай атылам, дигән.

Сез әйтерсез: бу чыпчык
Кыланчык һәм мактанчык.
Айга ул ничек кунсын?
Шыттыра инде бусын.

Мин аны үзем күрдем,
Тордым хәтта янында.
Тора иде ул чыпчык
Бер мәчетнең аенда.

*1992*

## ТАПКЫР ҖАВАП

Өйгә бирелгән эшләрне
Тикшергәч, әйтте апа:
— Марат, синең мәсьәләңдә

Киткән бит бик зур хата.

Бер кило алма бәясе
Синдә йөз тапкыр арткан.
Игътибар белән карап чык
Кайда икәнен хатаң.

Марат шунда әйтеп куйды
(Ярый кайчак хәйлә дә):
— Апа, мин бит исәпләдем
Аны яңа бәядә.

*1992*

## ЭТ АЛЫР ИДЕМ МИН ДӘ

Әгәр әти рөхсәт итсә,
Әгәр әни рөхсәт итсә,
Эт алыр идем мин дә
Һәм тотар идем өйдә.

Ул эт ит тә сорамаса,
Ул эт сөт тә сорамаса,
Үлән генә ашаса
Йә су эчеп яшәсә,
Алыр идем мин дә эт,
Ләкин андый эт юк бит.

Мин хәзергә болай итәм —
Кеше этен сыйпап китәм.
Бусы да ярап куя,
Эт кулны ялап куя.

*1992*

## МИҢА ҮСӘРГӘ КИРӘК

Миңа үсәргә кирәк,
Бик тиз үсәргә кирәк.
Тиз-тиз үсеп, абыйны
Узып китәргә кирәк.

Шунсыз миңа ярамый,
Әйтмәгез, ашыкма, дип.
Абыйдан калган киемне
Кию туйдырды бик-бик.

*1992*

## КҮҢЕЛДӘ БЕР ТЕЛӘК

Һәр көнне без иртән торуга
Радио тыңлыйбыз иң элек:
Ничек соң дөньялар, тынычмы,
Бармы соң илләрдә иминлек?

Әнә шул сорауга җавапны
Телибез торырга гел белеп:
Без тыныч, без көчле, без көләч,

Илләрдә булганда иминлек.

Зарланмый эшлибез эшләрне,
Эзләми беркем дә җиңеллек:
Иң авыр эшләр дә шатлык ул,
Илеңдә булганда иминлек.

Кайвакыт без тыныч ярышта
Куйсак та бирешеп, җиңелеп:
Беләбез — без әле җиңәрбез,
Тик булсын илләрдә иминлек.

Яшибез гел шулай кояшлы
Һәм тыныч көннәргә сөенеп.
Һәркемнең күңелендә бер теләк:
Иминлек!
Иминлек!!
Иминлек!!!

*1992*

## КҮҢЕЛЛЕ КӨН

Бүген безнең класста
Бик күңелле көн булды:
Укытучыбыз һәркемгә
Гел бишле генә куйды.

Тәртип бозсак, сүкмәде,
Оялтып та китмәде.
Ул йөрде көлеп кенә,
Без йөрдек сөенеп кенә.

Сәбәбе моның гади,
Аптырамагыз һич тә:
Укытучы апабыз
Тормышка чыкты кичә.

Их, барлык апалар да
Чыксын иде тормышка.
Ул чагында һәрвакыт
Укыр идек без бишкә.

*1992*

## ЯҢГЫР ТЕЛӘҮ

Ләйлә хәзер һәр көнне
Сикереп тора да иртән
Тәрәзәгә ташлана:
— Яңгыр яумыймы икән?

Ә яңгыр гел юк та юк,
Шыбырдамый шап та шоп.
Күкләр һаман болытсыз,
Болытсыз шул кызыксыз.

Әй яңгыр, яңгыр, яңгыр,
Яумыйсың һаман да ник?
Белмисеңме, Ләйләгә

Алды әнисе зонтик.

*1992*

## БЕЗНЕҢ ТАЛӘП

Карар кылдык без мәктәптә
Забастовка үткәрергә.
Безнең таләп — билгеләрне
Ике тапкыр күтәрергә!
Ә берленең нәселен үк
Калдырмаска — бетерергә!
Иң-иң түбән билгене дә,
Һичьюгы, «өч» иттерергә.
Шушы карар үтәлмәсә,
Мәктәпләрне яптырырга!
Көндәлек һәм журналларны
Өеп утта яндырырга!
Менә шул!

*1992*

## БӘЛКИ

Үзгәртәләр, үзгәртәләр,
Үзгәртәләр дөньяны.
Бу бутаулар, үзгәртүләр,
Күрәсең, бик файдалы.

Дөньяны үзгәртә торгач,
Бәлки, шуны аңларлар:
Кирәге калмады диеп,
Мәктәпләрне ябарлар.

Бөтен кеше надан булса,
Файда гына бит илгә:
Китап-дәфтәр, гәзит-журнал
Кирәк булмый беркемгә.

Институт, мәктәпләрдә
Ферма ачарга була.
Сыер, сарык, дуңгыз асрап,
Ит-май ашарга була.

Саный китсәң, наданлыкның
Файдасы күп тагын да.
Тыныч кына яшәп була
Дуңгыз көтеп авылда.

Бәлки әле, берәр вакыт
Килер шундый заманнар:
Чыбыркы тотып утырыр
Ил башында наданнар.

*1992*

## ФИЗЗАРЯДКА ЯСЫЙ

Сөйләнергә бик ярата
Гөлгенә.
Дәрестә дә сөйләшә ул
Гел генә.

Күп сөйләшмә, дисәң әгәр,
Гөлгенә:
— Физзарядка ясыйм мин, — ди, —
Телемә.

*1992*

* * *

Җир өстенә сирәк кенә булып
Карның тәүге орлыклары төште.
Күп тә үтми шушы орлыклардан
Кышның әйбәт калын кары «үсте».

Озакламый ярсу язлар килеп
«Урып» алыр кышның бу карларын.
Кар сулары белән тутырып куяр
Җир куенында булган зур амбарын.

*1992*

## КАЛСЫН БЕЗНЕҢ ЭЗЛӘРЕБЕЗ

Очтык, очтык кошлар булып,
Коенып таң нурларында;
Калсын безнең эзләребез,
Калсын безнең төсләребез
Киек Каз Юлларында.

Истек, истек җилләр булып
Хыял канатларында;
Калсын безнең эзләребез,
Калсын безнең төсләребез
Гөлнең ап-акларында.

Актык, актык сулар булып,
Актык шаулап та, тын да;
Калсын безнең эзләребез,
Калсын безнең төсләребез
Диңгез дулкыннарында.

*1993*

## ШУҢА КҮРӘ ДӘ БЕЗ МАЛАЙЛАР

Безнең җаннар гел уйнаклап тора,
Болындагы гүя шук тайлар.
Күпме чапсак та, без арымыйбыз,
Шуңа күрә дә без малайлар.

«Сөйләшәбез» йодрык белән дә без,
Күбеп кайта кайчак маңгайлар.
Зарланмыйбыз ләкин, сынатмыйбыз,
Шуңа күрә дә без малайлар.

Үртәсәләр, кызлар үртәсеннәр,

Вакыт җиткәч, алар бер аңлар —
Без кызларны яклар өчен туган,
Шуңа күрә дә без малайлар.

Артып китсә кайчак шуклыгыбыз,
Тыныч булсын апа-агайлар,
Илнең киләчәге безнең кулда,
Шуңа күрә дә без малайлар.

*1993*

## КЫЗЛАР ҖЫРЫ

Без әле язгы күбәләк,
Кырга чыгасыбыз бар.
Кырга чыгып, очып-уйнап,
Гөлгә кунасыбыз бар.

Без әле янган шәм генә,
Йолдыз буласыбыз бар.
Йолдыз булып, кызыктырып
Янып торасыбыз бар.

Без әле нәни кош кына,
Оя корасыбыз бар.
Рәнҗетмәгез безне берүк —
Ана буласыбыз бар.

*1993*

## ӨЧ НӘРСӘ

Туган ягына кешене
Өч нәрсә гел тартып тора.
Кайда йөрмә — шул өч нәрсә
Тартып алып кайтып тора.

Беренчесе — балачагың,
Агачтагы алма чагың.
Эзли кеше шул алманы,
Белсә дә алданачагын.

Икенчесе — туган өең,
Ул — кендек бәйләнгән төен.
Йөртә кеше үз тәнендә
Шул төеннең бетмәс җөен.

Өченчесе — тапкан анаң,
Бар яхшылык безнең аннан.
Кеше ятим, кеше үксез,
Шушыларны алсаң җаннан.

*1993*

## ОНЫТЫП КУЙСАК

Һиндстаннан килгән чәйләр тәмле,

Эчәбез гел аны кич-иртә.
Авырып китсәк, кирәк була ләкин
Туган якта үскән мәтрүшкә.

Җылы яктан килгән җимешләр дә
Авызлардан сулар китерә.
Ә чирләсәк, үз бакчаңда үскән
Кура җиләк тизрәк терелтә.

Онытып куйсак туган якларны без
Дөнья куып йөреп кич-иртә.
Мәтрүшкәсе, җиләкләре белән
Тәңре безнең искә төшертә.

*1993*

## СУЫК

Уссаланып, бүген суык,
Малайларны йөри куып.
Ә малайлар тоттырмыйлар,
Һич кенә дә тик тормыйлар.

Йөгерәләр, тәгәриләр,
Бер-берләрен бәргәлиләр.
Кыйнашалар-чинашалар,
Йодрыкларын җәлләмиләр.

Малайларны тоталмагач,
Артларыннан куып-куып,
Бабайларның битләреннән
Чеметеп китә усал суык.

*1993*

## ТАВЫШСЫЗ ПУЛЕМЕТ

Бакчабызда бер пулемет
Туктаусыз атып тора.
Аткан уклары үзенә
Әйләнеп кайтып тора.

Беркемне дә яраламый
Бу пулемет уклары.
Тик гөлләрне сыйпап үтә
Уклары — бал кортлары.

*1993*

* * *

Килеп җитте җәй уртасы,
Башланды озын көннәр.
Кичен чәчәк атар кебек
Иртән утырткан гөлләр.

Яктырып таң ата башлый,
Сүнүгә кичке шәфәкъ.
Кояш булып, яңгыр булып

Ява күкләрдән шәфкать.

*1993*

## АК КӘГАЗЬ

Әй, ак кәгазь. Синдә нинди көч бар?
Тартасың син һаман үзеңә.
Күңелемнең нечкә иләге син,
Һәр сүз синең аша сөзелә.

Бөтен ачу кайчак сиңа төшә,
Ертыласың, утта янасың.
Үткәрмисең ләкин үзең аша
Уйларымның ямьсез, карасын.

Фикерләрне туплап барыр өчен
Син уңайлы, иң шәп бер кәгазь.
Һәр шигырьне язып куйган саен
Рәхмәт укыйм сиңа, ак кәгазь.

Искерүне белмәс хәтерем син,
Киләчәккә илтер күперем.
Шул күпердән килеп табарбыз без
Мизгелләрен минем гомернең.

*1993*

## АКЛЫК

Әй матур да кар явуның күренеше!
Ак кар, ахры, күкнең ап-ак сөенече.
Сөенечне буламыни әйтми калып? —
Ул бит чыга яки ташып, яки янып.

Күкнең бүген сөенече чиктән ашкан —
Җир белән күк бербөтен булып тоташкан.
Кешеләр дә йөри гүя күккә басып,
Иңнәрендә ак канатлы шатлык ташып.

Бүгенге көн юмартлыкның бер билгесе,
Күңелләргә күчә аның ак өлгесе.
Тәңре безгә җибәргәндер бу аклыкны
Әз булса да сафлансын дип җир кешесе.

Югыйсә бит каралыклар хәттин ашты,
Пычраклыклар сарды җанны, иңне басты.
Керегез, кер, диеп, минем ак өемә,
Күкләр безгә үзенең җиде ишеген ачты.

*1994*

## СЕРЛЕ КӨНДӘЛЕК

Җир ул — табигатьнең көндәлеге,
Шунда яза барлык хисләрен:
Җилләр белән ашкынуын яза,
Гөлләр белән — сөенечләрен.

Карлар белән — күңел аклыкларын,
Яңгыр белән — кайгы, сагышын.
Аккан сулар белән язып бара

Көннәр белән төннәр агышын.

Җәйге кояш белән назын яза,
Яшеннәре белән — гайрәтен.
Көзләр белән юмартлыгын яза,
Куеп бөтен көчен, сәләтен.

Табигатьнең шушы көндәлеген
Өйрән генә укый белергә —
Аңларсың син һәр күренеш серен,
Төшенерсең яшәү серенә.

*1994*

## АГЫМСУ

Әй агымсу, агымсу,
Чабасың ярсып-ярсып.
Кемнәр серен сөйләмәгән,
Синең ярларга басып.

Әй агымсу, агымсу,
Өсләрең дулкын-дулкын.
Күпме кайгы-хәсрәтләрне
Дулкыннар белән йоттың?

Әй агымсу, агымсу,
Ярларың катлы-катлы.
Ярыңа кемнәр язмышы
Ком-ташлар булып ятты?

Әй агымсу, агымсу,
Юлларың борма-борма.
Син дә туры агалмыйсың —
Бәреләсең уңга-сулга.

Әй агымсу, агымсу,
Бик болганган суларың.
Кайсы халык җаны аша
Үтте икән юлларың?!
*1994*

## КЫЗЫК НӘРСӘ

Кар да кебек ул,
Сөт тә кебек ул.
Бар да кебек ул,
Юк та кебек ул.
Үзе тоттырмый,
Үзе йоттырмый.
Үзе дәшә ул,
Үзе кача ул.
Күккә дә очмый,
Җиргә дә төшми.
Суга да акмый,
Утта да пешми.
Үзе еракта,

Үзе янәшә.
Бик кызык нәрсә —
Рәшә!
*1994*

## САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Салават күпере төшкән
Болынга.
Аллы-гөлле буяулары
Кулында.

Төс өләшеп йөри, ахры,
Гөлләргә.
Нинди буяу тияр икән
Кемнәргә?

Чабыйм әле мин дә шунда —
Булышыйм.
Җиребездә гөл-чәчәкләр
Күп булсын.
*1994*

## БАЙ КЕШЕ

Мин бай кеше.
Күп малайлар
Карый миңа көнләшеп.
Юмарт булсам да, аны мин
Бирә алмыйм өләшеп.

Очыйм дисәм, оча алам,
Канатларым пар минем.
Байлыгым шул — әтием дә,
Әнием дә бар минем.

*1994*

## САНДУГАЧ ТЫЙНАКЛЫГЫ

Сандугач сайрый өздереп,
Җыры сарыла җанга.
Карыйм-карыйм — күрә алмыйм,
Кайда соң, үзе кайда?

Керәм урманнар эченә,
Күрмәмме диеп аны.
Юк, күралмыйм — кошым китә
Моңга күмеп дөньяны.

Үзен күрсәтүдә түгел,
Җырда аның шатлыгы.
Булсачы кешеләрдә дә
Сандугач тыйнаклыгы.

*1994*

## ҮЗЕБЕЗ ХУҖА БУЛГАЧ

Энем белән без икәү
Һәр көн өйдә калабыз.
Эт булып, песи булып
Куышабыз, чабабыз.

Бүре булып улыйбыз,
Аю булып дулыйбыз.
Мендәрләрне туп итеп
Футболлы да уйныйбыз.

Беркөнне бер уенны
Уйнап беттек дигәндә,
Кара буяу таптык та
Асфальт җәйдек идәнгә.

Асфальт бик матур булды,
Ялт та йолт итеп торды.
Тик машинабыз батты,
Батты да ябышып катты.

Машинасы машина,
Кайгырган юк ансына!
Ничек түзәр сыртыбыз
Әтинең каешына?!

*1994*

## МИНЕМ ЭТ БУЛАСЫМ КИЛӘ

Минем эт буласым килә,
Беләсезме нигә?
Этләрне бит иркәлиләр
Сыйпап үбә-үбә.

Этләр югалса, эзлиләр,
Кадерле шул этләр.
Этләр алдында тора гел
Тәмле-тәмле итләр.

Кая барса да, аларны
Йөртәләр гел тотып.
Калдырмыйлар бит аларны
Больницада «онытып».

*1994*

## КАЛЫЙК ВАКЫТЫНДА СОРАП

Озын-озын, нәрсә озын? —
Озын-озын бәхет юлы.
Үз бәхетенә бара кеше
Кайвакытта гомер буе.

Олы–олы, нәрсә олы? —
Ата-ана хакы олы.
Онытмасын иде кеше
Үлгәнчегә кадәр шуны.

Авыр-авыр, нәрсә авыр? —

Авыр аналар каргышы.
Бу каргышны алганнарны
Көтә Сак-Соклар язмышы.

Ерак-ерак, нәрсә ерак? —
Үткәннәргә юллар ерак.
Ата-ана фатихасын
Калыйк вакытында сорап.

*1994*

## ЫЗГЫШЫРГА НИГЕЗ ЮК

Тургай сайрый үз телендә,
Сандугач — үз телендә.
Өстен телләр, мескен телләр
Юк табигать телендә.

Саескан да, каргалар да,
Тартар яки бүдәнә —
Һәркайсысы үз телендә
Рәхәтләнеп сөйләнә.

Ник чыпчыкча сайрыйсың дип,
Козгын көлми чыпчыктан.
Яңгырый йөз төрле аваз
Йөзләрчә төр кошчыктан.

Табигатьтә гармония,
Табигатьтә тигезлек.
Бер урманга бар да сыя,
Тоймый беркем көйсезлек.

Тавышларның күплегеннән
Арта гына хозурлык.
Уйласаң уйларга чумып,
Хәйран булып торырлык.

*1994*

## АШЫГЫЙК

Актыккы суларны алганда
Уфтанмас өчен җан ачынып —
Кулларда егәрлек барында,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Күтәрик егылган гөлләрне,
Матурлык калмасын басылып.
Холкыбыз бик сабыр булса да,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Булмасын нәфсебез безгә баш,
Без аңа үзебез баш булыйк.
Яманлык җиңелсен дисәк без,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Ходаның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

*1994*

## АТЫМ-КАНАТЫМ

Атландым чабыш-атка,
Карамыйм алга-артка —
Ярышам җилләр белән,
Кавышам гөлләр белән.

Кичәм карурманнарны,
Үтәм чытырманнарны.
Сикерәм таулар аша,
Сикерәм ярлар аша.

Чакыра иркен дала.
Кызлар кул болгап кала:
Атым ыргый айларга,
Тотынып калам ялларга.

Җил сызгыра колакта,
Йолдыз яна еракта.
Оча атым, сикерә,
Җиде күккә менгерә.

Йолдыз җыям учларга,
Бүләк өчен кызларга.
Йөртә күктә җыр-атым,
Мәңге талмас канатым.

*1994*

## ФЕВРАЛЬ

Февраль, февраль!
Шундый гаҗәп ай син —
Бер карыйсың, өтә суыгың.
Бер карыйсың, тамчыларың бии,
Сәхнә итеп түбә кыегын.

Бер карыйсың, күктән карлар ишелә,
Буран куба кысып тыннарны.
Бер карыйсың, кояш үз нурында
Коендырып йөри кырларны.

Февраль холкын алдан әйтә алмый
Иң-иң оста синоптиклар да;
Сыйган аңа мартның җилләре дә,
Январь аеның суыклары да.

Тугангамы февраль аенда,

Холкым минем шуңа охшашлы:
Җанга сыйган болыт, давыл, буран,
Яшен, яңгыр һәм дә кояшы.

*1994*

* * *

Сайраганы, сайрамаганы бар,
Кошларның да була төрлесе.
Ләкин юктыр кошның һичбер җирдә
Мәкерлесе, эче керлесе.

Кошлар йөрәгендә мәкер булса,
Оча алмас иде һавага.
Яманлыкны күтәрерлек канат
Ярый әле юк бер җанда да.

*1994*

## ЮЛБАСАР

Йөрер өчен аңа һич тә
Кирәк түгел юлларың.
Киртә була алмый аңа
Хәтта агымсуларың.

Үтә ул карлы кырлардан,
Үтә сазлыклар аша.
Сикереп чыга бакчадагы
Читән-казыклар аша.

Бу гайрәтле юлбасарны
Куркыта алмый берни:
Киң урамнарга сыймыйча,
Ул гел бәйләнеп йөри.

Курка ул бары керергә
Карурманнар эченә.
Алар гына бирешмиләр
Юлбасар-җил көченә.

*1994*

## ЯЗГЫ ТУЙ

Күл буенда зур концерт,
Күңелле һәр тарафта.
Язның матур җырларын
Җилләр ерак тарата.
Җырчылары кем диген? —
Җырчылары бакалар.
Алар шулай җырлашып
Концерт куеп яталар.
Иң зур бака — солистка,
Кечерәге — дирижер.
Ыбыр-чыбыр бакалар
Мең тавышлы олы хор.
Концерт кына түгел бу,
Бу — язгы бака туе.

Бик күңелле урын шул
Туй ясарга күл буе.

*1994*

## ТИК ИГЕЛЕК МӘҢГЕЛЕК

Ходай безне яраткан,
Төрле җиргә тараткан.
Акыл биргән, тел биргән,
Иман биргән, дин биргән.

Кояш биргән, Ай биргән,
Яшәр өчен җай биргән.
Җир дигән зур табынга
Нигъмәтләрен бай биргән.

Эшләр өчен кул биргән,
Сайлар өчен юл биргән.
Килгән кадәр кулыңнан
Яхшылыклар кыл, дигән.

Исеңдә тот шуны да —
Бу дөнья фани, дигән.
Тик игелек агачы
Һичкайчан аумый, дигән.

*1994*

## ЧЫПЧЫК, ӘНИ ҺӘМ МИН

Чыпчык әйтә: «Чык, чык, — ди, —
Урамда бик кызык», — ди.
Әни әйтә: «Юк, юк, — ди, —
Чыгып йөрмә, суык», — ди.

Ә мин әйтәм: «Чыгам! — дим, —
Суык түгел урам, — дим. —
Әнә чыпчык чыбыкка
Яланаяк кунган», — дим.

*1994*

## ЧЫНЛАП ӘЙТӘМ

Әти белән урманга
Бардык беркөнне.
Машинабыз коштай очты —
Мин тоттым рульне.

Бәлки, уйлыйсыздыр әле
Шаярта диеп.
Юк, шаяртмыйм: тоттым рульне
Туктагач килеп.

*1994*

## БЕР ТАКТА

Беркөн әти урамнан
Табып керде бер такта.
Шундый әйбәт, шәп такта,
Буялган ул ап-акка.

Әти әйтә, әгәр, ди,
Тапсам тагын күп такта,
Дача салып җибәрәм
Су буена — аръякка.

Безнең дача яныннан
Пароходлар үтәр, ди.
Безгә алар «гу-гу» дип
Сәлам биреп китәр, ди.

Без калырбыз кул болгап
Үзебезнең балконнан.
Йөгерешер дулкыннар
Пароходлар артыннан.

Ә хәзергә бу такта,
Матур такта, ак такта
Өр-яңа ямау булды
Безнең иске баракка.

*1994*

## БЕРДӘНБЕР

Мин әтинең бердәнбере,
Мин әнинең бердәнбере.
Алырга гына торалар,
Ни сорасам, шул әйберне.

Ләкин мин күп сорамыймын,
Мин бит инде аңлы, зур кыз.
Беләм: әти-әниләрнең
Акчалары түгел чутсыз.

*1994*

## КАЙСЫ КӨЧЛЕРӘК

Җил мактанды: мин көчле,
Мин аударам агачны.
Ә гөл әйтте: мин көчле,
Мин тишеп чыгам ташны.

Сезнеңчә кайсы көчле,
Барсын җимергән җилме?
Әллә җирне матурлап
Таш тишеп чыккан гөлме?

*1994*

## ТИЗ ҮСҮ УЛ — БИК ЯХШЫ

Әни әйтә: ай-һай, улым,
Тиз үсәсең бигрәк, ди.
Болай булса сиңа ел да
Яңа өс-баш кирәк, ди.

Гел яңа кием алырга
Акча җиткерим ничек?
Булмыймы соң бераз гына
Әкренрәк үсеп.

Ә мин әйтәм: кайгырма, дим,
Тиз үсү ул — бик яхшы.
Үскәчтен, мин үзем эшләп
Карый башлыйм өс-башны.

*1994*

## БӨТЕН КЕШЕ БАЙ БУЛЫР

Кемгә генә карама,
Акча юк дип зарлана.
Бу ни хәл соң, бу ни эш? —
Болай булмаска тиеш.

Акча кәгазь ләбаса —
Күп-күп итеп ясасаң,
Җитәр иде сиңа да,
Җитәр иде миңа да.

Акча әгәр күп булса,
Урлашу бетәр иде,
Кеше аны чүп кебек
Типкәләп китәр иде.

Йозак кирәкмәс иде,
Өйләр бикләнмәс иде,
Бер-берсеннән кешеләр
Һич тә шикләнмәс иде.

Үзем министр булсам,
Шуннан башлармын әле:
Бар дөньяны акчага
Күмеп ташлармын әле.

Бетәр җирдә ярлылар,
Бетәр җирдә зарлылар.
Аш-су бал да май булыр,
Бөтен кеше бай булыр.

*1994*

## ҮПКӘЛӘҮ

Сеңлем Ләйлә су буеннан

Бик нык үпкәләп кайтты.
Ни булды, дим, үпкәләдең
Кемнәргә син бу чаклы?

— Кемгә булсын! — диде сеңлем. —
Үпкәләдем кояшка.
Чыкмады бит, ә мин ничек
Кызыныйм аннан башка?!

*1994*

## БӨТЕН ЭТ — МИНЕМ ДУСТЫМ

Барлык этләр миңа өрә,
Чыктым исә урамга.
Бу ни хәл соң, бу ни эш? —
Аптырыймын моңарга.
Үртәмим дә бит үзләрен,
Бик тәртипле малай мин.
Һәрбер эткә сөяк бирәм,
Дуслар булыйк, давай, дим.
Сөягемне алсалар да
Китәләр алар өреп.
Әллә ошамый микән соң
Аларга минем бүрек?
Шулайдыр әле, мөгаен,
Башта бит бүре бүрек.
Шуңа каршылыйлар алар
Һәрвакыт мине өреп.
Бетте. Ташладым бүрекне,
Суык булса да кышын.
Хәзер инде урамдагы
Бөтен эт — минем дустым.
*1994*

## ШАГЫЙРЬ БӘХЕТЕ

Кулга кәгазь-каләм алсам,
Өстәлә дәрт, арта көчем.
Табыла сүзләр, агыла хисләр,
Кушылып китә иртә-кичем.
Онытыла тормыштагы
Җитешсезлек, рәнҗү-үпкә.
Ак кәгазем — ак канатым
Алып менеп китә күккә.
Ачыла күкнең капкалары,
Исеп куя йолдыз җиле.
Монда күкләр бер болытсыз,
Монда фәрештәләр иле.
Монда кушыла көн белән төн,
Монда кушыла барлык төсләр.
Агыла җиргә йолдыз нуры,
Сузылып кала ап-ак эзләр.
Карап тора Ай һәм Кояш
Сокланып бу хозурлыкка.
Китә шунда җан пакьләнеп,
Дөнья гаме чыга юкка.
Булмаса мондый мизгелләр,
Шагыйрь җаны үләр иде.

Сокланучы бетсә әгәр,
Йолдызлар да сүнәр иде.

*1994*

## ЧАЛБАРЫ ЮК, ДИ

Бу заман шундый
Шәп булып чыкты —
Иске заманны
Сукты да екты.

Пионер бетте,
Комсомол бетте.
Бу заман безне
Ирекле итте.

Теләсәң — укы,
Теләмәсәң — юк.
Үз кулыбызга
Бирелде хокук.

Уйныйсың килсә,
Рәхәтлән — уйна.
Тик чалбарыңны
Ерттырып куйма.

Тузса, тишелсә
Иске чалбарың,
Белеп тор: әле
Чалбары юк, ди,
Яңа заманның.

*1994*

## МАКТАНЧЫК ЧЕБЕН

Бер мактанчык чебен әйткән
Дусларына: менә түшәм.
Телим икән, таш түшәмне
Башым белән бәреп тишәм.

Һәм күрсәткән батырлыгын,
Башы белән сөзеп ташны.
Һәм чынлап та тишкән чебен,
Ташны түгел, ләкин башны.

*1994*

## АЛА КАРГА

Ала карга нигә ала,
Белә моны кайсыгыз?
Белмәсәгез, үзем әйтәм,
Авыртмасын башыгыз.
Бик-бик элек, кош-кортларга
Кием өләшкән чакта,
Ала карга бар кошлардан
Килгән, ди, иң-иң артта.

Ул килгәнче кара тунны
Алган, ди, кара карга.
Ә ак тун эләккән булган
Өлгер акчарлакларга.
Ала каргага калган, ди,
Тик ала-кола тире.
Ала-коладан тектергәч,
Тун булган ике төрле.
Шулай да ул шат икән,
Туны җылы, шәп икән.
Туны шәп булгач, карга
Китми җылы якларга.

*1994*

## АЧУ КИЛӘ

Бик ачу килә кышка,
Көннәре шундый кыска —
Өлгермисең уйларга,
Чакыралар уйнарга.

*1994*

## САЕСКАН

Саескан, саескан,
Борыны бозга ябышкан.
Алырга дип тартышкан,
Әмма боз бик карышкан.

Җибәрмәгән, нык тоткан,
Эләктергән койрыктан.
Шулай итеп саескан
Бозга тәмам ябышкан.

*1994*

## ТАБЫШМАК

Йөреп тора туктаусыз,
Үзе алга баралмый.

*(Сәгать)*

*1994*

## ЯМАНЛЫК ДИГӘН КОРТКА

Яшәгән, ди, бер йортта
Яманлык дигән кортка.
Котырткан ул һәркемне
Һәрвакыт яманлыкка.
Бик-бик усал булган ул,
Эттәй ырлап торган ул.
Һәр саф җанга таш аткан,
Шуңардан бик тәм тапкан.
Аны суга салганнар —
Тик ул суда батмаган.
Аны утка атканнар —
Аңа ут та капмаган.

Көлгән ул кешеләрдән,
Мине җиңәр көч юк дип.
Мин батарлык су юк дип,
Мин янарлык мич юк дип.
Мин керәм сезнең җанга,
Бик рәхәт миңа анда.
Мин җиңәм батырларны,
Саргайтам матурларны.
Тик ялгышкан бу кортка,
Дәва бар яманлыкка.
Мактанган ул ашыгып —
Ул дәва бит Яхшылык.
Яман булсак, безне тиз
Кол итәр ул, басар ул.
Яхшы булсак, күңелдән
Үзе чыгып качар ул.

*1994*

## ПЕСИ ҺӘМ ТЫЧКАННАР

Песи белән тычканнар
Элек бик дус булганнар:
Уйнаганнар гел бергә,
Җырлаганнар гел бергә.
Ризыклар бүлешкәннәр,
Кунакка йөрешкәннәр.
Бары да уртак булган,
Югы да уртак булган.
Беркөн песи чирләгән,
Бер өшеп, бер тирләгән.
Әйткән: тычкан дусларым,
Лачыннарым-кошларым!
Аптекага барыгыз,
Берәр дару алыгыз.
Ярар, дигән тычканнар
Һәм урамга чыкканнар.
Ә урамда, урамда —
Шундый кызык, ди, анда:
Этләр туп тибәләр, ди,
Җилләр җыр сибәләр, ди.
Күселәр сөзешә, ди,
Чыпчыклар көлешә, ди.
Ничек ташлап китәсең
Бу кадәрле кызыкны —
Уйнаганнар тычканнар
Качышлы һәм сызыклы.
Уйный торгач көн үткән,
Көн үткән дә кич җиткән.
Аптекалар ябылган
Һәм дарусыз калынган.
Инде хәзер нишләргә? —
Дару юк бит эчәргә.
Алдашырга булганнар,
Сүз беркетеп куйганнар.
Әйткәннәр: песи дускай,
(Килгән үзләре ай-вай)
Бар аптекны айкадык,
Кирәк дару тапмадык.
Йә, ярар, дигән песи,

Калтырап өши-өши.
Иртәгесен барырсыз,
Ни бар, шуны алырсыз.
Иртәгесен тычканнар
Иртүк йөгереп чыкканнар.
Урам тагын гөр килгән,
Бар да уйнаган, көлгән.
Бу кызыклы уенга,
Сабантуйдай җыенга
Тычканнар да кушылган,
Чирле песи онтылган.
Караңгы төшкәч кенә,
Уеннар беткәч кенә
Тычканнар кергән кайтып,
Кара кайгыга батып.
Әй, песикәй, дигәннәр,
Башкайларын игәннәр.
Аптекларны япканнар,
Кирәксез дип тапканнар.
Йә, ярар, дигән песи,
Кайгырмагыз юк өчен.
Хәлем бара уңайга,
Терелермен болай да.
Көн артыннан көн үткән,
Песи терелеп җиткән.
Чыгып киткән урамга,
Бераз һава суларга.
Шунда бүтән песиләр,
Маэмайлар һәм күселәр
Алганнар аны урап,
Куйганнар аннан сорап:
Син кайда булдың болай?
Күренмәдең бит бер ай.
Песи әйткән: чирләдем,
Бер өшеп, бер тирләдем.
Минем тычкан дусларым
Һәр көн аптекка чапты,
Ләкин алар көн саен
Дару тапмыйча кайтты.
Шул чагында маэмайлар,
Алабайлар, акбайлар,
Чыпчыклар һәм чәүкәләр
Бертавыштан әйткәннәр:
Синең тычкан дусларың
Һәр көн монда уйнады.
Алар бит бер тапкыр да
Аптекада булмады.
Моны белгәч, песинең
Ачуы чыккан яман.
Тычканнарны шунда ук
Бугазларыннан алган.
Песи белән тычканнар
Шулай дошман булганнар.
Кем кичерсен ялганны? —
Яралый бит ул җанны.
Төзәлми җан ярасы,
Йөзгә күчә карасы.
Сөйләсәң генә хак сүз,
Һәрвакыт ак була йөз.

*1994*

## КЫЗЧЫК ҺӘМ КОШЧЫК

Кил әле минем яныма,
Килче, матур кошчык.
Кун әле минем учыма,
Китмә әле очып.
Сөйләшик әле туйганчы,
Син кайлардан килдең?
Бәлки, синең дә минем күк
Юктыр туган өең?
Киткәндер, бәлки, сине дә
Әти-әниең ташлап.
Эзлисеңдер син шуларны
Иртә яздан башлап.
Алай булса, бергә эзлик,
Җиңел булыр безгә.
Мин җир буйлап йөрермен,
Ә син күктән эзлә.
Һавалардан очкан чакта
Күз сал болытларга.
Бәлки, эзләрен табарсың
Ерак офыкларда.
Диңгезләрне дә карап үт,
Синең күзең үткер.
Әгәр тапсаң, тиз арада
Миңа хәбәр китер.
Кошчык, кошчык!
Бар, оч инде
Тизрәк, тизрәк, тизрәк!
Юлларымда егылмаска
Миңа өмет кирәк!
Өмет кирәк!

*1995*

## ИКЕ КЕШЕ

Мин бер түгел, ике бугай,
Никтер миңа тоела шулай:
Ярты ягым кире минем,
Ярты ягым гына уңай.

Ашый беләм — юа белмим,
Чүпли беләм — җыя белмим.
Уйный беләм — уйлый белмим,
Сөйли беләм — тыңлый белмим.

Ала беләм — бирә белмим,
Йоклый беләм — тора белмим.
Ерта беләм — ямый белмим,
Өзә беләм — ялгый белмим.

Нигә соң мин шулай икән —
Бер кире, бер уңай икән?
Уйны уйга ялгый алмыйм,
Үз-үземне аңлый алмыйм.

*1995*

## ЯҢГЫР

Матур булып яңгыр явып үтте,
Чистарынып калды бар дөнья.
Сөенешеп коендылар гөлләр
Көтеп алган язгы яңгырда.

Үләннәр дә, юылган чәч кебек,
Кинәт кенә китте күпереп.
Сөендерде яңгыр бар дөньяны,
Килгәнгәме бик тә көттереп.

Сабырлыкка сынау узды һәр гөл —
Һәм аларның өмете акланды.
Һәр үсемлек бер йотым су эчте,
Шуның белән гомер сакланды.

Күп вакытта бер йотым су җитми
Йә җитми бер йотым һавасы.
Шундый якын, шундый кыска бит ул
Яшәү белән үлем арасы.

*1995*

## МИЛЛӘТЕМ

Әй милләтем, милләтем —
Байлык тулы келәтем;
Шул келәткә ачкыч тап, дип,
Туган телне өйрәттең.

Келәтең бик хикмәтле,
Байлыкларың кыйммәтле,
Һәр байлыгың үзенә тартып
Җилкендерде йөрәкне.

Авыр узган юлларың,
Шуңар моңлы җырларың.
Тик җырларың өзелмәде,
Кысылса да тыннарың.

Гасырларның сыры бар
Синең йөздә, милләтем.
Матурларның нуры бар
Синең күздә, милләтем.

Үч тотмадың беркемгә —
Булдың олы йөрәкле.
Йөз чытмадың беркемгә —
Булдың изге ниятле.

Әй милләтем, милләтем,
Бар әле көч-куәтең.
Барасың иңеңә салып
Заманалар михнәтен,
Әй милләтем, милләтем.

*1995*

## ГОРУР БУЛЫЙК

Мескенләнмик әле, горур булыйк,
Горур булуларга ни җитә!
Сокланабыз бит без бөркеткә дә
Очса гына күктә, биектә.

Син бит, халкым, бөркет нәселеннән,
Һич килешми сиңа мескенлек.
Дошманнарың хөрмәт итсен дисәң,
Горурлыгың итсен өстенлек.

Матур халык бит без, батыр халык,
Күпме изсәләр дә, калыктык —
Милләт үлми горурлыгы барда,
Горурлык ул — безнең таныклык.

Яшереп яткырмыйча йөрәкләрдә
Никадәрле гайрәт, көч барын —
Яшик җирдә бер дә кимсенмичә,
Башны биек тотып, татарым.

*1995*

* * *

Бу дөньяның ние бар? —
Кояшы бар, ае бар;
Теләгәндә учларында
Учак ягар җае бар.

Бу дөньяның ние бар? —
Үзәне бар, тавы бар;
Бер тавына менеп җитсәң,
Артларында тагы бар.

Бу дөньяның ние бар? —
Елгасы бар, яры бар;
Ярсып аккан елганың да
Уйга баткан чагы бар.

Бу дөньяның ние бар? —
Күге бар һәм җире бар;
Күкнең, җирнең мәңге бетмәс
Ымсындырган сере бар.

*1995*

## ДИҢГЕЗ

*Кызылъяр мәктәбенең 75 еллыгына*

Туган авылым мәктәбен,
Белмим, кемнәр салдырган?
Кем булса да мәңгелек
Һәйкәл салып калдырган.

Диварлары тузса да,
Күп гомерләр узса да,
Кала килгән нигезе
Булып гыйлем диңгезе.

Бу диңгездә бик күпләр
Өйрәнгәннәр йөзәргә.
Өйрәнгәннәр ун баллы

Давылларга түзәргә.

Алмашынып торса да
Капитаннар корабта,
Алга барган кораблар,
Чигенү белмичә артка.

Күп диңгезләр кичелгән,
Тозлы сулар эчелгән.
Күп җәүһәрләр җыелган
Бу диңгезнең эченнән.

Әле һаман бу диңгез
Тынгысыз һәм ярсулы.
Болганса да заманнар,
Болганмый ул, саф сулы.

*1995*

## АТА ХУЛИГАН

Котыра буран, дулый,
Киң урамнарга сыймый.
Кешеләрнең битенә
Кушучлап карлар сылый.

Үткәнгә дә бәйләнә,
Сүткәнгә дә бәйләнә:
Бүрекләрен салдыра,
Аптырашта калдыра.

Карт дими ул, яшь дими,
Кемнәрдән генә көлми.
Бу ата хулиганга
Милиция дә тими.

Кешеләр аннан курка,
Кемдер бүреген тота.
Кемдер ул күрмәсен дип
Сыена берәр йортка.

Ә мин аннан курыкмыйм,
Бүрегемне дә тотмыйм —
Котырсын әйдә буран,
Мин бит өйдә утырам.

*1995*

## ЙОКЫ ЧАКЫРУ

Йокы, йокы, кил инде,
Куеныма кер инде.
Тәмле, татлы сыеңны
Миңа бераз бир инде.

Керфегемә кунарсың,
Күзләремә туларсың.
Бик аз гына булса да
Минем белән уйнарсың.

Чәчләремнән сыйпарсың,
Битләремнән сыйпарсың.

Мин йоклап киткәч кенә
Назлавыңнан туктарсың.

Йокы, йокы, кил инде,
Көткәнемне бел инде,
Әнием дип уйлармын,
Тынычланып йоклармын.

*1995*

## БАРГАНДА ҺӘМ КАЙТКАНДА

Атлап бик тә иренеп,
Сузылып, киерелеп,
Каранып тирә-якка,
Тукталып һәрбер чатта
Кая бара балалар?
Мәктәпләргә баралар.
Очынып, сикерешеп,
Куышып, йөгерешеп,
Карамый алга-артка,
Туктамый һичбер чатта
Кая бара балалар?
Өйгә кайталар алар!

*1995*

## ҮСМӘМ МИКӘН, НЫК ТАРТСАҢ

Җитим генә мин үсеп,
Алачакмын бер көчек.
Ул минем дустым булыр,
Исеме Очкын булыр.

Аның белән әле без
Сунарга да йөрербез,
Аю, бүре тотарбыз,
Урманнарда йокларбыз.

Пәриләрдән-җеннәрдән,
Тагын әллә кемнәрдән
Тормабыз куркып бер дә,
Булгачтын икәү бергә.

Ә хәзергә юк этем,
Өйдә берүзем — читен.
Әти-әни гел эштә,
Кайталар бары кичтә.

Бик куркак булмасам да,
Бик елак булмасам да,
Елап та алгалыйм шул,
Куркып та калгалыйм шул.

Туйдым болай булудан,
Гел бәләкәй булудан.
Бер тартыгыз колактан,
Үсмәм микән, нык тартсаң.

*1995*

## ӘЙ, ДУСЛАРЫМ, КИЛЕГЕЗ

Әгәр дә мин урамнан
Акча тапсам бер капчык,
Китәр идем кибеткә,
Иптәшләремнән качып.

Алыр идем шоколад,
Кесәләрем тулганчы.
Ашар идем туңдырма,
Авызларым туңганчы.

Кибетчеләр тәм-томны
Өлгермәс иде ташып.
Сыйланыр идем качып,
Бушап беткәнче капчык.

Юк ла, качып ашагач
Кызык булмас ул бер дә.
Дусларым белән җыелып
Сыйланам бергә-бергә.

Әй, дусларым, килегез,
Кемгә нәрсә аласы?
Калды бары бер капчык
Акча гына табасы.

*1995*

* * *

Акыллы фикер искерми,
Узса да күпме вакыт.
Тора аны заман үзе
Яңартып, ялтыратып.

Вакыт күбрәк узган саен,
Киңәйгән саен чикләр,
Югарырак кала бара
Акыллылар, бөекләр.

*1995*

* * *

Ак күгәрчен, күк күгәрчен
Урын сайлый ояга;
Үз урының табулары
Җиңел түгел дөньяда.

Ак күгәрчен, күк күгәрчен
Очалар офыкларга;
Тимәсме канат очлары
Күктәге болытларга.

Ак күгәрчен, күк күгәрчен
Гөрләшә гөлдер-гөлдер;
Бер генә бирелә яшәү,

Бер генә бирелә гомер.

*1995*

## АНАМ ТЕЛЕ

Татар теле — анам теле,
Иң борынгы бабам теле.
Буыннардан буыннарга
Күчеп килгән заман теле.

Ничә гасыр чарлангансың,
Матурайган, яңаргансың.
Халкыбызның күңеленнән
Җыр алгансың, моң алгансың.

Изелгәнсең, тапталгансың,
Пычратсалар, пакьләнгәнсең.
Милләтемнең үлмәс җанын
Син үзеңдә саклагансың.

Сиңа безнең язмыш сыйган,
Син кайгы һәм шатлык теле.
Татарымны татар иткән
Беренче һәм актык теле.

Анам теле — телләр теле,
Милләтемнең бердәнбере.
Син булганга без дә исән,
Син булганга без дә тере.

*1995*

## ТӨПЧЕК МАЛАЙ

Минем әни шундый әйбәт,
Мине бер дә орышмый.
Баштан сыйпап кына тора,
Бернинди дә эш кушмый.

Телим икән, уйнап керәм,
Телим икән, тик ятам.
Эшләр өчен чөнки минем
Бар абыем, бар апам.

Ә мин өйдә кече малай,
Ягъни мәсәлән, төпчек.
Ашыкмыйм әле үсәргә,
Ни файда бар соң үсеп?

Буем да кечкенә минем,
Хурланмыйм моңа һич тә.
Белеп торам: үсеп китсәм,
Йөгертәчәкләр эшкә.

*1995*

## НУЖА

Безнең бабай иелеп йөри,

Нидер эзләгәндәй астан.
Әни әйтә: бабагызны
Кечкенәдән нужа баскан.

Әгәр күрсәм, ул нужаның
Мин кирәген бирәм әле.
Бабабызны турайт диеп,
Өйгә алып керәм әле.

Турайтмаса, киреләнсә,
Бастырачакмын почмакка.
Минем нинди икәнемне
Белер ул менә шул чакта.

*1995*

## ЯВЫЗ ЧЕБЕН

Явыз чебен булган, ди,
Ул киртәгә кунган, ди.
Чебен килеп кунуга,
Киртә шартлап сынган, ди.

Аннан кунган капкага,
Авып төшкән капка да.
Чебенгә кызык икән,
Ул тәмам кызып киткән.

Таптап изгән чиләкне,
Аударган бер келәтне.
Агачларны сындырган,
Тәрәзәләрне кырган.

Дөресме бу, ялганмы,
Келәт, капка ауганмы? —
Ансын белмим үзем дә,
Тик хаклык бар сүземдә.

Яманлык эшләр өчен
Кирәкми акылың, көчең,
Аңа җитә юләрлек,
Бер котырып китәрлек.

Бер котырып киттеңме,
Анда бар да бетте инде:
Капка ега читәнне,
Читән ега бүтәнне.

Өй дә аварга мөмкин,
Таш та янарга мөмкин.
Яман эшне башлау җиңел,
Туктату гына читен.

*1995*

## ШУНСЫ НАЧАР

Әни миңа тун алды
Бик матурын, карасын.
Йокларга ятканда да

Килми аны саласым.

Шундый йомшак, җылы ул,
Гүя әнкәй кулы ул.
Үзе таман, килешле,
Гел үлчәп теккән төсле.

Бик әйбәт шул әнием,
Миңа матур тун алды.
Шунсы начар: әнинең
Үзенең туны югалды.

*1995*

* * *

Кошлар кунарга ярата
Электр чыбыгына.
Ышанып утыра алар
Куркыныч юклыгына.

Монда ток барлыгын белсә,
Бер кош та кунмас иде.
Барысын белеп гел курыксаң,
Яшәп тә булмас иде.

*1995*

## ОЗАК-ОЗАК ЯНАЧАК

Кеше бит ул — бер учак:
Утынын сала торсаң,
Көлләрен ала торсаң,
Бераз кузгатып куйсаң,
Утын уятып куйсаң,
Давылдан саклый алсаң,
Явымнан каплый алсаң,
Сүнгәндә өргәләсәң,
Яңа көч биргәләсәң,
Күмерен таратмасаң,
Урынын яңартмасаң,
Таш белән бастырмасаң,
Боз белән катырмасаң,
Ялкыннарың үрләтсәң,
Күмерләрен дөрләтсәң,
Бу учак
Озак-озак яначак.

*1995*

* * *

Зур дәрьялар кичтем диеп
Тынычланма, күңелем.
Алда тирән диңгезләр бар,
Калуың бар күмелеп.

Күкләргә менгән чакта да
Шашынма, җан, ул чаклы.
Күккә менеп җитеп булмый,
Күкләр бит җиде катлы.

Мең сынау аша үтсәң дә,
Гел бер уй булсын анда:
Әле тормыш сынавының
Иң авырлары алда,
Иң авырлары алда!

*1995*

## БЕТМӘС

Болыннарның яме бетмәс,
Җирдә гөлләр барында.
Гүзәлләрнең кадере бетмәс,
Илдә ирләр барында.

Илдә батыр ирләр бетмәс,
Җирдә көрәш барында.
Җирдә әле көрәш бетмәс,
Күзләрдә яшь барында.

*1995*

## КАНАТЛЫ ЕГЕТ

*(Моңсу әкият)*

Бу хәлләр булган элек,
Ләкин сөйлимен белеп.
Булмаган әле ул чакта
Ярлылар да, байлар да.
Болай диеп аталмаган
Еллар да һәм айлар да.
Игеннәр дә чәчмәгәннәр,
Булмаган сука-сабан.
Өйләр булган тау куышы,
Тумаган җиргә ялган.
Кешеләр бер-берләренә
Гел дөрес сүз сөйләгән.
Дөньяда алдашу барын
Бер кеше дә белмәгән.
Менә шундый заманнарда
Җиргә туган бер батыр.
Көче аның башкалардан
Артык булган йөз тапкыр.
Иңнәрендә булган аның
Көчле ике канаты.
Йөзе аның балкып торган
Кояш кебек яп-якты.
Иңдә канатлары булгач,
Йөргән ул очып кына.
Бөркетләр белән ярышып,
Офыклар кочып кына.
Һәр көн ауга йөргән Батыр
Башкалар белән бергә.
Аулар гел уңышлы булган
Бу Батыр барган җирдә.
«Эһ» дигәнче куып тоткан
Урманда киекләрне.

Көче белән шаккатырган
Ул барлык егетләрне.
Үзенең дуслары белән
Ни тапса да, бүлешкән:
Олыны да, кечене дә
Калдырмаган өлештән.
Һәркем үз баласы кебек
Яраткан аны, сөйгән.
Ил картлары да олылап
Аңарга башын игән.
Һәр ана «улым» дип йөрткән,
Көчсезгә булган терәк.
Картлар дога укыганнар
Аңа исәнлек теләп.
Шулай яшәгән бу Батыр
Дан белән, хөрмәт белән.
Саф, чиста күңел белән һәм
Намуслы хезмәт белән.
Бервакытны йөргән чакта
Ялгызы гына ауда,
Бер бик чибәр кыз күргән ул
Таныш булмаган тауда.
Бу кыз шундый гүзәл икән,
Безнең Батыр таң калган.
Кыз бер күренеп алган да
Әллә кая югалган.
Эзләгән канатлы Батыр
Аны биек таулардан.
Ул менмәгән һичбер кыя,
Һичбер тау да калмаган.
Ишетелеп куйгалый, ди,
Кайчак кызның көлгәне.
Тик аерып булмый икән
Тавыш каян килгәнне.
Әле уңда, әле сулда
Ишетелә, ди, тавыш.
Егет эзләп арып беткән,
Йөзенә чыккан сагыш.
Утырган ул тауга менеп,
Түбәнгә иеп башын.
Ярсудан кубарып алган
Тауның бер кыя ташын.
Һәм ни гаҗәп: әлеге таш
Әйләнгән чибәр кызга.
Якынайган йөзләр йөзгә,
Текәлгән күзләр күзгә.
Кыз шулкадәр гүзәл икән —
Күзнең явын алырлык.
Аның янында кояш, ай
Тоныкланып калырлык.
Озак торганнар карашып
Болар бер-берләренә.
Мәхәббәтләре нур булып
Тулган күңелләренә.
Кыз әйткән шунда егеткә:
— Гайрәтең чиксез икән!
Яр ит син мине үзеңә,
Мин синең белән китәм.
Тик белеп тор: бер шартым бар —
Чыкмаска минем сүздән.

Мин кая гына барсам да,
Йөрергә минем эздән.
— Мин бик риза, — дигән егет, —
Теләсәң, булам колың.
Тик минеке генә бул син,
Бир миңа тизрәк кулың.
Алып кайткан егет кызны,
Кулларына күтәреп.
Туй ясаганнар гөрләтеп,
Сыйлар булган җитәрлек.
Туйдан соң әйткән егеткә
Гүзәл кыз, назлы итеп:
— Чәчәкләрдән бишек үреп
Йоклат мине тирбәтеп.
Мин тауларның иркә кызы,
Гел назлауга өйрәндем.
Зифа каеннарга менеп,
Җилләр белән тирбәлдем.
— Ярар, — дигән батыр егет,
Киткән бишек үрергә.
Әзер булган кыз өчен ул
Җанын ярып бирергә.
Кояш баеп өлгергәнче
Бишек беткән үрелеп.
Ботакка элгәч, һәркемгә
Торган, ди, ул күренеп.
Кыз кереп яткан бишеккә,
Егет тирбәтеп торган.
Назлы күзләр йөрәктәге
Дәртне дөрләтеп торган.
Егет сунарга барырга
Җыена башласа әгәр,
Кыз чирлегә сабыша икән,
Шундыйга киткән хәлләр.
Егет башта бу хәлләргә
Йөрсә дә бик пошынып,
Тиз күнеккән. Эшкә җаны
Тормаган гел очынып.
Беркөн ырудаш дуслары
Чакырган аны ауга:
— Син генә юлны беләсең
Теге Диюле тауга.
Барыйк әле әйдә шунда, —
Дигән аңа егетләр, —
Анда бит шундый күп була
Төрле-төрле киекләр.
Син бармагач, никтер безнең
Юллар уңмый башлады.
Эзтабар эт Акбайны да
Бүре тотып ашады.
Батыр егеткә сөйгәне
Пышылдаган: «Юк, барма!»
Егет түбән карап әйткән:
— Бара алмыйм шул ауга.
Чирләп торам, һич хәлем юк,
Сәбәбе нидер, белмим:
Беркөнне күкрәгем сызлый,
Икенче көнне — билем.
Дуслары Дию тавына
Киткән үзләре генә.

Һәм Дию йоткан аларны,
Калган эзләре генә.

Ни гаҗәптер: шушы көннән
Егет авырый башлаган.
Йокысы качкан. Тамакка
Бик әз генә ашаган.
Иң авыры — аның җаны
Бәргәләнгән күкрәктә.
Батыр егет хәлсезләнгән,
Калган коры сөяккә.
Тора-бара канатлар да
Сынып төшкән иңеннән.
Көчкә генә тора икән
Хәтта яткан җиреннән.
Аптыраган егет моңа
Һәм барган Аксакалга.
Сораган:
— Миңа ни булды?
Һич урын тапмыйм җанга.
Канатларым да сындылар,
Күрмим дөнья ямьнәрен.
Гәүдәмә таш аскан кебек
Авырайды тәннәрем.
Аксакал уйлап торган да
Үз сүзен әйтеп салган:
— Беләсеңме, егеткәем,
Син бит тудырдың ялган.
Ә ялган ул — күңелгә таш,
Ташның да иң авыры.
Аны канат күтәралмый,
Юмый вакыт яңгыры.
Киткән егет ау иленә,
Башын түбән игән дә
Һәм кыядан ташланган ул
Упкынга, бик тирәнгә.
Егетнең хәлсез гәүдәсен
Упкыннар үзенә алган.
Әмма тирән упкыннан да
Үрелеп чыккан ялган.
Шуннан башлап җирдә ялган
Ишәйгәннән-ишәйгән.
Хаклык көчсезләнгән саен,
Ялган һаман көчәйгән.
Ә бит үзе туган иде
Изге генә нияттән.
Ләкин җенне кертеп булмый,
Бер чыгарсаң чүлмәктән.
Әкиятем моңсу бетте,
Кичерегез, дусларым.
Ләкин нишлим, ялганларга
Кушмый миңа вөҗданым.

Ә ялганга, дусларым,
Корыгыз нык читәнне.
Онытмагыз: тел — явыз җен,
Авыз — чүлмәк икәнне.

*1964–1996*

## САГЫНАМ ШУЛ ЧАКЛАРНЫ

Ике катлы йорт салдык без,
Бар аның ун бүлмәсе.
Өске катка борма-борма
Баскычлардан менәсе.

Әллә каян күренеп тора,
Матур безнең өебез.
Тик кайвакыт бер-беребезне
Көне буе эзлибез.

Әле әтием «югала»,
Әле әни «югала».
«Югалырга» туры килә
Кайвакытта миңа да.

Рәхәт иде яшәгәндә
Өчебез бер бүлмәдә.
«Югалырга» мөмкинлек юк
Иде һичбер кемгә дә.

Сагынам шул чакларны,
Калганбыз рәхәт яшәп.
Ярый инде берәм-берәм
«Югалышып» бетмәсәк.

*1996*

## СЕЗ КИРӘК

Без юлларга чыктык кына,
Күңелдә якты теләк.
Иң дөрес, иң туры юлны
Сайлашырга сез кирәк.

Алда көрәшләр дә булыр,
Югалып калсак кинәт,
Егылганда тотынырга,
Көч бирергә сез кирәк.

Сүнгән чакта өметебез,
Калмаган чакта терәк,
Күз яшьләрен сөртә-сөртә
Юатырга сез кирәк.

Боекмас өчен күңелләр,
Кимсенмәс өчен йөрәк,
Сез кирәк, әти-әниләр,
Безгә һәрчак сез кирәк.

*1996*

## БЕР ДӘ РӘХМӘТ ӘЙТМИЛӘР

Шулай булып туганмын мин,
Эшләп торам тук та тук.
Кулларыма корал алсам,
Булмый мине туктатып.

Беркөнне телевизорның
Сүтеп алдым да эчен,
Бик шәп тартма ясап куйдым,
Бәрәңге салыр өчен.

Урындык аякларын да
Кыскарткалап торам мин.
Өстәл өстен балта белән
Шомарткалап торам мин.

Обойларга матур-матур
Рәсемнәр ясап куям.
Ишекләргә пычак белән
Чокыр-чакырлар уям.

Дус-ишләрем мактый мине:
Булдырасың, шәп, диләр.
Тик әти-әниләр генә
Бер дә рәхмәт әйтмиләр.

*1996*

## ЭШНЕҢ АНЫҢ БЕРНИЕ ЮК

Эшнең аның берние юк,
Мин курыкмыймын эштән.
Бакча казырга да була,
Чабарга мөмкин печән.

Өй салу да кыен түгел,
Бер тотынгач бара ул.
«Кис» дисәң, балта кисә ул,
«Яр» диденңме, яра ул.

Бер эшнең кыенлыгы юк,
Һич ялганлап әйтмимен.
Чөнки карап торганым бар
Эшләгәнен әтинең.

*1996*

## КУНАК КЫЗЫ ШИКЕЛЛЕ

Самавыр агарттым әле,
Су буена төштем дә.
Әй эшләдем, әй тырыштым
Җен кергәндәй эчемә.

Комнар белән ышкыдым да
Аккан суда юдырдым.
Ике колагыннан тотып
Кабат-кабат чумдырдым.

Матур булды самавырым,
Сары нурлар сибелде.
Карап кына торырлык ул,
Кунак кызы шикелле.

*1996*

## КОШЛАРЫБЫЗ НИ ЭШЛӘР

Яңа йортка күченәбез,
Өйдәгеләр бар да шат.
Тутыралар әйберләрне
Тартмаларга шалт та шалт.

Ләкин мин бу иске йорттан
Һич теләмим күчәргә.
Монда торып калыр өчен,
Белмим инде нишләргә.

Озакка түгел, бер айга
Калдырсалар да ярый.
Әмма минем әйткән сүзгә
Кем карый соң, кем карый?

Әти әйтә:
— Бу иске йорт
Күптән тузды инде, — ди, —
Шуның тишекләрен ямап
Гомер узды инде, — ди.

Әни дә аңа кушыла:
— Яңа өй шәп булачак.
Биектәге тәрәзәгә
Кояш төшеп торачак.

Кайнар суын, ваннасын
Тормыймын,  — ди, — санап та.
Лифт белән менәсең, — ди, —
Теләсә кайсы катка.

...Әйберләрне берәм-берәм
Бетергәчтен тутырып.
Әйтте әни:
— Берәр нәрсә
Калмый микән онтылып?

— Кала! — дидем мин әнигә, —
Кала, бер нәрсә кала:
Өй кыегында оя бар,
Ул ояда өч бала.

Без китүгә бу урынны
Бульдозерлар тигезләр,
Безнең кыекка урнашкан
Кошларыбыз ни эшләр?!

*1996*

## АЛМАГАЧНЫҢ ҮПКӘСЕ

Күршеләрнең алмагачы
Шау чәчәктә утыра.
Безнең алмагачлар гына
Бер чәчәксез буш тора.

Сорадым мин алмагачтан:
«Нигә чәчәк атмадың?

Иңнәреңә нигә син дә
Ак шәлеңне япмадың?»

Җавап бирде алмагачым:
«Минем сезгә үпкәм бар:
Ботакларымны кистегез
Ачылсын дип түтәлләр.

Мин бит көзен сезгә бик күп
Алмалар биргән идем.
Алмаларым күп булганга
Башымны игән идем.

Хәзер менә сызланамын,
Төзәлми яраларым.
Төзәлмичә яраларым,
Булмас шул алмаларым».

Шулай диеп алмагачым
Миңа әйтте үпкәсен.
Белмим инде аның безне
Кайчан гафу итәсен.

*1996*

* * *

Кошлар китә, кошлар кайта,
Кошларны кем санаган:
Бәлки, аларның да барсы
Кайталмыйдыр яңадан.

Кошлар китә, кошлар кайта,
Кошлар урый дөньяны.
Юлларда янып каладыр
Канатлары сынганы.

Кошлар китә, кошлар кайта,
Нәрсә йөртә кошларны?
Әллә юллар баса микән
Сагыну-сагышларны?

Кошлар китә, кошлар кайта,
Һавада — кошлар юлы.
Йолдызлардан саркып-саркып
Тарала кошлар моңы.

*1996*

* * *

Агач телләр дә була,
Тасма телләр дә була.
Агач телләр күсәктәй,
Тасма телләр ефәктәй.
Егылабыз күсәктәй.
Буылабыз ефәктәй.

*1996*

## РӘХМӘТ СЕЗГӘ, АПАЛАР

*(Балалар бакчасында тәрбияләнүче нәниләрнең чыгарылыш кичәләре өчен кечкенә тамаша)*

Вакыйга балалар бакчасында бара. Зур бүлмә. Анда пианино, уенчыклар һәм барлык бакчаларда була торган кирәк-яраклар. Тамаша башланыр алдыннан барлык балалар түгәрәк ясап зал уртасына тезелгән.

Уртага бер бала чыга.

Беренче бала.

Без әле бик нәни идек,
Инде үстек, зур булдык.
Сезнең күзләрдә чагылган
Якты булдык, нур булдык.

Икенче бала.

Өйрәттегез еламаска,
Өйрәттегез көләргә.
Өйрәттегез тагын бик күп
Төрле-төрле һөнәргә.

Өченче бала.

Без бии дә беләбез,
Без җырлый да беләбез.

Хор белән.

Хәзер сезгә «Туган тел»не
Бергә җырлап бирәбез.

Пианино янында утыручы музыка укытучысы «Туган тел»не уйный.
Балалар Габдулла Тукайның «Туган тел»ен җырлыйлар.

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Балалар «Туган тел» җырын ахырынача җырлыйлар. Шунда бер тәрбияче аларга болай дип мөрәҗәгать итә.

Тәрбияче. Ә хәзер, балалар, тел турында кайбер мәкальләр, әйтемнәрне искә төшереп алыйк. Йә, кайсыгыз башлый?

Беренче бала. Акылы кысканың теле озын.
Икенче бала. Телең белән узма, белем белән уз.
Өченче бала. Сүз бер көнлек, тел гомерлек.
Дүртенче бала. Татлы тел тимер капканы ачар.
Бишенче бала.

Телеңне тезгендә тот,
Этеңне чылбырда тот.

Алтынчы бала.

Тел — күңелнең көзгесе.

Җиденче бала.

Теле барлар халык булган,
Теле юклар балык булган.

Сигезенче бала.

Колак икәү, күз икәү,
Ләкин телем бер генә.

Тугызынчы бала.

Теленә салынган

Эшендә абынган.

Унынчы бала.

Бит күрке — күз,
Тел күрке — сүз.

Унберенче бала.

Озын тел — еландыр,
Муеныңа уралыр.

Тәрбияче. Рәхмәт, балалар. Тел турында бик акыллы сүзләр беләсез икән.

Беренче бала.

Без бит инде бик зур үстек,
Без барын да беләбез.
Елар чаклар артта калды,
Хәзер уйнап-көләбез.

Икенче бала.

Күңелләрдән һич тә китмәс
Биргән сабакларыгыз.
Һәр көн саен ныгый барыр
Очар канатларыбыз.

Өченче бала.

Көйсезләнсәк, еласак та,
Сез гел сабыр булдыгыз.
Безнең баштан сыйпап торды
Сезнең йомшак кулыгыз.
Дүртенче бала.

Рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт,
Тәрбияче апалар.
Бездән соң да шаулап торсын,
Гөрләп торсын бакчалар.

Бишенче бала.

Тик сез берүк без китә дип
Ямансулап калмагыз.
Без бит хәзер зурлар булдык,
Без мәктәпкә барабыз.

Алтынчы бала.

Әйе, безне мәктәп көтә,
Кыңгыраулы зур мәктәп.
Ә бу юлга безне бит сез
Чыгардыгыз җитәкләп.

Җиденче бала.

Анда да без сынатмабыз,
Менә күрерсез әле.
Болар безнең бакчаныкы
Диеп йөрерсез әле.

Сигезенче бала.

Уйларга өйрәттегез,
Уйнарга өйрәттегез.

Тугызынчы бала. Әйдәгез, апаларга бер уйнап та күрсәтик инде.
Унынчы бала. Нәрсә уйныйбыз?
Унберенче бала. Аптыратышлы уйныйк.

Берничәсе. Әйдәгез, әйдәгез, аптыратышлы уйныйк.
Берсе *(алга чыгып)*. Аптыратыйммы?
Икенчесе. Аптырат.
Сорау бирүче. Аптырат кайда?
Җавап бирүче. Башымда.
Сорау бирүче. Башың кайда?
Җавап бирүче. Муенда.
Сорау бирүче. Муенның кайда?
Җавап бирүче. Иңемдә.
Сорау бирүче. Иңнәреңдә тагын ни бар?
Җавап бирүче. Иңнәремдә куллар бар.
Сорау бирүче. Кулларыңда ниләр бар?
Җавап бирүче. Кулларымда бармак бар.
Сорау бирүче. Бармакларың ничәү?
Җавап бирүче. Һәр кулымда бишәү.
Сорау бирүче. Бармакларың ни исемле?

Алгарак биш бала чыга.

Беренчесе.

Мин баш бармак буламын.
Калган барлык бармакларга
Әмер биреп торамын.

Икенче бармак.

Ә мин имән бармак булам.
Бөкрәйсәм, кармак булам.
Баш бармакның бөтен эшен
Мин генә җайлап торам.

Өченче бармак.

Мине урта бармак диләр.
Буем озын, үзем чибәр.
Әле минем шәплегемне
Белеп кенә бетермиләр.

Балалар дүртенче бармак янына киләләр. Аны алгарак чыгарырга телиләр.

Дүртенче бармак.

Ә мин... Ә мин... *(еламсырап)*
Онытканмын исемемне.
Әнкәм кем дип җырлагандыр
Тирбәткәндә бишегемне.

Бишенче бармак.

Минем исемем чәнчә бармак,
Мине саклый барча бармак.
Шуңа үстем иркә булып,
Эшләмимен иртә торып.

Барлык бармаклар бергә җыела.

Баш бармак. Әйдәгез, ботка пешерәбез.
Имән бармак. Ярма юк бит.
Урта бармак. Әҗәткә алырбыз.
Исемсез бармак. Аны кайчан түләрбез?
Чәнчә бармак. Түләмәбез, ашарбыз да качарбыз.
Баш бармак. Качсак, тиз тотылырбыз.
Имән бармак. Хәйлә белән котылырбыз.
Урта бармак. Котылмасак, нишләрбез?

Исемсез бармак. Үзебез тары чәчәрбез.
Чәнчә бармак. Курыкмыйча яшәрбез.
Тәрбияче. Бармаклар дөрес әйтәме, балалар?
Хор. Дөрес, дөрес.
Тәрбияче. Хәзер ял итеп алабызмы әллә... арыгансыздыр инде.
Балалар. Юк, юк, арымадык.
Берсе алга чыгып. Сез бит безне өйрәттегез...
Хор. Нык булырга.
Бала. Арыганда бер-беребезгә тотынырга...
Хор. Тотынырга.
Бала. Ялгышмаска, карышмаска...
Хор. Алдашмаска.
Бала. Кояшка карап юл табарга...
Хор. Адашмаска.
Тәрбияче. Рәхмәт сезгә, балалар, рәхмәт. Ә хәзер, әйдәгез, «Саубуллашу» җырын җырлыйк.

Музыка укытучысы пианино янына утырып көй уйный. Балалар
җырлый.

Сау бул инде, гүзәл бакча,
Безнең җылы оябыз.
Синдә үсеп канат ярдык,
Инде юлга чыгабыз.

Гөлләр булып сибелербез,
Су булып түгелербез.
Кошлар булып очып китеп,
Офыкка күмелербез.

Алып менәр йолдызларга
Монда үскән канатлар.
Йолдызлардан тезәрбез без
Барыр юлга маяклар.

*1996*

## ӘКИЯТ КЫЗЫ

*Чаллы кызы Гүзәл Шәйхетдиновага багышлыйм*

Борын-борын заманнарда
Хыялый бер кыз булган.
Әткәсенә, әнкәсенә
Каш астында күз булган.
Бик зиһенле, бик акыллы,
Шигъри җанлы булган ул.
Туганда ук гөлдер-гөлдер
Шигырь сөйләп туган ул.
Шигырьләр сөйләп озаткан
Аккан болытларны да.
Шигырьләр сөйләп юаткан
Күңеле сыныкларны да.
Көлдергән дә, елаткан да —
Бөтенесен булдырган.
Әйтерсең лә телләреннән
Сандугачлар очырган.
Ул очырган сандугачлар
Барып кунган гөлләргә.
Һәм гөлләр дә тотынган, ди,
Көн-төн шигырь сөйләргә.
Шигырьләрен йолдыз итеп

Чөйгән кызый һавага.
Кайберләрен җилгә биреп
Җибәргән ул далага.
Теләгән кыз шигырьләре
Җиһанга сибелүне.
Кешеләрнең күңелләре
Җыр-моңга күмелүне.
Очып барган кошларны да
Шигырь белән «сыйлаган».
Ә кичләрен курчакларга
Мондый җырлар җырлаган:
«Әлли-бәлли, курчакларым,
Матурларым, йомшакларым.
Йоклагыз сез төшләр күреп,
Ай-йолдызлы кичләр күреп.
Йокы бит ул балдан татлы,
Йокы бит ул майдан татлы.
Әлли-бәлли, курчакларым,
Йоклагыз сез, йомшакларым».
Курчакларын йоклаткачтын,
Калгачтын дөнья тынып.
Айга карап җырлаган ул,
Югарыга омтылып:
«Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап
Шигырь сөйлисем килә.
Ай югары, ай югары,
Айга менгән юк әле.
Айга менеп, шигырь сөйләп
Йөргән көннәр юк әле».
Кызның моңаеп җырлавын
Ишеткән дә төнге җил
Очып килгән кыз янына,
Әйдә, дигән, илтәм, кил.
Һәм илтеп тә куйган кызны
Айның нәкъ уртасына.
Йолдызлар җыелган җиргә —
Иң якты ноктасына.
Зөһрә кыз да шунда икән,
Көянтәсе иңендә.
Чәчләре сибелеп тора, ди,
Айның талгын җилендә.
«Әй, Зөһрә кыз, ни хәлең бар,
Талмадымы иңнәрең?
Көянтәңне бирче миңа,
Сугарыйм Ай гөлләрен!
Син беразга ял итеп тор,
Суларыңны мин ташыйм.
Синең баскан эзләреңә
Инде хәзер мин басыйм».
Шулай дигән дә Җир кызы
Аскан көянтә-чиләк.
Киткән йөгерә-йөгерә суга,
Ай сукмакларын иңләп.
Аяклары тыпыр-тыпыр
Биеп баралар икән.
Чиләгеннән чәчәкләргә
Сулар тамалар икән.
Ә йолдызлар куллар чабып

Такмак әйтеп тора, ди.
Билләрен кыз әле уңга,
Әле сулга бора, ди.
«Бас, бас, бас әле,
Без дә басарбыз әле.
Урталарга чыгып басып
Күңел ачарбыз әле.
Бас, бас катырак,
Дөнья булсын шатрак.
Синең баскан эзләреңнән
Чишмә чыксын чылтырап».
Биегән кыз тыпыр-тыпыр
Асып көянтә-чиләк.
Аның баскан эзләрендә
Кызарып пешкән җиләк.
Кыз ул пешкән җиләкләрне
Йолдызларга өләшкән.
Йолдызларның күңеле тулган,
Күзләре җемелдәшкән.
Аннары кыз тып-тып басып
Ай читенә килгән дә
Шигырьләр сөйли башлаган,
Карап җиргә, түбәнгә:
«Исәнмесез, җирдәшләрем,
Кардәшләрем, иптәшләрем!
Исәнмесез, урман-сулар,
Исәнмесез, борма юллар,
Исәнмесез, былбылларым,
Якыннарым, күз нурларым.
Исәнмесез, офыкларым,
Исәнмесез, болытларым!
Исәнмесез, барчагыз да,
Исән генә торасызмы?
Сөрәсезме, чәчәсезме,
Сугасызмы, урасызмы?
Бәйлисезме, тегәсезме,
Елыйсызмы, көләсезме?
Бу минутта нишлисез сез,
Сөенәсезме, көенәсезме?
Сәлам сезгә Ай, йолдыздан,
Сәлам сезгә Зөһрә кыздан.
Сәлам сезгә бик ерактан,
Сәлам сезгә чын йөрәктән.
Бәхет телим барчагызга,
Уңыш телим барчагызга.
Алма булып бәхет пешсен
Тормыш дигән бакчагызда».
Шундый шигырь сөйләгән, ди,
Айдан торып гүзәл кыз.
Аның шигырь сөйләгәнен,
Бәлки, сез дә күргәнсез?!
Әгәр күрмәгән булсагыз,
Менә ул — алдыгызда.
Шигырьне чәчәкләр итеп
Өләшәм барыгызга.
Алыгыз, ал, тартынмагыз,
Кадагыз түшегезгә.
Мин әкият кызы булып
Керермен төшегезгә.

*1997*

## СӘВИЯ НИГӘ ЕЛАГАН

Июль дигән ай булган,
Җирдә гүзәл җәй булган.
Җәйне мактап көн вә төн
Былбыллар сайрап торган.
Күктә кояш нур сипкән,
Җилләр җиргә җыр сипкән.
Ташып торган яктылык
Җирне-күкне бер иткән.
Менә шундый бер айда,
Менә шундый бер җәйдә
Сәвия дигән кыз туган,
Ул кыз бик елак булган.
Көне-төне елаган,
Өзмәгән дә куймаган.
Елый-елый ул шулай
Бар авылны җыйнаган.
Килгән әби-бабайлар,
Килгән кызлар, малайлар.
Ник елыйсың, дигәннәр,
Конфет-прәннек биргәннәр.
Сәвия туктамаган,
Төннәрен йокламаган.
Күз яшеннән күл булган,
Күлнең суы мул булган.
Анда йөзгән аккошлар,
Тагын бик күп ят кошлар
Канат кагып бу күлдә
Тудырганнар балкышлар.
Сәвия һаман елаган,
Өзмәгән дә куймаган.
Кояш үбеп яшьләрен
Киптерергә уйлаган.
Җилләр биргән кулъяулык,
Офыктан кисеп алып.
Кошлар җыелып килгәннәр,
Яшеңне сөрт, дигәннәр.
Сәвия барсын аңлаган,
Әйтә генә алмаган:
Аягым авырта, дип,
Мине шул елата, дип.
Менә шулай, дусларым,
Сәвия шуңа елаган.
Ә кешеләр Сәвияне
Елак кыз дип уйлаган.
*1997*

## ГЫЙНВАР БАБАЙ

Үтеп бара әнә Гыйнвар бабай,
Кар өстеннән шыгыр-шыгыр атлап.
Сакалларын җилләр җилфердәтә,

Керфекләрен бәсләр сарган ап-ак.

Як-ягына борылып карамый ул,
Уе бик тә еракларга киткән.
Иңнәренә аның карлар булып
Шыбыр-шыбыр йолдыз ява күктән.

Бара гыйнвар горур гына атлап,
Адымнары авыр һәм дә салмак.
Сакчылары боз-сөңгеләр тотып
Як-ягыннан бара аны саклап.

*1997*

## ГӨЛШАТ

Гөлшат карый көзгедән,
Канәгать ул үзеннән:
Бөтен җире килешле,
Әкияти кыз төсле.

Керфекләре, кашлары ла —
Чәчәкләрнең таҗлары.
Кара кашына карасаң,
Әйләнәчәк башларың.

Йөзләрендә яз яктысы,
Ә күзләре — сүзсез җыр.
Бу күзләрне сурәтләргә
Шагыйрьләрдә сүз юктыр.

Түшләрендә пар сандугач
Канат кагарга тора,
Битләрендә ике кояш
Балкып янарга тора.

Иреннәре — алсу чәчәк,
Таңнар үбеп туймаслык,
Ашкынуы — ярсу диңгез,
Йөрәкләргә сыймаслык.

Көзгедән карый Гөлшат,
Аның күңеле бик шат.
Аны чакырып кул изи
Мәхәббәт дигән учак.
*1997*

## БУЛГАН ӘЙБӘТ ЗАМАННАР

Борын-борын борында
Булган әйбәт заманнар.
Кешеләр бер-берләренә
Кунакларга барганнар.

Бәйрәмнәрдә котлашып
Матур хатлар язганнар.
Авыллардан — шәһәрләргә,
Шәһәрләрдән авылларга
Посылкалар салганнар.

Бар да әйбәт булганнар,
Бар да юмарт булганнар.
Хәтта куяннар да элек
Тәмле күчтәнәчләр биреп
Җибәргәннәр урманнан.

Үзгәрделәр әбиләр,
Үзгәрделәр әниләр.
Хәзер инде куяннар да
Ерак-ерак урманнардан
Күчтәнәч җибәрмиләр.

*1997*

## КҮКЕ

Нигә кычкыра күке?
Ул әйтә: җәйләр җитте.
Исәнмесез, кошлар, ди,
Исәнмесез, дуслар, ди.

Берәү, икәү, өчәү, ди,
Дусларым, сез ничәү? ди.
Армадыгызмы юлда?
Оягыз бармы монда?

Әгәр булса оягыз,
Сез дә, без дә сыярбыз.
Мин кунакка барырмын,
Бер йомырка салырмын.

Курыкмагыз миннән, ди,
Мин беркемгә тимәм, ди.
Йомыркамны сакларсыз,
Әгәр килсә тилгән, ди.

Күк-кү, күк-кү, кошларым,
Йомшак түшле дусларым.
Мин сезне бик сагындым,
Кайсыгызга барыйм соң?
Күк-кү!
Күк-кү!

*1997*

## ЭЛЕМТӘЧЕ ҮРМӘКҮЧ

— Бер чәчәктән бер чәчәккә
Җеп сузасың, үрмәкүч.
Әйтче миңа, ул җепләрне
Ник сузасың, үрмәкүч?

— Ник сузаммы? Бу бит, дустым,
Телефон чыбыклары.
Телефонсыз белеп булмый
Дөнья яңалыкларын.

Сөйләшсеннәр, серләшсеннәр,
Чәчәкләр үз телендә.

Телефон бик кирәк була
Көнен дә һәм төнен дә.

Дөнья бит бу, ә дөньяда
Төрле хәл булып тора:
Йә кыраулар өтеп ала,
Йә давыл кубып тора.

Авыр чакта дусларыңны
Чакырасың ярдәмгә.
Телефонсыз ярыймыни
Шундый озын җәйләрдә.

*1997*

## ЧЫПЧЫКЛАР

Бер чыпчык әйткән дустына:
«Әйдә болай итәбез —
Без дә сыерчыклар кебек
Җылы якка китәбез.

Юкса безгә һичбер сан юк,
Көтмиләр оя ясап.
Данлы, санлы булыр идек,
Көз китеп, язын кайтсак».

Бу чыпчыклар шулай уйлап
Юлга чыгып киткәннәр.
Көн киткәннәр, төн киткәннәр —
Шактый ара үткәннәр.

Арыганнар, алҗыганнар,
Яңгырга юлыкканнар.
Алларында диңгез күргәч,
Коточкыч курыкканнар.

Һәм кирегә бөкләгәннәр...
Ә диңгез калган көлеп:
«Дан алулар, сан алулар
Җиңел түгел шул», — диеп.

*1997*

## ҮСӘМ!

Әй яңа көн, яңа көн,
Син исәнме? Мин исән!
Кояш исән, Ай исән!
Мин сөенәм син килсәң.

Җир исән дә, ил исән,
Анам биргән тел исән.
Җир өстендә гөл булып
Ай үсәсен көн үсәм.
Үсәм!

*1997*

* * *

Апам белән икебез
Без бертигез эшлибез:
Мин өйне чүпләп торам,
Ә апам җыештыра.

* * *

Күңелеңдә болыт булса,
Яңгыр булып явачак.
Күңелеңдә шатлык булса,
Кояш булып яначак.

*1997*

## ӘЙБӘТ ПЕСИ

Песи алып кайттым әле
Беркемнән дә сорамый.
Песикәем тырнамый да,
Мыр-мыр итеп мырламый да,
Аякка да уралмый.

Әтигә дә ошады ул,
Әнигә дә ошады.
Нигә алып кайттың, диеп,
Берсе дә орышмады.

Әйбәт шул ул, бик тәртипле,
Пычратмый һич өйне.
Ашамый да, эчми дә ул,
Чөнки ул тал песие.

*1997*

## ЧЕРКИЛӘР ҖЫРЫ

Без-з, без-з, черки без,
Без бит уйнап йөрмибез.
Бик җаваплы эшебез,
Бик саваплы эшебез.
Анализлар алабыз,
Уколлар да салабыз.
Чирлене терелтәбез,
Ялкауны йөгертәбез.
Тишәбез дә керәбез,
Очлы безнең энәбез.
Безнең гомер бик кыска,
Безгә юкка тимәгез,
Ти-мә-гез-з!
Без-з-з!

*1997*

* * *

Күкләр була җиде катлы,
Һәрбер катында — капка.

Капкаларда фәрештәләр
Бик уяу тора сакта.

Күкләргә менүләр авыр,
Күкләрнең юк баскычы.
Һәркемнең үз йөрәгендә
Күк капусы ачкычы.

*1997*

## ЭТЮД

Чәчәкләр бии болында,
Җил курай уйнап тора.
Ак каен да сикереп төшеп
Биергә уйлап тора.

Итәкләрен чеметеп тоткан,
Чакыру гына көтә.
Тик әле кавалер гына
Йөри кайдадыр читтә.
Чәчәкне күрми үтә.

*1997*

* * *

Күктә йолдызлар шундый күп:
Тоныгы, яктысы бар.
Һәркайсының үз урыны,
Үз төсе — чаткысы бар.

Кояш та бар күктә, Ай да,
Этешми берсе берсен.
Күкләрнең күңеле бик киң,
Сыйдыра бөтенесен.

*1997*

## НИ БАР АННАН ТАТЛЫРАК?

Баш та авырта кебек,
Эч тә авырта кебек.
Кай җиремнең авыртканын
Булмый гына бит белеп.

Тәнем кайнар да кебек,
Кайнар түгел дә кебек.
Хәлем авыр да кебек,
Хәлем җиңел дә кебек.

Өйдә каласы да килә,
Мәктәпкә барасы да.
Йоклап аласы да килә,
Урамга чабасы да.

Нишләргә дә белгән юк,

Беттем инде аптырап.
Әй, ятып йоклыйм әле, —
Ни бар аннан татлырак?

*1997*

## АРЫЛДЫ

Әнием, төшемдә бүген
Бик күп эшләр эшләдем:
Керләр юдым, аш пешердем,
Тутырдым су кисмәген.

Ишегалларын себердем,
Су сиптем кыярларга.
Үлән йолкып алып кайтып
Ашаттым куяннарга.

Әй арылды, әй арылды —
Эттән болай арылды.
Бүген, әнием, син бер эш тә
Кушма миңа, ярыймы?

*1997*

## БӘРЕП ЧЫГА БИТ УЛ ЙӨЗЛӘРГӘ

Ике яшь кыз шайтан уены тапты,
Булмаса да шайтан затыннан:
Үткән-сүткәннәрнең башларына
Төкереп калды алар балконнан.

Төкерекләре башка төшкән саен,
Шатлык белән тулды эчләре.
Шул уенны уйнап үтә торды
Бу кызларның иртә-кичләре.

Астагылар бармак янасалар,
Посты алар балкон читенә.
Һәм ярыкка авызларын куеп
Төкерделәр кеше битенә.

Әй көлделәр алар, әй көлделәр,
Үз эшләре белән масаеп.
Көлә торгач гүзәл бу кызларның
Авызлары калды чалшаеп.

Әкият бит бу, диеп уйламагыз,
Һич ялган юк ошбу сүзләрдә.
Җанга оялаган яманлыклар
Бәреп чыга бит ул йөзләргә,
Бәреп чыга бит ул йөзләргә!

*1998*

## БИШЕК ҖЫРЫ

Мин сине күкләрдән эзләп,
Йолдыздан таптым.

Шуңа күрә йөзләрең ак,
Йөзләрең якты.

Коендырдым Ай нурында
Төннәр буена.
Ай нурлары кереп тулган
Синең куеныңа.

Былбыллар бәхет теләде
Сиңа таңнарда.
Агып китте сагышларың
Сары салларда.

Җәйге кояш битләреңә
Ай нурын якты.
Шуңа күрә йөзең якты,
Телләрең татлы.

*1998*

## САГЫНДЫК

Әй сагындык без мәктәпне
Каникулда чагында.
Аннан да нык сагыныр идек,
Әгәр җәйге каникуллар
Озын булса тагын да.

*1998*

## ОЗЫН КУЛЛЫ КЫЗ

*(Әкият)*

Борын-борын заманда
Шундый бер кыз булган, ди,
Кайда тәмле нәрсә бар —
Шунда кулын сузган, ди.
Әтиемә димәгән,
Әниемә димәгән —
Үзен генә уйлаган,
Үзен генә сыйлаган.
Кунак килсә, иң элек
Табынга ул утырган.
Авызына тәм-томны
Шыплап-шыплап тутырган.
Матур алма күрсә дә,
Татлы хәлвә күрсә дә,
Алган кунак алдыннан —
Һич китмәгән табыннан.
Авыздагы ризыгын
Шаптыр-шоптыр чәйнәгән.
Сүз әйтергә теләсә,
Теле көчкә әйләнгән.

Әниләре кызларын
Кыйнап та караганнар,
Үзен генә аерып
Сыйлап та караганнар.

Ләкин кызга кермәгән
Ата-ана сабагы.
Кеше алдыннан алмаса,
Һич туймаган тамагы.
Үрелгән ул уңга да,
Үрелгән ул сулга да.
Үрелә торгач кулы
Булган аның колгадай.
Буе бер колач булган,
Кулы биш колач булган.
Кулы артык озайгач,
Өйләргә сыймас булган.
Тора-бара бу куллар
Әверелгән еланга.
Сөйрәп киткән еланнар
Кызны кара урманга.
Яши, ди, кыз урманда,
Үкенә, ди, узганга.
Кайталмый, ди, өенә
Елан куллы булганга.
Менә, дуслар, шундый хәл
Булган, ди, бер илдә элек.
Сез дә оятка калмагыз
Кеше алдына үрелеп.

*1999*

## ЯЗГЫ ТАНТАНА

Язбикә болыннар буйлап
Чәчәкләр сибеп йөри.
Җил чәчәкләр тирәсендә
«Әпипә» биеп йөри.

Кояш чәчәкләргә карап
Күктән кул чабып тора.
Кояшның алкышы җиргә
Нур булып тамып тора.

*1999*

## УРАМ МАЛАЕ

Җил ул — урам малае,
Вакыты күп уйнарга.
Әллә нинди уеннар
Уйный бит ул шуңарга:
Кар-бураннар туздыра,
Морҗалардан сызгыра.
Агачка менеп китә,
Ботакларны селкетә.
Электр чыбыкларын
Таган итеп атына.
Йә тагылып китә ул
Машиналар артына.
Ауный җиргә ятып та,
Уйный карлар атып та.
Кайтыр өе булмагач

Карамый ул вакытка.
Җил шул урам малае,
Аңа рәхәт, әлбәттә.
Йөртер идем мин аны
Үзебезнең мәктәпкә.
Анда аның директор
Койрыгын кысар иде.
Җил малае шым калып
Почмакка посар иде.

*1999*

## КОШ АЛМА

Кош алма тапкан Әлинә,
«Абый, бу, — ди, — Кош алма!
Канатлары кушылган,
Кызыл түшле кош булган.

Әйдә моны очырыйк,
Китсен ерак-еракка.
Язлар җиткәч, кошыбыз
Кайтыр тагын бу якка».

Әлинә белән икәү
Очырдык алма-кошны.
Ә кошыбыз канат кагып
Ал кояшка кушылды.

Кайтыр, кайтыр кошыбыз,
Мөмкин түгел кайтмаска.
«Син кайда, Әлинә?» — диеп
Кунар ул алмагачка.

*1999*

## НӘНИ ДОКТОР

Минем әнием Алсу,
Ә мин булам Әлинә.
Нәни генә булсам да,
Булышам мин әнигә.
Әнием минем доктор,
Кешеләрне дәвалый.
Кайбер көнне эшенә
Ул мине дә алгалый.
Палатага керәм мин
Әнием белән бергә.
Керү белән тотынам
Һәммәсен терелтергә.
Кайсының кулын тотам,
Кайсының битен сыйпыйм.
Кайберсен үзе биргән
Конфеты белән сыйлыйм.
Кайсына су китерәм,
Аны тотып эчерәм.
Кайсының тирен сөртәм —
Барсын шулай терелтәм.
Ах-ух килеп ятучы
Апалар һәм абыйлар:

«Нәни доктор килгән», — дип,
Матур итеп карыйлар.
Ә без чыгып киткәндә,
Барсы кала терелеп.
Баштан сыйпап калалар:
«Безгә тагын кил», — диеп.
Киләм, киләм. Чын доктор
Булып киләм үскәчтен.
Тик мин үсеп җиткәнче
Авырулар бетмәсме?

*2000*

## КАЗАН

Барлык урамнарың матур,
Башкалам минем, Казан.
Бу кадәрле матурлыкны
Алдыңмы әллә яздан?!

Көндез күктә кояш яна,
Төннәрен йолдыз, Казан.
Тукай да синең турында
Мактап шигырьләр язган.

Көннәр буе мәчетләрдән
Яңгырап тора азан.
Җаннарга иман саласың,
Динле шәһәр син, Казан.

Синең һәрбер тәрәзәңнән
Якты бөркелә, Казан.
Йортларың синең, башкалам,
Тукылган, ахры, наздан.

*2002*

## АРАДА ШУЛ КҮПЕР ЯТА

Өйдә икәү: песи дә мин,
Ул — миңа, мин — аңа иптәш.
Серләшәбез песи белән,
Песи бик тә әйбәт сердәш.

Тыңлый белә — сүзне бүлми,
Юләр сатсаң, шыр-шыр көлми.
Ачулансаң, үпкәли дә
Озак кына янга килми.

Песинең бар үз дөньясы,
Минем дә бар эчке дөньям.
Кайчак яшерен үз дөньямның
Ишеген аңа ачып куям.

Анда песи кереп йөри,
Нәрсә барын күреп йөри,
Шунсы әйбәт: серне саклый,
Беркемгә дә мине сатмый.

Эчке дөнья безнең аерым,

Уртак яклар да бар бераз:
Миңа да гел җылы кирәк,
Аңарга да кирәк бит наз.

Ул да һәрчак өйдә бикле,
Минем дә бит ирек чикле.
Уртак язмыш якынайта —
Арада шул күпер ята.

*2002*

## ЭЧТӘЛЕК

Җиңүләр җиңел бирелми. *С.Хәкимова* .......... 5

### Беренче бүлек. Мәхәббәт — мәңгелек сер

Нурсөя *(Поэма)* .......... 14
Сөю бит ул картаюны белми *(Туплам)* .......... 38
Бүген, бәлки, нәкъ шул вакыттыр.......... 44
«Орчык кадәр генә калдың инде...».......... 45
«Бер-беребездән ераклаштык бугай...» .......... 46
«Озын, авыр юлларны без...» .......... 46
«Мин — Таһир...» .......... 47
Синең белән бәйләп язмышларны .......... 47
Якындагы бәхетең .......... 48
«Керфекләрең арасыннан...» .......... 48
«Кулъяулыкка күз нурыңнан...» .......... 49
«Алсу, Алсу!..».......... 50
«Тып-тып басып юлның ташларына...» .......... 50
«Син минем белән мавыгып...».......... 51
«Мин сиңа таба йөгерәм...».......... 52
Киттем әле .......... 52
«Үрләрнең иң биегенә басып...» .......... 53
«Әллә кайчан онытылган хисләр...» .......... 54
Карашларың адаштыра .......... 54
«Хатлар яза алмыйм, үпкәләмә...» .......... 55
Тормышымны минем яз иттең.......... 56
Булмый кичереп.......... 57
«Уемда — син, җанымда — син...» .......... 58
Сер .......... 58
«Җәй алып килдең син җиргә...» .......... 59
Әйтер идем .......... 60
Яраттырдым .......... 61
Әйтерсең син.......... 61
Болыннар булырлар чәчәкле.......... 62
«Тау башында басып тора идем...».......... 63
«Синең белән очрашырмын диеп...» .......... 63
«Әйләнәсең дә киләсең...».......... 64
«Искиткеч бер чәчәк үсә...» .......... 64
«Күктә без кабызган йолдыз...» .......... 65
Күңел пәрдәләрен күтәреп .......... 66
Яз кояшы .......... 66
«Әллә артык матур идең...».......... 67
«Күп хатын-кыз үз-үзенә...».......... 67
Шаяру .......... 68
Аучы .......... 69
Яшьлек ул — яшел җимеш .......... 70
«Гомеремнең моңсу бер чорында...».......... 70
«Арабызда чиксезлекләр ята...».......... 71
Әлинәгә.......... 72
«Нигәдер шулай тоела...» .......... 72
Сезгә.......... 73
«Сулышыма утлар капты — янмадым...» .......... 73
Елмай әйдә.......... 74
Сүзсез җыр .......... 74
«Матурлыгын белми йөргән кызлар сирәк...» .......... 75
«Хисләр давылында оча яфрак...» .......... 76

### Икенче бүлек. Гомернең мизгелләре

Чорлар күләгәсе *(Туплам)* .......... 78

Елмаеп, көн җаны яралды *(Туплам)* .......... 85
Без табигать балалары *(Туплам)* .......... 91
Йокысызлар да кирәк *(Туплам)* .......... 97
Йөрәгендә бара күтәреп *(Туплам)* .......... 103
Туган як төсе *(Туплам)* .......... 110
Үткәннәрнең кайтавазы да юк .......... 116
Капкаларны ачтым мин бүген.......... 116
Бәйрәмме ул, түгелме .......... 117
Ипи кибете.......... 118
Бу юлы син хаклы идең .......... 121
«Үзе күктә...» .......... 122
«Ирләр иртәрәк китәләр...» .......... 122
«Чәчәктәй үсеп чыгалар...» .......... 123
Күләгә һәм кояш .......... 124
«Ялкауга мендәр кирәк...» .......... 124
«Бик бай иде...» .......... 125
«Шәфәкъ вакыты...» .......... 125
Шәһәр чәчәк атачак .......... 126
Кирәк күңел өчен .......... 127
«Без инде көрәшеп туктадык...» .......... 128
Бүләк .......... 128
«Көтә кеше гомер буе...» .......... 129
«Син яшь былбыл...» .......... 130
«Бөтен нәрсә тора бәхеттән...» .......... 130
Ярдәм сорап .......... 131
Җан хөрлеге .......... 132
Юк инде .......... 132
Тапмадым .......... 133
«Җәйге иртә. Җилләр йоклый әле...» .......... 134
«Сиздермичә генә...» .......... 135
«Сәясәт җилләре безне...» .......... 136
Янар йөрәк турында легенда.......... 137
«Тишек кесәдән коелган...» .......... 140
Оныттым шуны нишләп .......... 140
Урап барам каләм очына .......... 141
Мизгел .......... 142
«Балачакның баллы эзе инде...» .......... 143
«Бетми торып бу дөньяда...» .......... 143
«Кеше җиргә яшәр өчен килә...».......... 144
Портретлар .......... 145
Юл башы .......... 146
Ак моңнар.......... 147
«Без мылтыклардан куркабыз...».......... 147
«Туганда ул бик зур булып туды...» .......... 147
«Агымсулар аша чыга кеше...» .......... 148
«Ялганнар күбәйгән саен...» .......... 148
«Чын шагыйрьләр күп булалмый алар...».......... 148
«Аерса безне аерыр...».......... 148
«Карый, карыйм — күрә алмыйм...» .......... 148
«Яна-яна арыдым инде...» .......... 149
Ике тавыш .......... 149
Карт юкә .......... 150
Урам шавы.......... 150
Ни булды .......... 151
Ирекле ил.......... 152
Сыналган халык .......... 153
Яшәү кирәк .......... 154
Хәзер инде шундый яшәү кирәк .......... 155
«Бер сорауга җавап эзлим...» .......... 156
Бер өмет .......... 157
Кунак .......... 158
Әтәч елында .......... 160
Тынлык тавышы.......... 161
«Авырып яттым...» .......... 162
«Карт агачларны кисәләр!..».......... 163
Эш тәме .......... 164
Шундый сугыш .......... 164
Шундый көн .......... 165
Ана җыры .......... 166
«Язмаган шагыйрьләр бар...».......... 167
«Яшьләр белән яшәрәм мин...».......... 167
«Елмаеп сөйләшсә берәрсе...».......... 167
«Гомере буе бик тырышып...» .......... 167
Чакыра балачагым .......... 168

Наз .... 169
Пуляның калмады кирәге .... 170
Февраль бураны .... 171
Агымсуда агып бара .... 172
Нибары .... 172
«Агыла кара болытлар...» .... 173
Шом калды .... 174
Сандугач оясы .... 175
Булыр иде сызып ташлап .... 176
Мең савапка саналыр .... 176
Нилектән .... 177
Түгел икән .... 178
Йөрәк .... 179
Һәр көн иртән .... 180
Бер кыз җырлый .... 181
Мондый бәхет тә кирәк .... 182
Хикмәтле дару .... 184
Әрнү .... 185
«Бернәрсә дә үзгәрмәде кебек...» .... 186
Аҗаган .... 187
Онытабыз .... 187
«Гәүдәм минем йодрык кадәр генә...» .... 188
Төсләр .... 188
«Үргә менә башласаң...» .... 189
«Һәр көн йөрим уйлар урманында...» .... 189
Бернәрсә дә булмый мәңгелек .... 190
«Мин беләмен дошманнарым барын...» .... 191
«Көз үзенең кулъяулыгын...» .... 192
«Уйлар буранында адаштым...» .... 192
«Бик еш атыла йолдызлар...» .... 192
«Әллә көлү, әллә елау...» .... 192
«Елаганың бармы, диләр...» .... 192
«Кошларга канат биргән...» .... 192
«— Нигә очынасың болай...» .... 193
«Канатлылар оча, дибез...» .... 193
«Биегрәк менә барган саен...» .... 193
«Ташкыннар булып агыла...» .... 193
«Ак чәчәкләр җибәргәнсең...» .... 193
«Бик биектән кошлар очып бара...» .... 194
«Шәһәр һавасы төтенле...» .... 194
«Кемдер алыштыра исемен...» .... 194
«Шешә имеп үскән балалар...» .... 194
«Чумдым тирән уйларга...» .... 194
Ике юл .... 195
Елагыз, диләр .... 196
«Тамагым тук...» .... 197
«Кайчакта күңелдә...» .... 198
«Дөнья матур...» .... 198
Яши башларга вакыт .... 199
«Бар киемен чишенеп ташлаган да...» .... 200
Ике кыз .... 200
«Яратырга сәбәп кирәк түгел...» .... 201
«Милләт, дибез, татар, дибез...» .... 201
Билгесез солдат кабере .... 202
Әйт син, доктор .... 203
Егет һәм кыз .... 204
«Якын миңа, никтер бик тә якын...» .... 204
Китаплар китабы .... 205
Җан очышы .... 206
Тәрбия .... 207
«Һәр көн саен ак кәгазьгә...» .... 207
Шундый-шундый уйлар .... 208
«Чорлар белән сыналдык...» .... 208
«Өйрәтелгән өй эте без...» .... 209
Үзебез .... 210
«Яшьлек күзләрендә...» .... 210
Чебен .... 211
Җыр суза Авзалова .... 212
«Гел камчылап торам сине...» .... 212
«Тормыш арбасының күчәренә...» .... 213
«Елгалар, диңгезләр кичтем мин...» .... 214

**Өченче бүлек. Җыр — күңелнең канаты**

Без кавышырбыз ........................................................................................................ 216
Миңа өйсез күңелсез................................................................................................... 216
Ирекле кош.................................................................................................................. 217
Өлешемә тигән көмешем............................................................................................ 218
Син кайда .................................................................................................................... 218
Туган көн...................................................................................................................... 219
Ашкыну ....................................................................................................................... 220
Яшь йөрәкләр янар чак............................................................................................... 221
Бәргәләнә йөрәк .......................................................................................................... 222
Язмышларны берләштерик ....................................................................................... 223
Таптым мин үземне .................................................................................................... 224
Синең йөрәк аңлармы?............................................................................................... 225
Яратып яраттырам ...................................................................................................... 225
Без янар өчен туган..................................................................................................... 226
Гөлҗимеш.................................................................................................................... 227
Яшел алма.................................................................................................................... 228
Безнең йолдыз ............................................................................................................. 229
Соң булыр.................................................................................................................... 230

## Дүртенче бүлек. Балачак

Өйдә калам .................................................................................................................. 232
Күпмегә зыян .............................................................................................................. 232
Үпкә ............................................................................................................................. 233
Туйдым инде бу күлмәктән........................................................................................ 233
Әллә кече, әллә зур ..................................................................................................... 234
Бүреккә хуҗа табылды ............................................................................................... 234
Этюд............................................................................................................................. 235
Аңламыйм мин абыйны ............................................................................................. 235
Каян белгән?................................................................................................................ 236
Бияләй........................................................................................................................... 236
Сабыр Сабир ................................................................................................................ 236
Кайчы һәм энә ............................................................................................................. 237
Мактану бәласе ........................................................................................................... 237
Соры борынлы кошчык .............................................................................................. 238
Варис............................................................................................................................. 238
Ашык-пошык Галәви................................................................................................... 239
Күчәр һәм тәгәрмәч .................................................................................................... 239
Гаделша командасы .................................................................................................... 240
Маэмай-художник ....................................................................................................... 244
Оныгы һәм әбисе ........................................................................................................ 244
Октябрь......................................................................................................................... 245
Көйсез бала................................................................................................................... 245
Такырбаш .................................................................................................................... 246
Бергә-бергә .................................................................................................................. 246
Эзләдем, ди, апасын..................................................................................................... 247
Нинди савыт тәмлерәк................................................................................................ 247
Хикмәтле сүз ............................................................................................................... 248
Малай такмагы............................................................................................................. 248
Иң матур җир .............................................................................................................. 249
Кечкенә патша.............................................................................................................. 249
Көч бирәсең миңа син, Муса...................................................................................... 250
Сәгать........................................................................................................................... 250
Ана турында баллада................................................................................................... 251
Үлемсез җыр ................................................................................................................ 252
Бал корты...................................................................................................................... 253
«— Мин югары, син түбән...».................................................................................... 253
Күктә............................................................................................................................. 254
Күкеле сәгать .............................................................................................................. 254
Кояш һәм каз бәбкәләре ............................................................................................. 255
Гайни ........................................................................................................................... 256
Ап-ак иткән .................................................................................................................. 257
Композитор чыпчыклар ............................................................................................. 257
Сабантуй....................................................................................................................... 258
Кая киткән тамчылар? ................................................................................................ 258
Бушлай билет «саталар» ............................................................................................ 259
Әллә кайчак... .............................................................................................................. 259
Ак болытлар ................................................................................................................ 260
Язгы парчалар .............................................................................................................. 260
Мөнипнең дәфтәре....................................................................................................... 261
Йолдызлы кич ............................................................................................................. 261
Ярык койрык ................................................................................................................ 262
Охшашлык.................................................................................................................... 262
Футбол .......................................................................................................................... 263

Бәби кемгә охшаган? ........ 263
Төшермәдем ........ 264
Җәй көне дә шуармын ........ 264
Әнием һөнәре ........ 264
Моңлы минем кураем ........ 265
Чуар тавык ........ 265
Бушлык ........ 266
Тапкан тәмле нәрсәне ........ 266
Март кояшы ........ 267
Апрель ........ 267
Май ........ 268
Июнь-июль ........ 268
Август ........ 268
Сентябрь ........ 269
Йорт һәм оек ........ 269
Менә шулай үсә алар ........ 270
Ай ........ 270
Мин бит синең Илдарың ........ 271
Бабаң кебек бул, диләр ........ 272
Энә ........ 272
Ике кыз һәм бер көчек ........ 274
Бәп-бәләкәй Апуштан ........ 275
Тотылды ........ 276
Чаңгы шуганда ........ 276
Чәчәкләр яратучы ........ 277
«Җенле» мендәр ........ 278
Суык төсе ........ 278
Яши алмыйм шунсыз ........ 279
Буран белән дуслаштык ........ 279
Бераз көтәргә микән? ........ 280
Безнең бабай ........ 280
Уйлап табучы ........ 281
Аю тун ........ 282
Мөнип ........ 282
Нурлыбаян ........ 283
География дәресендә ........ 284
Рәхәт тә соң! ........ 284
Дамир ........ 285
Сөенче ........ 286
Безнең авыл ........ 286
Авылда печән өсте ........ 287
Кем булды икән янымда ........ 287
Ындыр ........ 288
Мичче карт ........ 288
Суыкборын һәм Суыкколак ........ 289
Калмагыз соңга ........ 291
Укытучы булдым ........ 291
Шаян малай ........ 292
Илдус ........ 293
Мәктәптән кайтып киләм ........ 294
Гадәт ........ 295
Минем әни ........ 295
Авылыбызда туй бүген ........ 296
Илшат һәм җил ........ 297
Туган як табигате ........ 297
Горур Каенбикә ........ 298
Тукай аша ........ 299
Кыям һәм куян ........ 300
Авылдан киләм ........ 300
Баулы ягым ........ 301
Искәндәрнең киңәше ........ 302
Халикъ, балык һәм песи ........ 302
Цирк килгәч ........ 303
Баллы су ........ 304
Күпер ........ 304
Кем гаепле ........ 305
Әтисенә охшап ........ 306
Молодец минем әби ........ 306
Рәхмәт сиңа, замана ........ 307
Нигә кызык Илһамга? ........ 308
Өй артында шомыртым ........ 308
Мультфильмнар карыйбыз ........ 309
Күз тидерәм кирегә ........ 310
Айнур ........ 310

Каян белгән бал кортлары 311
Каргалар теле 312
Әйтергә бик авыр сүз 313
Ялкау ялы 313
Беренче звонок 314
Яшен һәм яңгыр 315
Кемнәр тибеп җибәргән? 316
Минем чана 316
Җиңеләйтү чарасы 317
«Әйбәт» явыз 318
Кран 318
Җиргә якын булса кеше 319
Бәп-бәләкәй булсам да 320
Му-му-му... 320
Әни 321
Тапкыр җавап 322
Авыр көн 322
«Радиодан әйттеләр...» 322
Кем ялгышкан? 323
Кибеттә 323
Фазыл 323
Шул явызны күрсәләр 324
Аида 324
Укыр идем бишкә генә 325
Бөек шагыйрь 326
Ару турында 326
Тылсымчы 327
Узыш 328
Серле чишмә 328
Юллар юлы 329
Минем сакчым 330
Туймыйм 331
Куллар 332
Сорау һәм җавап 333
Кыш 334
Төгәл үлчәү 334
Шундый ул 335
Кыш башы 335
Тиргәү 336
Ком өстендә ике малай 336
Әйбәт кешеләр 337
Арттан йөрер идегез 337
Көнләшмим мин 338
Карабай 339
Күзе китапта гына 340
Яз 340
Арифметиканың дүрт гамәле 341
Кечкенә кеше 342
Табу һәм югалту 343
Сүзсез генә 344
Ай турында әкият 344
Аунар иде 346
Тырыша торгач 346
Иң әйбәт нәрсә кемдә? 347
Әдәпле бала 348
Әти карап торганда 348
Ялкау песи 348
«Шигырь кайда — бөтен төштә...» 349
Күчтәнәч 350
«Сабан туе бара. Ә бер читтә...» 350
Якты тәрәзәм 351
Күңелле мәшәкать 352
Йомгак 352
Мөгез 353
Челәп 354
Сүздә торучан кунак 354
Без барсын да беләбез 355
Тау сырты 356
Тау бите 356
Урман авызы 357
Елга култыгы 358
Бер генә 359
Инде танып алгансыздыр 360
Бөтенесе кирәк 360

Ул белмәгәнне белә ........ 361
Тел ачкычы ........ 362
Көзге табын ........ 362
Шаккату ........ 363
Мин андый малай түгел ........ 364
Елга монологы ........ 364
Рәнҗемәсен ........ 365
Җыр башы ........ 366
«Яз килә, боз сөңгеләрен...» ........ 366
Җир өстендә җиз кыңгырау ........ 367
Төнге маҗара ........ 367
Калыр идем ........ 368
Үсеп кенә җитим әле ........ 369
Пычрак ........ 370
Шәп корал ........ 370
Нәрсәгә? ........ 371
Сөенә беләсеңме? ........ 371
Менә шундый хыяллар ........ 372
Узар идем ........ 373
Тыңлаусыз туп ........ 374
Әниләр бәйрәмендә ........ 376
«Урман — колак, кыр — күз...» ........ 376
Каләм эзлим ........ 377
Гөлләрем ........ 378
Әнкәсе белән улы ........ 379
Ике дөнья — ике елга ........ 379
Черки ........ 380
Кыз һәм кран ........ 380
Шунда Мөнип килеп чыккан ........ 382
Кар өстендә кара мәче ........ 382
Әгәр инде өч өрсә ........ 383
«Бозның борыны җебегән...» ........ 383
Ычкындырмам, чыдармын ........ 384
Иң көчле дару ........ 384
«Котырды җил, котырды...» ........ 386
Иң иртә ........ 386
Әби, бабай рәхмәт әйтә ........ 387
Әти эзе ........ 387
Кыска вакытлы яңгыр ........ 388
Каргалар күтәреп китәр ........ 388
Оча торган чәчәкләр ........ 389
Барсына да җитә ........ 390
«Үтте сызылып җәйге яшен...» ........ 390
Атлар чишмәсе ........ 391
Аласын алып бетергәч ........ 393
Батыр песи ........ 393
Галим песи ........ 394
«Җирдә юллар бар чагында...» ........ 394
Өзмим әле акларын ........ 394
Кыңгыраулар тавышы ........ 395
Яну ........ 396
Бүгенге көн ........ 396
Татарстан байрагы ........ 397
Әни, синең хәер-фатихаң ........ 397
Айдагы чыпчык ........ 398
Тапкыр җавап ........ 398
Эт алыр идем мин дә ........ 399
Миңа үсәргә кирәк ........ 399
Күңелдә бер теләк ........ 400
Күңелле көн ........ 401
Яңгыр теләү ........ 402
Безнең таләп ........ 402
Бәлки ........ 403
Физзарядка ясый ........ 403
«Җир өстенә сирәк кенә булып...» ........ 404
Калсын безнең эзләребез ........ 404
Шуңа күрә дә без малайлар ........ 405
Кызлар җыры ........ 405
Өч нәрсә ........ 406
Онытып куйсак ........ 406
Суык ........ 407
Тавышсыз пулемет ........ 407
«Килеп җитте җәй уртасы...» ........ 407
Ак кәгазь ........ 408

Аклык.......... 408
Серле көндәлек .......... 409
Агымсу.......... 409
Кызык нәрсә .......... 410
Салават күпере .......... 410
Бай кеше .......... 411
Сандугач тыйнаклыгы .......... 411
Үзебез хуҗа булгач.......... 412
Минем эт буласым килә .......... 412
Калыйк вакытында сорап .......... 413
Ызгышырга нигез юк.......... 413
Ашыгыйк .......... 414
Атым-канатым .......... 414
Февраль.......... 415
«Сайраганы, сайрамаганы бар...» .......... 416
Юлбасар.......... 416
Язгы туй .......... 417
Тик игелек мәңгелек .......... 417
Чыпчык, әни һәм мин .......... 418
Чынлап әйтәм.......... 418
Бер такта .......... 418
Бердәнбер .......... 419
Кайсы көчлерәк.......... 419
Тиз үсү ул — бик яхшы.......... 420
Бөтен кеше бай булыр .......... 420
Үпкәләү.......... 421
Бөтен эт — минем дустым .......... 421
Шагыйрь бәхете .......... 422
Чалбары юк, ди .......... 423
Мактанчык чебен .......... 423
Ала карга .......... 424
Ачу килә .......... 424
Саескан .......... 424
Табышмак.......... 425
Яманлык дигән кортка.......... 425
Песи һәм тычканнар .......... 426
Кызчык һәм кошчык.......... 428
Ике кеше.......... 429
Яңгыр.......... 429
Милләтем.......... 430
Горур булыйк .......... 431
«Бу дөньяның ние бар?..» .......... 431
Диңгез .......... 432
Ата хулиган .......... 433
Йокы чакыру .......... 434
Барганда һәм кайтканда .......... 434
Үсмәм микән, нык тартсаң.......... 435
Әй, дусларым, килегез.......... 436
«Акыллы фикер искерми...».......... 437
«Ак күгәрчен, күк күгәрчен...» .......... 437
Анам теле .......... 438
Төпчек малай.......... 439
Нужа.......... 439
Явыз чебен.......... 440
Шунсы начар.......... 441
«Кошлар кунарга ярата...».......... 441
Озак-озак яначак .......... 442
«Зур дәрьялар кичтем диеп...» .......... 443
Бетмәс .......... 443
Канатлы егет .......... 444
Сагынам шул чакларны.......... 449
Сез кирәк .......... 450
Бер дә рәхмәт әйтмиләр.......... 451
Эшнең аның берние юк .......... 452
Кунак кызы шикелле .......... 452
Кошларыбыз ни эшләр .......... 453
Алмагачның үпкәсе .......... 454
«Кошлар китә, кошлар кайта...» .......... 455
«Агач телләр дә була...» .......... 455
Рәхмәт сезгә, апалар .......... 456
Әкият кызы.......... 461
Сәвия нигә елаган .......... 464
Гыйнвар бабай.......... 465
Гөлшат .......... 466

Булган әйбәт заманнар ... 466
Күке ... 467
Элемтәче үрмәкүч ... 468
Чыпчыклар ... 469
Үсәм ... 470
«Апам белән икебез...» ... 470
«Күңелеңдә болыт булса...» ... 470
Әйбәт песи ... 471
Черкиләр җыры ... 471
«Күкләр була җиде катлы...» ... 472
Этюд ... 472
«Күктә йолдызлар шундый күп...» ... 473
Ни бар аннан татлырак? ... 473
Арылды ... 474
Бәреп чыга бит ул йөзләргә ... 475
Бишек җыры ... 476
Сагындык ... 476
Озын куллы кыз *(Әкият)* ... 477
Язгы тантана ... 478
Урам малае ... 479
Кош алма ... 480
Нәни доктор ... 481
Казан ... 482
Арада шул күпер ята ... 483

Литературно-художественное издание

***Яруллин** Фанис Гатауллович*

**ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

В трех томах

Том I

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Яруллин** Фәнис Гатаулла улы*

**ӘСӘРЛӘР**

Өч томда

I том

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Р.Н.Нуруллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.12.2007. Форматы 84г108 1/32. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 26,04. Шартлы буяу-оттиск 26,46. Нәшер-хисап табагы 22,69. Тиражы 2000 д. Заказ С-1529.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.